# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2022 3(35)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык шагыйре (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Нур-Солтан)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

## БУ САНДА

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Вәлиева М.З.* XVII–XVIII гасыр язма истәлекләрендә антонимия күренеше *(кешенең холкы белән бәйле лексик антонимнар мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Хәбибуллина Л.Г.* Татар теленең урта диалекты минзәлә сөйләшенең синтаксик үзенчәлекләре *(Татарстан Республикасының Актаныш районына үткәрелгән фәнни экспедиция материаллары нигезендә)* . . . . . 15
*Гарипова И.З., Денмөхәммәтова Э.Н.* Фразеологик берәмлекләр аша кешегә бәя бирү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
*Ханнанов Р.Г.* Хәзерге заман сүз сәнгатендә әдәби тел нормалары: грамматик башлангыч һәм проблемалар . . . . . . . 25
*Хәкимов Б.Э., Шәехов М.Р.* Русча-татарча машина тәрҗемәчесе өчен параллель тест корпусында җөмләләр тәңгәллеге . . . . . . 31

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Хасавнех А.А., Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Әбү Бәкер Каландар Руминың «Каландар-намә» исемле суфичыл әсәрендә мәхәббәт классификациясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
*Хөббитдинова Н.Ә.* Габдулла Тукай иҗатында милли-мәдәни антропологик образлар: сәнгатьчә универсалияләр һәм интертекстуальлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
*Сәмитова С.Г.* Гаяз Исхакый иҗатында милли проблемаларның гаилә яссылыгында чагылышы *(«Ул икеләнә иде» (1915) һәм «Ул өйләнмәгән иде» (1916) повестьлары мисалында)* . . . . 55
*Сафиуллина Р.Ф.* Татар шагыйре Габделҗәббар Кандалый шигъриятендә әдәбиятара бәйләнешләр: заманча караш . . . . . 63

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Закирова И.Г.* Стадиаль яктан иң соңгы чор эпик әсәре буларак «Әйтүкә» романик дастаны: өйрәнү тарихы һәм реконструкция . 71
*Фазлетдинов И.К.* Башкортстан татарларының качкыннар һәм караклар турындагы риваятьләрендә тарих һәм мифология синтезы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
*Каюмова Г.Ф.* Үсемлек образлары кулланылган татар һәм төрек мәкальләрендә кыйммәтләр чагылышы. . . . . . . . .100

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Гайнетдинов А.М.* Казан губернасы Мамадыш өязе Шепшеңәр авылы тарихыннан (XVII гасырның икенче яртысы – XVIII гасыр) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .108

**СӘНГАТЬ**

*Мусина Р.Р.* Саклау зонасы буларак рухи традицияләр *(халык сәнгать промыселлары турындагы закон буенча фикер алышуга)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116

*Шәмсутова А.А.* Татар драматургиясендә тарихи-мәдәни күренеш буларак «театраль пространство» категориясе. . . . . . 119

**ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР**

Солтан Габәши татар музыкасы турында *(дәвамы)* . . . . . . . . . 130

*Мифтахетдинова Н.М.* Төрки телле язу машиналарында Яңалифкә яраклаштырылган стандарт клавиатура проектлары . 139

*Г. Шәрәф* Ильинский Блюменау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Каюмова Г.И.* Камаллар династиясенең дәвамчысы *(Г. Камалованың тууына 100 ел тулу уңаеннан)* . . . . . . . . . . . 153

*Миңнуллина Ф.Х.* Олы галим, милләтпәрвәр шәхес *(Н. Ханзафаровның 85 яшьлек юбилее уңаеннан)* . . . . . . . . . . 161

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Солтангәрәева Р.Ә.* Татар мифологиясе һәм дөнья *(«Татар халык иҗаты: 25 томда. 1 т.: Мифология» ([төз., иск. һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт. Л.Х. Дәүләтшина] Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. 511 б.) китабына рецензия)* . . 167

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Валиева М.З.* Антонимия в письменных памятниках XVII–XVIII вв. *(на примере лексических антонимов, обозначающих черты характера человека)* . . . . . . . . . . . . 7

*Хабибуллина Л.Г.* Синтаксические особенности мензелинского говора среднего диалекта татарского языка *(на примере материалов научных экспедиций в Актанышский район Республики Татарстан)* . . . . . . . . . . 15

*Гарипова И.З., Денмөхәммәтова Э.Н.* Описание и оценка человека посредством фразеологических единиц . . . . . . . . . 19

*Ханнанов Р.Г.* Нормы литературного языка в современных художественных произведениях: грамматические основы и проблемы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25

*Хакимов Б.Э., Шаехов М.Р.* Эквивалентность предложений в параллельном тестовом корпусе для русско-татарского машинного переводчика . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Хасавнех А.А., Мухаметзянова Л.Х.* Классификация любви в суфийском произведении Абу Бакра Каландара Руми «Каландарнаме» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36

*Хуббитдинова Н.А.* Национальные культурные антропологические образы в творчестве Габдуллы Тукая: художественные универсалии и интертекстуальности . . . . . . 46

*Самитова С.Г.* Отражение этнически детерминированных проблем сферы межгендерных отношений в творчестве Гаяза Исхаки *(на примере повестей «Он сомневался» (1915) и «Он еще не был женатым» (1916))* . . . . . . . . . . . . . . . . 55

*Сафиуллина Р.Ф.* Проявление межлитературных связей в творчестве татарского поэта Габдельджаббара Кандалый: современный взгляд . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Закирова И.Г.* Произведение «Айтука» как стадиально поздний романический дастан: история изучения и реконструкция . . . . 71

*Фазлутдинов И.К.* Синтез истории и мифологии в преданиях татар Башкортостана о беглецах и разбойниках . . . . . . . . . . 84

*Каюмова Г.Ф.* Олицетворение человеческих ценностей через образы растений в татарских и турецких пословицах . . . 100

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Гайнутдинов А.М.* Из истории деревни Шепшенар Мамадышского уезда Казанской губернии (вторая половина XVII – XVIII век). . . . . . . . . . . . . . . . . 108

## ИСКУССТВО

*Мусина Р.Р.* Духовные традиции как охранная зона *(к обсуждению закона о народных художественных промыслах)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116

*Шамсутова А.А.* Категория «театральное пространство» как историко-культурный феномен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

Султан Габаши о татарской музыке *(продолжение)* . . . . . . . . . 130

*Мифтахутдинова Н.М.* Проект стандартной клавиатуры, адаптированной к Яналифу на тюркоязычных пишущих машинках . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139

*Г. Шараф* Ильинский Блюменау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148

## ПЕРСОНАЛИИ

*Каюмова Г.И.* Преемница династии Камаловых *(в связи со 100-летием со дня рождения Г. Камаловой)* . . . . . . 153

*Миннуллина Ф.Х.* Известный ученый, патриот *(к 85-летнему юбилею Н. Ханзафарова)* . . . . . . . . . . . . . . . . 161

## НОВЫЕ КНИГИ

*Султангареева Р.А.* Татарская мифология и мир *(рецензия на книгу «Татар халык иҗаты: 25 томда. 1 т.: Мифология» ([төз., иск. һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт. Л.Х. Дәүләтшина] Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. 511 б.)* . . . 167

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.145

***М.З. Вәлиева***

# XVII–XVIII ГАСЫР ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ АНТОНИМИЯ КҮРЕНЕШЕ
## (кешенең холкы белән бәйле лексик антонимнар мисалында)

Данная статья посвящена анализу лексических антонимов, обозначающих черты характера человека в старотатарском языке на примере произведений XVII–XVIII вв. Автор анализирует функциональные особенности антонимов, также в статье уделяется внимание взаимодействию антонимов со своими синонимическими рядами в данных источниках. На основе анализа выясняется, что лексические антонимы представляют богатый лексический ресурс и широко используются в письменных источниках XVII–XVIII вв. для создания выразительности.

**Ключевые слова:** письменные источники XVII–XVIII вв., старотатарский язык, антонимы, синонимы, семантика.

The article is devoted to the analysis of lexical antonyms denoting human character traits in the Old Tatar language on the example of the works of the 17th–18th centuries. The author analyzes the functional features of antonyms, the article also pays attention to the interaction of antonyms with their synonymic rows in these sources. Based on the analysis, it turns out that lexical antonyms represent a rich lexical resource and are widely used to create expression in written sources of the 17th–18th centuries.

**Keywords:** written sources of the 17th–18th centuries, the Old Tatar language, antonyms, synonyms, semantics.

Тел белемендә антонимия күренешен фәнни нигездә тикшерүгә багышланган шактый хезмәтләр язылуга карамастан, ул бүген дә актуаль проблемаларның берсе булып тора. Рус тел белемендә антонимнар Л.А. Булаховский [Булаховский, 1953], А.А. Реформатский [Реформатский, 1967], Н.М. Шанский [Шанский, 1977] хезмәтләрендә тикшерелсә, татар телендә антонимия күренеше К. Насыйри [Насыйри, 1975] хезмәтләрендә яктыртыла башлый. XX гасырның икенче яртысында татар теленең антонимик системасын фәнни тикшерүгә, системага салып бирүгә, төрле аспектлардан чыгып яктыртуга Г.Х. Әхәтов [Әхәтов, б. 32–33], Ш.С. Ханбикова [Ханбикова, б. 3–6], Ф.С. Сафиуллина [Сафиуллина, б. 51–56], М.Б. Хәйруллин [Хайруллин, б. 105–108], И.Б. Бәширова [Баширова, 2010, б. 232–264] һ.б. кебек галимнәр үзләреннән зур өлеш кертә. Болардан тыш, антонимнарны төркемләү принциплары, төп үзенчәлекләре, аеруча лексик, морфологик төркемнәре Р.М. Закированың кандидатлык диссертациясендә [Закирова, 2001] киң яктыртыла.

Бүгенге көндә галимнәр антонимнарны, беренче чиратта, тел һәм контекстуаль антонимнарга бүлеп тикшерә. Тел антонимнары дигәндә, контексттан тыш та антоним буларак кабул ителә, аларның капма-каршы мәгънәле сүзләр икәнен телдә сөйләшүче һәр кеше җиңел тоя торган сүзләр күздә тотыла [Татар лексикологиясе, 1 т., б. 177]. Билгеле бер контекстта, ситуациядә генә антоним булып килгән тел берәмлекләре контекстуаль антонимнар булып карала [Татар лексикологиясе, 1 т., б. 177].

Матур әдәбиятта, халык авыз иҗатында антонимнар гасырлар дәвамында кулланылуы, язучы яки шагыйрьгә фикерен төгәл җиткерү, вакыйга-хәлләрне, эчке кичерешләрне сәнгатьле сурәтләү өчен үтемле стилистик чара булуы, телне лексик-семантик яктан баетуы белән зур әһәмияткә ия. Шуңа да карамастан, антонимнарның матур әдәбият телендә, аеруча борынгы язма истәлекләрдә кулланылыш үзенчәлекләре бүгенге көндә махсус тикшерелмәгән диярлек. Шуларны күздә тотып, без әлеге мәкаләдә XVII–XVIII гасырлар язма истәлекләрендә чагылыш тапкан лексик антонимнарның кулланылыш үзенчәлекләрен яктыртуны максат иттек. Язма чыганакларда лексик антонимнар арасында аеруча кешенең эчке һәм тышкы сыйфатлары белән бәйле сүзләр үзләренең кулланылышы ягыннан кызыклы булулары белән аерылып тора. Алар арасында төрле тамырдан булган антонимнар да, бер тамырдан булган капма-каршы мәгънәле берәмлекләр дә күзәтелә. Фактик материалга нигезләнеп, кешенең эчке һәм тышкы сыйфатлары белән бәйле төшенчәләргә тукталдык. Үзара антонимик мөнәсәбәттә торучы төшенчәләрне аерып чыгардык һәм анализлау барышында шушы төшенчәләрне белдерә торган лексик берәмлекләрнең синонимик парларына да игътибар итәргә тырыштык.

*Аң-акыл һәм акылсызлык.* Бу төшенчәләр чыганакларда *гақыллы, зирәк* һәм аларга антонимик мөнәсәбәттә торган *гақылсыз, дивана* һ.б.сүзләре белән белдерелә.

*Акыл, акыллылык* – язма истәлекләрдә кешене кеше иткән иң төп сыйфатларның берсе буларак югары бәяләнә: *Ғали әйде, бән үзем гақыл wә балиғым, чунки синдән кечек wакытда күб-күб тәғлим алдым* [Мөслими, б. 39]. Хатын-кызга карата әйтелгән *гақыллы* сүзе әсәр героеның аңлы, зиһенле, төпле, уйлап эш итә торган булуын, аның зирәклеген искәртә: *Олы бикнең гақыллы тол қалған хатыны бар ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 86].

Бер тамырдан ясалган *гақыллылар – гақылсызлар* антонимик парларының бергә кулланылышы түбәндәге мисалда чагылыш таба: *Әй қалтақ, бу нә эшдер, гақыллылар белерләр, гақылсызлар көләрләр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 87].

*Ғақылсыз* лексемасының синонимик пары буларак *дивана* сүзен атарга мөмкин. Биредә ул конкрет затны атау максатыннан телгә алына: *Шаһ йоқысындан уйғанды, күрде ки, бер дивана йөрер* [Мөслими, б. 16]; *Дивана андан играз идеб арлы-бирле қарады* [Мөслими, б. 16].

*Ғақыллы* сүзенең синонимы булып *зирәк* лексемасы кулланыла: *Аңа Ходаwәндәи ғаләм бер уғыл биреб ирде, ғаҗәйеб зирәк wә ғақыллы wә кямил* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, б. 505]. Әлеге мисалларда *зирәк* лексик берәмлегенә борынгыдан салынган югары бәянең гасырлар үтү белән үзгәрмәве, буыннан-буынга рухи кыйммәт, олы тәҗрибә буларак күчә баруы күренә.

*Сабырлык – сабырсызлык.* Дини карашлар, ислам дине тәгълиматы тарафыннан сабыр итү, сабыр булу хуплана, сабыр кеше Аллаһ тарафыннан зурлана. Бу төрки-татар халкының халык авыз иҗатында, язма чыганакларында мөһим урын алып тора. Язма чыганаклардан күренгәнчә, сабырлык кешедән ныклык, зур энергия таләп итә, ул кешене гомере буена озата барырга тиеш. Теләсә нинди авыр шартларда да үзенең тынычлыгын җуймаган, саклап кала алган кеше һәрчак югары бәяләнә. Галимнәр фикеренчә, сабырлык – адәм баласының үзеннән, аның ихтыярыннан өстен торган әхлакый-этик һәм фәлсәфимифологик категория [Татар мифологиясе, б. 302]. Әлеге сыйфат белән бәйле төшенчәләр язма чыганакларда *сабыр, сабыр әһле, сабыр қылу* һәм аларга капма-каршы мәгънәдәге *сабыры қалмау, сабырдин үтү, сабыр қылыры қалмау* кебек сүз һәм сүзтезмәләр белән аңлатыла. Аеруча суфи шагыйрь Мәүлә Колый иҗатында сабырлыкка дан җырлана, сабыр итү белән күп нәрсәләргә ирешеп булуы ассызыклана: *Сабыр берлә гөлләр ачылыр, китәр қышлар* [Мәүлә Колый, б. 491]; *Сабыр берлә гәүһәр булыр энҗе ташлар* [Мәүлә Колый, б. 491]. Шагыйрь һәммә кешене, шул исәптән үзен дә тыныч булырга, *сабырлык көймәсенә менәргә* өнди: *Мәүлә Колый, сабыр эшен гадәт иткел* [Мәүлә Колый, б. 491]; *Сабырлық көймәсенә беник, иқра* [Мәүлә Колый, б. 491].

Шулай итеп, язма чыганакларда ‘сабыр, сабырлык’ төшенчәсе күпмедер дәрәҗәдә дини рухны чагылдырып, геройның вакыйганы ничек бар, шулай кабул итеп, дөнья байлыкларыннан өстен булып, иң авыр чакта да тотнаклык, түземлек саклап кала белүен аңлата: *Падишаһ хәзрәте бик **сабыр әһлендән** ирде, қараwылчыларға чағырмайыб, ақрын әдәб берлә, йа фәлән, сән бәнем тәхетемнең айақларыны кисмәгел, зира ки аталарымыздан қалған мирасдыр, зиннәте китмәсен, диде* [Мөслими, б. 16]. Әлеге мисалдан аңлашылганча, *сабыр* лексик берәмлеге *сабыр әһле* сүзтезмәсендә килеп, патшаның түземлеген генә түгел, ә хакимнәргә хас олпатлыгын да күрсәтә. Нинди генә авырлыклар килсә дә, тынычлыгын югалтмыйча, түзем булып калу язма истәлектә *сабыр қылу* сүзтезмәсе белән аңлатыла: *Нәсры гаййәр **сабыр қылды*** [Мәҗмүгъ әл-хикәят, б. 515]; *Шаһзадә **сабыр қылды** wә ул мәхбүбәне бисийар дус тотар ирде* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, б. 507]; *Мин көмәнле, бер анча көнгә **сабыр қылсаң** булыр ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 70].

Югарыда саналган лексик берәмлекләргә антонимик мөнәсәбәттә торучы *сабыры қалмау, сабыр қылыры қалмау* кебек сүзтезмәләр геройның түземлеге бетүгә, сабырсызлыкка ишарә итә: *Падишаһзадә*

*қатиғ пәришан булды, һич* ***сабыры қалмады*** [Мәҗмүгъ әл-хикәят, б. 509]; *Моңа* ***сабыр қылырым қалмады*** *диб, пәри қызыны хазыйр қылыб әйтде* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, б. 509].

‘Түземлек-чыдамлык бетү’ мәгънәсе *сабырдин үтде* сүзтезмәсе белән дә бирелә. Түбәндәге мисалда бу сүзтезмә геройның сабырлыгы бетүне генә түгел, ә түземлеге төкәнеп, ачуы килә башлавы кебек рухи халәтен дә ача: *Әйтде: бу эш* ***сабырдин үтде*** [Мәҗмүгъ әл-хикәят, б. 509].

Мисаллардан күренгәнчә, нинди генә авыр хәлдә дә сабыр булып кала алу һәркемнән зур ихтыяр көче таләп итә, ә шушы сыйфатка ия кеше татар халкында, суфичылык әдәбиятында аеруча югары бәяләнә, мактала.

*Дәрманлы – дәрмансыз.* Бу төшенчәләрдә кешенең рухи көче турында гына түгел, физик мөмкинлекләре, хәле, куәте хакында да сүз бара. Әдәби ядкярләрдә бу мәгънәләр, беренче чиратта, бер үк тамырдан ясалган *дәрман* һәм *дәрмансыз* антонимнары һәм гарәп-фарсы телләреннән кергән *мәдәт, қуәт, қодрәт* кебек лексик берәмлекләр белән җиткерелә. Түбәндәге мисалларда *дәрманлы* һәм *дәрмансызлық* дериватлары әдәби геройның хәле хакында сөйли: *...wә қатиғ дәрманлы булды* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, б. 508]; *Ачлықдин, дәрмансызлықдин би уғлы Балинны бер ботқа бирделәр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 72].

*Турылыклы, гадел – угры.* Бу төшенчәләр күпчелек очракта чыганакларда *ышанычлы, гадел* һәм аларга антонимик мәгънәдә кулланылган *қарақ* кебек лексик берәмлекләр белән бирелә.

Язма истәлектә әсәр героеның теге яки бу уңай сыйфатын төгәл итеп, аерып атау очраклары еш күзәтелә. Мәсәлән, ышанычны аклый торган, эш-хәлне ышанып, икеләнмичә тапшырырга лаеклы, турылыклы кебек сыйфатларны язма истәлектә *ышанычлы* лексик берәмлеге җиткерә. Ул *киңәшче* сүзе белән янәшә килеп, бу сыйфатка ия кешенең файдалы һәм турылыклы кеше-дус булуына басым ясый: *Қунғрат би анларның* ***ышанычлы*** *киңәшчесе ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 75].

Түбәндәге мисалда урын алган *файдалы* һәм *ғадел* лексемалары исә геройны халык мәнфәгатьләрен кайгыртып, халыкка намуслы хезмәт итеп, ярдәм күрсәтеп яшәүче турылыклы шәхес итеп тасвирлый, ягъни ил күләмендә файдалы кеше булуын ача: *Андин соң Чыңгыз үсде, олыгайды, халыққа* ***ғадел*** *дад қылыб, файдалығ булды* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 74].

‘Турылыклы, ышанычлы’ төшенчәсен язма истәлектә гарәп алынмасы *фазыйл* лексик берәмлеге дә күпмедер дәрәҗәдә ачыклап килә. Дөрес, бу лексема еш кына намуслы, турылыклы, кешелекле, инсафлы кебек сыйфатларга ия кешене бәяләү өчен дә файдаланыла. Мәсәлән, түбәндәге җөмләдә *фазыйл wә камил табибе* сүзтезмәсе табибларның намуслы, гадел, кешелекле булу белән бергә, һәрьяклап камил икәнлегенә дә басым ясый: *Падишаһзадә әйде: мәнең* ***фа-***

***зыйл wә камил*** *табибе хазиқларым күб торыр* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, б. 506].

‘Турылыклы, гадел’ төшенчәләренә антонимик мөнәсәбәттә торучы ‘урлашучы, кеше әйберен алучы, урлауга һәвәс кеше, ялганчы’ төшенчәсе язма истәлектә төрки-татар сүзе *қарақ* белән атала: *Хан илчеләр артындин йазу йибәрде, син* ***қарақсың****, сиңа нә өчен қальғаларымызны ачалық* [Мөслими, б. 42].

Аның абсолют синонимы буларак мәгълүм *уғры* лексемасы да шул төшенчәдә кулланыла: *Әй, Бүртә Күчин, син бу сыйфатлы күрекле кеше, нә өчен мондый эш қылдың, бу уғланларны йәшерден,* ***уғры*** *булдың – тиделәр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 77].

Ә менә түбәндәге мисалда *уғры* лексик берәмлегенең семантикасы киңәя, ул урлаучы яки ялганчыны гына түгел, ә кеше үтерүчене дә аңлата башлый: *Хәзрәте Мир Тимер йығлады, бу ғалимне қайу* ***уғры*** *үлтерде икән див, хәсрәтдә улды* [Мөслими, б. 40].

*Рәхимле – залим.* Антонимик мөнәсәбәттә торучы әлеге төшенчәләр язма чыганакларда *шәфкать, рәхим, рәхимле, рәхим қылу, рәхимлек қылу* һәм бу лексик берәмлекләргә капма-каршы мәгънәдәге *залим, залим булу* кебек сүз һәм сүзтезмәләр ярдәмендә бирелә.

Кешегә хас иң уңай сыйфатларның берсе буларак мәгълүм мәрхәмәтлелек, рәхимлелек Мәүлә Колыйда *шәфқәт қылғай* сүзтезмәсе белән җиткерелә: *Хәлен сораб, Ғарипләргә* ***шәфқәт қылсаң*** [Мәүлә Колый, б. 495]; *Халем күреб, шайәт* ***шәфқәт қылғай*** *мәңа Йар йулында башым-җаным кичәр булсам* [Мәүлә Колый, б. 496].

‘Мәрхәмәтле, шәфкатьле, башкаларга карата игътибарлы, ярдәмчел’ төшенчәсенең *рәхим, рәхимле* сүзләре белән бирелгән очраклары да еш күзәтелә: *Дүртенче уғлы Тулины халықлары* ***рәхимледер*** *дийеб, эше қаты, ашы татлы, таймас олуғ йортдыр дийеб, Мускау урдасына ханлықға қуйды* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 81].

Аеруча М. Колый, суфи шагыйрь буларак, кешеләрне шәфкатьле булырга, «рәхимлек қылырга» чакыра: ***Рәхим қылыб****, шайәт бер сүз әйткәй мәңа* [Мәүлә Колый, б. 495]; ***Рәхим кылмаз****, башын қуйса печәр ирде* [Мәүлә Колый, б. 492].

*Рәхимле* мәгънәсенең капма-каршысы булган ‘начар, әшәке, үтә явыз’ кебек төшенчәләрне язма чыганакларда *залим* сүзе ачыклый: *Түрәмез көч қылды****, залим булды****, чыдамадық, посдық, – диделәр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 72].

*Залим шаһ* сүзтезмәсендә явызлык, мәрхәмәтсезлек, шәфкатьсезлек, каты күңеллелек аеруча көчле чагылыш таба: *Бәни Харҗәм дидеге бер* ***залим шаһ*** *Хәбәш дийарында хоруҗ итде, та ки хәзрәте Исмәғыйльнең йирене алыр өчен* [Мөслими, б. 14].

*Яхшы – яман.* Антонимик мөнәсәбәттә торучы әлеге төшенчәләрне язма чыганакларда түбәндәге лексик берәмлекләр җиткерә: *йахшы, ғайәт йахшы, йахшы дәлилле, йахшылығ қылу; йаман, йаманлық, йаманлық қылу, йаманлау, йаман хәбәр, йаман қырғын; хурлау*; *асыл, асыл зат халык* һ.б.

Кешеләргә яманлык эшләп, зыян салып йөрүчеләр дә автор игътибарыннан читтә калмый. Кешенең үзен яисә эшен гомумән уңай яктан бәяләргә кирәк булганда, *йахшы* сүзе иркен кулланыла: *Хөрмәтләрен **йахшы қылыб** йөрмәк кәрәк* [Мәүлә Колый, б. 491]; *Бу миндин туған өч уғыл – Бүдән Чар, Қағыйн Чар, Салчут – болар йорт тотмаға **йахшы ирмәсләрдер*** [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 71].

*Гайәт* сүзе белән янәшә килгән очракта *йахшы* лексемасы намуслы, кешелекле, тәрбияле, тәртипле һ.б. шундый уңай сыйфатларга ия кешенең әйбәт якларын тагын да күпертеп, гомумиләштереп күрсәтә: *Чыңғызны **гайәт йахшы хан** тиб, ханның җенесе баласы дийеб мақтадылар* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 74].

*Йахшы дәлилле сүз* сүзтезмәсендә *йахшы* лексемасы кешенең яхшы күңелле, акыллы-зирәк булуын бәяли: *Һай, имде синең шул **йахшы дәлилле сүзең** өчен тәқый синең диңгез күк күңелең өчен йөз мең үлемдин азад булсын, – тиде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 83].

Түбәндәге мисалда антонимик мөнәсәбәттә торган *йахшылық, йаманлық* лексемалары сүзтезмә рәвешендә кулланылган. Бу очракта инде алар кешенең эчке сыйфатларын гына белдереп калмый, ә капма-каршы мәгънәгә ия әдәп-әхлак категорияләренә әверелә: *Анда Ақсақ Тимер әйде: «Син ғафил дәгелсең, мин ғафил мен, син үзеңә **йаманлық қылғайсың**, мин үземгә **йахшылық қылғаймын**», – тиде, башын кисде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 83].

*Йахшы* сүзенең синонимы буларак *хуш* сүзе дә очрый, ул башлыча геройның эш-хәрәкәтен бәяләгәндә кулланылган: *Чыңғыз хан килеб, арбаны қарады, хуш қылыбсың, тийеб, Қалдар бине мақтады* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 76].

Аеруча яхшы сыйфатларга гына түгел, акыл, белем, кешелеклелек ягыннан абруйлы саналган дәрәҗәле, хөрмәтле кешеләргә карата *асыл* сыйфаты кулланылган. Мәсәлән, *асыл зат халык* сүзтезмәсенә килгәндә дә *асыл* сүзе кешеләрнең ихтирамга лаек уңай сыйфатларын гына түгел, ә халык буларак тарих аренасында ихтирам казануын, затлы милләттән булуын ассызыклый: *Өченче уғлы Гәрәйне ир кийәр сауты ир қушаныр, қылычы күбдер дийеб, **асыл зат халық** дийеб, Курал урдасына ханлықға қуйды* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 81].

*Йахшы* сүзенең антонимик пары, затка, вакыйга-күренешкә, әйберләргә начар яктан бәя бирә, күпмедер дәрәҗәдә авыр хискичерешләрне дә аңлата торган лексемаларга *йаман, ачы* сүзләрен мисалга китерергә мөмкин. Мәсәлән, түбәндәге очракта начар сыйфатларга ия кеше күздә тотыла: *Бу җиһандин туғмады мәндин **йаман*** [Мәүлә Колый, б. 488].

«Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәрендә *йаман* лексемасы ‘коточкыч, үтә ачы, үтә начар’ кебек мәгънә төсмерләре белән баетыла. Мәсәлән, түбәндәге мисалда без аны *йаман қырғын* сүзтемәсендә, ягъни ‘коточкыч каты сугыш-орыш’ дигән төшенчәдә очратабыз: *Ул ачыйғлығ **йаман қыргында** халық уғлы бонларның қадерен белмәсләр, үлтерер-*

*ләр, бонларның нәселе-ыруғы китмәсен тийеб алыб қалдым, – тиде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, б. 77].

Ә инде *ʿгайәт йахшыʾ* төшенчәсенең капма-каршысы булган, ягъни тулаем юньсез кеше образын бирергә теләгән лексик берәмлекләрдән гарәп алынмасы *мәлғунь* сүзе кулланылуын искәртергә кирәк. Бу лексик берәмлек ләгънәтле, начар, әшәке, мордар, явыз кебек сыйфатларга ия образны атый: *Унбишенче көн Әберһә **мәлғунь** Кәғбәи Мөкәррәмәне йақмаға килде* [Мөслими, б. 12].

Шул рәвешчә, XVII – XVIII гасыр язма истәлекләрендә кешенең холкын белдерә торган төшенчәләр шактый актив кулланылган. Аларның барысының да диярлек антонимик мөнәсәбәттә торучы парлары булуы ачыкланды. Капма-каршы мәгънәгә ия әлеге төшенчәләрнең байтагы үз эчендә синонимик рәт тәшкил итүе дә мисалларда ачык чагылыш таба. Фактик материалдан күренгәнчә, кешегә хас рухи һәм физик сыйфатларны чагылдыра торган әлеге төшенчәләрне белдерү өчен, язма чыганакларда *гакыллы* һәм *гакылсыз*, *дәрманлы* һәм *дәрмансыз* кебек бер тамырдан ясалган, яки *яхшы* һәм *яман*, *рәхимле* һәм *залим* кебек төрле тамырдагы лексик берәмлекләргә нигезләнгән антоним сүзләр кулланыла. Шулай ук капма-каршы мәгънәдәге лексик байлыкны куллану, кешенең уңай сыйфатларына басым ясап, аларны күпертеп сурәтләү аеруча суфи шагыйрь Мәүлә Колый иҗатында киң кулланылуы ачыкланды. Гомумән, кешене рухи яктан уңай бәяли торган лексик берәмлекләрдә аерым шәхеснең генә түгел, ә халкыбызга хас уңай милли сыйфатлар да чагылыш табуын искәртергә кирәк.

### Әдәбият

*Әхәтов Г.Х.* Татар телендә антонимнар // Совет мәктәбе. 1977. № 2. Б. 38–39.

*Бәширова И.Б.* Татар әдәби теле. Семасиология. Казан, 2010. 532 б.

*Булаховский Л.А.* Введение в языкознание. М.: Учпедиз, 1953. 177 с.

Дәфтәре Чыңгызнамә // Мирастан биш сәхифә: XVII – XIX гасырлар әдәби-тарихи ядкярләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 38–96.

*Закирова Р. М.* Антонимы в татарском языке: Лексико-грамматические, семантические и стилистические особенности употребления: автореф. дис. ... канд. филол. наук: 10.02.02. Казань, 2001. 21 с.

*Насыйри К.* Әнмүзәҗ. Казан, 1975. 213 б.

Мәҗмүгъ әл-хикәят // Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Б. 503–522.

Мәүлә Колый шигырьләре // Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. китап. нәшр., 1963. Б. 487–503.

*Мөслими.* Тәварихы Болгария / Басмага әзерләүче С. Гыйләҗетдинов. Казан: Иман, 1999. 100 б.

*Реформатский А.А.* Введение в языкознание. М.: Просвещение, 1967. 533 с.

*Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен). Казан: Хәтер, 1999. 288 б.

Татар лексикологиясе: 3 томда. 1 т. Казан: ТӘһСИ, 2015. 352 б.

Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. 2 т. Казан: Мәгариф, 2009. 343 б.

*Хайруллин М.Б.* Проблемы развития лексической системы татарского литературного языка. Казань: Фикер, 2000. 202 с.

*Ханбикова Ш.С.* Сүздәге антонимик мәгънәләр // Лексика и стилистика татарского языка. Казань, 1981. Б. 3–6.

*Шанский Н.М.* Современный русский язык: Лексика. М., 1977. 335 с.

***Вәлиева Миләүшә Зәки кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145’367

***Л.Г. Хәбибуллина***

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ УРТА ДИАЛЕКТЫ МИНЗӘЛӘ СӨЙЛӘШЕНЕҢ СИНТАКСИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ
## (Татарстан Республикасының Актаныш районына үткәрелгән фәнни экспедиция материаллары нигезендә)

Диалектные тексты, собранные на определенной территории, являются основным материалом в изучении народной традиционной культуры. В данной статье исследованы некоторые синтаксические особенности обрядовых текстов на материале мензелинского говора среднего диалекта татарского языка.

Основное отличие диалектного синтаксиса от синтаксиса литературного языка – в структуре предложения, в изменении порядка слов.

**Ключевые слова:** диалектный синтаксис, мензелинский говор, средний диалект, татарский язык.

Dialect texts collected in a certain territory are the main material in the study of folk traditional culture. This article examines some syntactic features of ritual texts based on the material of the Menzelinsky subdialect of the middle dialect of Tatar language.

The main difference between dialect syntax and the syntax of a literary language is in the structure of a sentence, in changing the order of words.

**Keywords:** dialect syntax, Menzelinsky subdialect, middle dialect, Tatar language.

Диалекталь текстлар халыкның рухи культурасын өйрәнүдә төп материал булып тора. Диалектларда җанлы сөйләм теленең синтаксик үзенчәлекләре чагыла. Татар теленең диалекталь лексика, фонетика һәм морфологиясен өйрәнүгә шактый игътибар ителә, ә диалекталь синтаксис лингвистика фәненең азрак өйрәнелгән өлкәсе булып кала бирә.

Әлеге мәкаләдә Татарстан Республикасының Актаныш районы территориясендә татар теленең урта диалекты минзәлә сөйләшенең кайбер синтаксик үзенчәлекләре өйрәнелә. Анализ өчен фактик материал «Милли-мәдәни мирасыбыз: Актаныш» (Казан, 2010) хезмәтеннән алынды. Бу басма – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты татарлар яшәгән төбәкләргә үткәргән комплекслы экспедиция материаллары буенча язылган «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясенә караган беренче китап.

Диалекталь синтаксисның әдәби тел синтаксисыннан төп аермасы җөмлә структурасы белән бәйле һәм сүз тәртибенең үзгәрүендә чагыла. Татар диалектларының синтаксик үзенчәлекләре бертөрле һәм, кагыйдә буларак, хәбәрлек кушымчасы саклану, беренче төр изафә куллану, тезмә кушма җөмләләрнең күбрәк булуы, сорау кушымчасының хәбәрлек кушымчасы алдыннан кулланылуы белән характерлана [Сафиуллина, с. 67].

Диалекталь текстларны анализлаудан күренгәнчә, рухи культура лексикасына караган терминнарның күбесе синтаксик ысул белән – ике яки берничә нигез кушылып ясала. Төрки телләрдә иң борынгы сүз ясагыч чаралардан саналган беренче төр изафәгә караган тезмәләр аеруча актив кулланыла.

Телче-галимнәр билгеләгәнчә, «шунысы игътибарга лаек: сөйләшнең яки диалектның синтаксик архаиклыгының иң төгәл күрсәткече булып нәкъ менә беренче төр изафә тора» [Сафиуллина, с. 68]. Фактик материалны анализлаудан күренгәнчә, Актаныш территориясендәге сөйләштә дә мондый мисаллар шактый еш очрый. Мәсәлән: *Беd ике баланы да* ***тал бишектә*** *үстердек.* ***Тал бишек*** *үрүчеләр күп булды; Ақлашқан чағында қыd анасы айақ сөрткече,* ***бит җаулық****, намаdлық биреп җибәрә ақлашу бүләгенә; Ике йағы чигелгән булса, йәш қодаларға,* ***кийәү җегетләргә*** *бирерләр ийе җанчықны; Сәкегә тезелеп утырып, йөзлек қырыйына эскәмийәгә йә бүкәнгә утырып, зур* ***ағач табақтан*** *ун кеше буламы, җиде кеше буламы, шулай ашыйлар ыйы қашық белән; Бәбәй туғанда аwылда бер ataқлы* ***кендек әби*** *булыр ыйы.*

Мисаллардан күренгәнчә, Актаныш территориясендәге минзәлә сөйләшендә хәбәрлек кушымчалары исем хәбәрләргә дә ялгана. Мәсәлән: *Бер генә баламын.*

Иярүче кисәкнең ияртүче кисәктән соң килүе, ягъни кире сүз тәртибе шактый еш күзәтелә. Мәсәлән: *Йегетләр утын китерәләр, кешеләрнең читәннәрен, қоймаларын сүтеп; Иртәнге сәғәт икегә, өчкә чақлы шулай уйнап утыра торған ыйық җоқламайчы; Бер wақыт йегетләрне кертмәдек аулағиға; Урлыйлар бәлешне; Беd қул белән урдық урақны; Қазан тәкәсе дип wақ қына итеп пешерәләр ийе киндер орлығы салып; Wақ бәлеш пешерделәр қодағыйларға иртәнге чәйгә.*

Мисалларны анализлау күрсәткәнчә, сорау җөмләләр әдәби телдәге кебек формалаштырыла. Мәсәлән: *Суққан әйберләре, өшәнчекләре бармы суң?*

Гади җөмлә төзелешендә шундый үзенчәлек күзәтелә: җөмлә башындагы сүз яки аны алыштыра торган алмашлык җөмләнең азагында да кабатланып килә. Мәсәлән: *Иркә күлендә гел балық тоталар анда; Қалморза қутыры җул чаты ул; Бикә җийыны иң аdақы җийын ул; Баwырсақны балға шикәр қушып қайнатып бутыйсың аны.*

Академик хезмәтләрдә билгеләнгәнчә, «кушма җөмләләрнең төрләре, аларның компонентларын үзара бәйләгеч чараларның составы ягыннан сөйләшләр, нигездә, әдәби телдән аерылмый» [Татар лексикологиясе, б. 152].

Минзәлә сөйләшенең кушма җөмлә системасында теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр киң кулланыла, әлеге күренеш, гомумән, сөйләм теле өчен хас. Мәсәлән: *Мин бер мең туғыd йөd илле сигеdенче йылны бардым, беd аның белән сүләшмәдек; Киленнең бидрәсекөйәнтәсе була, су җулы күрсәтәләр, туғаннары, дус қыdлары җыйылышып, уйнап-бийеп, барып қайталар шунда, суwын қуйып қунақларға чәй эчерәсең; Дүрт атна уdа, җийын бетә, эш башлана;*

*Миннән соң қалған ике килен җалан айақ та җөрдөләр, икесе дә уқытучылар иде, без инде қара кеше.*

Әдәби телдә, сүзләрнең туры тәртибе булганда, синтетик иярчен җөмлә кушма җөмләне тәмамлый алмый, баш җөмләгә карата препозициядә урнаша. Диалектларда исә инверсия еш күзәтелә: синтетик иярчен җөмлә постпозициядә килә. Мәсәлән: *Қапқаны балалар ача қыd төшкәндә; Бер мең сигеd йөd сиксән икенче йылны монда күчкәннәр су басқанға; Эпи башлаталар, бал-май қаптыралар хәdер, тәмне телле булсын дип; Күкәйне, әйбер утыртқанда, җиргә чәчеп җибәргәннәр, уңыш булсын дип; Халық төрлөчә қыланған инде, тормош имин булсын дип; Миннегөл, Миннебай, Миннеқамал исемнәре қушалар ыйы баланың миңе булса; Нықлы була инде Тимер иseме қушсалар.*

Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, иярчен җөмлә төрләренең иң борынгыларыннан берсе дип шарт җөмләләр санала. Шарт наклонениесенең борынгы формасы булган *-сар*/*-сäр* аффиксы борынгы төрки язма истәлекләрдә үк кулланыла [Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков, с. 215].

Актаныш районы территориясендә җыелган диалекталь текстларны анализлаудан күренгәнчә, иярчен шарт җөмләле кушма җөмләләр актив кулланыла. Аларда шарт мөнәсәбәтенең төп квалификаторы буларак *-са*/*-сә* кушымчасы була. Мәсәлән: *Қызын бирергә риза булса, никах көнен билгеләп қайтқаннар; Күәстә ипи қабарып менсә, тизерәк шишәрә әвәлисең, ипийең беткән булса. Күәс төбендә қамырың қалса, тағын мич қырыйына тығасың инде сыйса; Қыdым, ипи салған көнне кеше керсә, чәй эчерми чығарма; Көн қойашлы булса, кичкә кибеп тә чығадыр ыйы; Баланың миңе булса, җүшкәдән қашық төшереп исем қушалар ыйы.*

*-са*/*-сә* шарт формалы җөмләләрдә еш кына шарт һәм вакыт мәгънәләренең синкретизмы күзәтелә. Бу очракта фраза үзе вакытка бәйле түгел, гомуми закончалык формасында була, типик күренешләргә ишарәли. Мондый мисалларда вакыт мәгънәсе даимилекне күрсәтә. Мәсәлән: *Аулағ өй булса, күгәрчен очорошлы уйнай торған ыйық; Бала-чаға чирләсә, қайссы әбидән өшкөрткәннәр; Қоролық булса, соңғы күмелгән мәйет қаберенә су салығыd; Қарға ботқасына чығалар беddә қоролыққа китсә; Қыш көне булса, чанада киләләр атлар белән, җәй көне булса, арбада киләләр инде, қыңғыраулы атлар белән киләләр; Алар мунчаға барса, мунча битҗаулығы эләләр ийе киленнәр.*

Шулай итеп, шарт мөнәсәбәтләреннән аермалы буларак, шарт-вакыт мәгънәле конструкцияләрдә вакыйгалар үтәлешенең билгеле бер шартлары тасвирлана.

Мисалларны анализлаудан күренгәнчә, теркәгеч мәгънәсендәге *исә* кисәкчәсе билгеле үткән заман хикәя фигыльгә кушылып килә һәм шарт мөнәсәбәтен белдерә. Мәсәлән: *Ақчаң **булдисә** аласың; Ашағыd, **йараттығыd исә**; Доға уқып алырға диләр суны беренче алғанда, **шикләнмәдисәң** су тотмай; Кәзәкәй басуда была торған ийе, ирнеңе боdа, тигеdмәй генә ашайсың, сақланыб **ашамадисә** иренне боdа.*

Актаныш территориясендәге минзәлә сөйләшендә шарт мөнәсәбәте *икән* сүзе ярдәмендә дә белдерелә. Мәсәлән: *Менә биш тәрәзә була* ***икән****, биш тәрәзәгә дә биш қызыл башлы сөлге элә; Тәбикмәкне бодай оны белән кичтән изәсең* ***икән****, ул иртәнгә ачый.*

Өйрәнелә торган сөйләш текстларында, иярчен максат җөмләне баш җөмләгә бәйләп, *өчен* бәйлеге урынына *күрә* бәйлеге кулланыла ала. Мәсәлән: *Қарама қайырысыннан чабата җасайлар, су үтмәскә* ***күрә*** *төбөнә қайын тузы салалар*.

Актаныш территориясендәге минзәлә сөйләшендә аналитик иярченле кушма җөмләләр дә кулланыла. Гадәттә, аларның компонентлары парлы мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән: *Алар* ***нәмәкәй*** *әйтә,* ***шуңа*** *ыриза;* ***Кем*** *қыйурақ,* ***шул*** *килен суwы сатыб утыра;* ***Кем*** *башлый чәкчәкне,* ***шул*** *ала ул бүләкне; Суга* ***кем*** *килә,* ***шул*** *алып китә; Бийанай* ***нәмә*** *қушса,* ***шуны*** *эшләп йөреш ийе;* ***Кем*** *ача,* ***шул*** *бүләк әйтә.*

Синтетик иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче *-мы* сорау кисәкчәсе диалектларда ия составында килә ала. Мәсәлән: *Магнит****мы*** *бар, җаумай җаңгыр.*

*-мы* сорау кисәкчәсе гади җөмләдә дә иягә ялгана ала. Мәсәлән: *Бүләк тигән урман****мы*** *булган шунда.*

Шулай итеп, диалекталь текстлар халыкның традицион культурасын өйрәнүдә төп материал булып тора. Татарстан Республикасының Актаныш районы территориясендәге минзәлә сөйләшенең синтаксик үзенчәлекләрен фәнни анализлау күрсәткәнчә, алар әдәби телдәгедән беркадәр аерымланган булсалар да, нигездә, уртак элементларны саклыйлар.

**Әдәбият**


Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков / под общ. ред. Н.К. Дмитриева и др. М.: Изд-во АН СССР, 1961. 232 с.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Актаныш. Казан, 2010. 415 б. («Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе. Беренче китап).

*Сафиуллина Ф.С.* О диалектном синтаксисе (на материале диалектов татарского языка) // Советская тюркология. 1978. № 4. С. 63–71.

Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. һәм автор М.З. Зәкиев. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2017. III т. 536 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 392 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге: якынча 40000 берәмлек / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. 839 б.

Татар халык сөйләшләре: Ике китапта: Беренче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. Казан: Мәгариф, 2008. 463 б.



***Хәбибуллина Лениза Газинур кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының диалектология һәм лексикология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***И.З. Гарипова,***
***Э.Н. Денмөхәммәтова***

# ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘР АША КЕШЕГӘ БӘЯ БИРҮ

В современной науке антропоцентрическая парадигма лежит на основе многих лигвистических исследований. Изучение личности через собственную речь или по характеристикам, представленными другими людьми, как в письменной, так и в устной форме является одним из актуальных направлений современного языкознания. Описание и оценка внешности человека, его деяния, намерения и др. можно увидеть и в фразеологических единицах языка, которые закрепились в нем как устойчивые характеристики в виде словосочетаний. В татарских фразеологических единицах можно найти как положительную, так и отрицательную оценку народа на те или иные действия. В данной работе рассматриваются и анализируются такие иносказательные единицы татарской речи, зафиксированные в фразеологических словарях.

**Ключевые слова**: фразеологизмы, положительный оттенк, отрицательный оттенк, оценивание, татарский язык, антропоцентризм.

In modern science the anthropocentric paradigm underlies many linguistic studies. The study of a person through his speech or by describing someone else, both in writing and orally is one of the topical areas of modern linguistics. The description and evaluation of a person's appearance, his actions, intentions, etc. can also be seen in the phraseological units of the language which are fixed in it as stable phrases. In Tatar phraseological units one can find both positive and negative assessments of the people for certain actions. In this paper such allegorical units of Tatar speech are considered and analyzed.

**Keywords**: phraseological units, positive connotation, negative connotation, evaluation, Tatar language, anthropocentrism.

Хәзерге вакытта тел белемендә, төп тикшеренү юнәлешләренең берсе буларак, һәр яңалыкта кеше феноменын үзәккә алып карау һәм һәр нәрсәне кешегә бәйле рәвештә өйрәнү процессы бара. Тел белемен антропологик принциплар нигезендә өйрәнү идеясе яңа булмаса да, күренекле немец галиме Вилгельм фон Гумбольдттан соң [Гумбольдт, 1985, с. 234], бу юнәлештә кыю эшчәнлек XX гасырның соңгы чирегендә генә алып барыла башлый. В.М. Алпатовның «Телгә антропоцентрик һәм системацентрик яклардан якын килү» хезмәтендә кешене үзәккә куеп тикшерү алымының тарихи яктан нигезле һәм төпле булуы ассызыклана. Тикшерүче тел үзенчәлекләрен аның иҗатчысына хас үзлекләр аша өйрәнү, аңлау һәм тасвирлауның уңышлы булуы турында әйтә. Телне өйрәнүгә багышланган һәр тикшеренү эше дә антропоцентрик алымга нигезләнә, бары тик кайвакыт интуициягә нигезләнгән анализны, ә кайчак катгый ысулларга нигезләнгәнен аерып, дөрес куллану зарурлыгы турында яза [Алпатов, 1993, с. 15–21].

Кеше (индивид) башкалар белән аралашу нәтиҗәсендә җәмгыятьтә генә яши ала һәм күптөрле вазифалар башкара. Шулар арасында берсе – бәяләү вазифасы. Ул үзен, гамәлләрен, әйләнә-тирә мохитне, тирә-юньне, танып белү процессын һ.б.ларны бәяли, чөнки ул һәрнәрсәне сизә, тоя, күрә, татып карый ала һәм һәрнәрсә белән актив рәвештә кызыксына.

Бәяләү – лингвистикадагы иң мөһим категорияләрнең берсе. Ул тискәре, уңай яки нейтраль була ала. Һәрбер телдә мондый системалар үзенчәлекле, чөнки һәр халыкның кыйммәтләр төшенчәсе үзгә. Бу кыйммәтләр, гасырлар дәвамында формалашып, халыкның менталитетында саклананалар, система буларак яшиләр. Төрле объектларга һәм күренешләргә, эш-гамәлләргә шулардан чыгып бәя бирелә. Төрле милләт вәкилләренең мәдәни үзенчәлекләре төрле булган кебек, бәяләү критерийлары да төрле була. Әмма «уңай» һәм «тискәре» бәяләрнең һәр халыкта да, мәдәнияттә дә барлыгы мәгълүм. Шунлыктан мондый бәяләрне һәр мәдәният өчен кулланып була.

Кеше аңында дөнья образы лингвистик универсалияләр җыелмасы һәм милли аңны чагылдырган лингвистик билгеләрнең тасвирланышы аша барлыкка килә. Дөньяның милли-лингвистик сурәтендә объектив дөнья да, җәмгыять әгъзаларының аңа карата субъектив мөнәсәбәте дә чагылыш таба. Семантик универсалияләр җыелмасының аерылгысыз компоненты булып *яхшы / начар* бәяләү төшенчәләре санала. Л.Б. Никитина фикеренчә, «һәр кешенең аң эшчәнлеге һәм дөньяны танып белү дәрәҗәсе һәрнәрсәне бәяләү процессы аша башкарыла. Бәяләү сәләте организмның яшәү урынына туры килү дәрәҗәсен билгели. Бәяләү эшчәнлеге сәләте һәр тере организмга бирелгән, һәм бу сәләт чынбарлыкны чагыштырулар аша кабул итәргә ярдәм итә, дип әйтә алабыз» [Никитина, 2003, с. 6].

Бәяләү системасын булдыруда татар тел белемендә тотрыклы сүзтезмәләр дә катнаша. Алар ярдәмендә кинаяләп әйтелгән уңай яки тискәре бәя гади сүзләр белән белдерелгәнгә караганда күпкә үтемлерәк һәм көчлерәк яңгырый.

Татар фразеологизмнарының фәнни яктан тирәнтен өйрәнелүе тел белемендә яхшы билгеле. Элек Л. Җәләй, Ш. Рамазанов, Л. Мәхмүтова, Н. Борһанова, Г. Ахунҗанов, Х. Курбатов, Г. Әхәтов, Н. Исәнбәт, Х. Мәхмүтов, Ф. Сафиуллина, Р. Йосыпов, Л. Бәйрәмова, һ.б.лар тарафыннан фәнни тикшерелгән тотрыклы сүзтезмәләр бүген дә эзләнү объекты булудан туктамый, чөнки Г. Әхәтов, Н. Исәнбәт, Ф. Сафиуллина тарафыннан төрле сүзлекләргә туплап бирелгән фразеологик берәмлекләр кеше феноменын төрле яклап ачыклауга ярдәм итәләр.

Мәгълүм булганча, фразеологик берәмлекләр белән кызыксыну күптән башлана, мондый сүзтезмәләр әдәбият белемендә поэтика элементлары буларак, лексикологиядә – идиомалар, фольклор текстларында сынландыру, гипербола яки литота составында да һ.б. өйрәнеләләр. Бу очракта барлык тармакларны да фразеологизмнарның бәя

бирү мөмкинлеге кызыксындыра. Бәя бирү – тотрыклы сүзтезмәләрнең иң мөһим максатларының берсе. Еш кына фразеологизмнарны семантик яктан шушы үзенчәлегенә нигезләнеп төркемлиләр.

Кеше, аның тәҗрибәсе һәм белеме һәр фразеологик берәмлекнең үзәгендә тора. Ул әйләнә-тирәдәге предметлар дөньясын кешеләр белән чагыштыра, эш-гамәлләр һәм кешеләрнең сыйфатлары белән тиңли.

Татар телендә кулланылган фразеологик берәмлекләр арасында кеше тормышына караганнары аеруча еш очрый. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, татар теленең фразеологик берәмлекләренең күбесе «Кеше» макрогруппасына карый, ягъни алар кешенең гамәлләрен һәм хисләрен сурәтләү өчен файдаланылалар. Мәсәлән: *коеп куйган* – кешенең тышкы кыяфәте охшашлыгы турында, *күз төшерү* – карап алу; *башы күккә тия* – шатлыкның чиксез булуы; *чәчләр үрә тору* – шаккату, гаҗәпләнү; *баш вату* – уйлану; *талканы коры калу* – алдану һ.б.

Кешегә бәя бирүдә аның характерын билгеләү төп күрсәткеч булып тора, чөнки һәр кеше гамәлләрен төрлечә кыла. Шуннан соң алар башкаларның бәяләү предметына әверелә. Татар телендәге тотрыклы сүзтезмәләрне дә берничә төркемчәгә аерырга мөмкин: 1) кеше характерының тискәре сыйфатларын күрсәтүче фразеологик берәмлекләр; 2) кеше характерының уңай сыйфатларын белдерүче фразеологик берәмлекләр; 3) кеше характерына нейтраль бәя бирүче фразеологик берәмлекләр.

Шунысы хак: күп халыкларда шәхескә кагылышлы кайбер сыйфатлар бер үк төрле бәяләнә. Еш кына икейөзлелек, ахмаклык, эшсезлек, ялкаулык, саранлык һ.б. кебек сыйфатлар һәр халыкта да тәнкыйтьләнә. Үлемгә сәбәпче булган сыйфат һәм гамәлләр гөнаһ буларак дөнья диннәре тарафыннан да тыела һәм кире кагыла.

Татар телендә кешегә уңай бәяне белдергән фразеологик әйтелмәләр арасында кеше һәм аның тән әгъзалары атамалары белән белдерелгәннәре шактый: а) кешенең тышкы кыяфәте, ә) холкы, б) эш-гамәлләре. Моннан тыш, татар халкында дуслыкка тугрылык, итагатьлелек, белемлелек һәм профессиональ эшчәнлекнең күпкырлылыгы югары һәм уңай бәяләнә.

*Тышкы кыяфәтне бәяләү аспектлары* түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

*1. Эмоциональ аспект* милли мәдәниятнең чагылышы һәм кешенең милли сәнгать образы булган тышкы кыяфәт стандартларына туры килә.

*2. Психологик аспект* кешене бәяләүдә тышкы һәм эчке бәйләнешне чагылдыра, психофизик, психо-эмоциональ, психик, интеллектуаль үзенчәлекләр һәм шәхес сыйфатларының тышкы күренешләрен танырга омтылыштан гыйбарәт.

*3. Иҗтимагый аспект* тышкы кыяфәтне бәяләүнең бер төренә карый. Ул типиклаштырылган кеше образларыннан гыйбарәт. Типиклаштыру төрле социаль катламнарга, профессиональ төркемнәргә, аның этикет формаларына бәйле була.

*4. Яшь аспекты* кешенең физик һәм психо-эмоциональ халәтләрен чагылдырган, гомернең билгеле бер периодына тәңгәл тышкы кыяфәттәге үзгәрешләрне бәяләүгә туры килә. Алар җәмгыятьтә булган әхлакый һәм этик нормалар, теге яки бу халыкның чит кешеләргә мөнәсәбәте, традицияләре, кеше тормышының кыйммәтен аңлау кебек критерийларны үз эченә алалар. Шулай ук сабыйлык, балачак, яшьлек, өлкәнлек, картлыкка туры килә торган үзенчәлекле бәяләү чорларына бүленәләр. Тышкы кыяфәткә бәя бирү төрле тасвирлаулар аша башкарыла, үзара бәйләнгән һәм/яки бөтенләй үзгә функциональ компонентлар, үзенчәлекләр, сыйфатлар, характеристика нигезендә төзелә.

Татар фразеологизмнары арасында кешенең тышкы кыяфәтенә уңай бәя бирә торган берәмлекләр дип түбәндәгеләрне аерып күрсәтергә мөмкин: *агызмаган бал, алтын кеше, асыл зат, асыл кеше, ата баласы, газиз баш, халык улы, менә дигән.* Алар хатын-кызга карата әйтеләләр, ир-атны сыйфатлаганда да кулланыла алалар.

Чибәр, матур кеше турында *ай дисәң авызы, көн дисәң күзе, алма бит; бер бите ай, бер бите кояш; бер кашык суга сал да йот; асыл кош; йөзе кояш булу; йөзе якты, бите ачык; керфегеннән гөл тамар; кура җиләге күк; нәзкәй бил; нечкә бил; эшкә батыр, төскә матур; тал чыбыгы кебек; угата чибәр; хур кызы* диләр. Буе озын, гәүдәсе таза булган ир-ат турында сөйләгәндә *алып кадәр* тасвирлавы кулланыла.

Ачык йөзле, киң күңелле кеше турында *ачык чырайлы*, *ачык күзле, йөзе ак булу; якты чырайлы; судан пакь, сөттән ак; сөттән ак, судан пакь; сөттән ак, чынаяктан пакь* фразеологизмнары кулланыла.

*Бал авыз* – әйтәсе сүзен матур итеп оештыра белгән, тәмле телле кеше турында сөйләгәндә әйтелә.

Татар теленең фразеологик сүзлекләрендә урын алган берәмлекләрне тикшерү түбәндәге нәтиҗәләрне бирде: сүзлекләрдә кешенең тышкы кыяфәтенә уңай бәя бирү компоненты булган 69 фразеологик берәмлек аерып каралды. Алар арасында 32 се – оригиналь фразеологизм, 37 се – бу фразеологик берәмлекләрнең синонимнары буларак билгеләнде. Анализ күрсәткәнчә, тышкы кыяфәткә бәя бирү семантикасы булган фразеологизмнар татар телендә, нигездә, соматизмнардан гыйбарәт. Бу аңлашыла да, чөнки соматизмнар кешенең тән әгъзалары, ягъни тышкы кыяфәтен билгеләүче сүзләрне тәшкил итә.

Семантик яктан караганда, татар телендә кешенең тышкы кыяфәтенә уңай бәя бирелгән фразеологизмнарда татар милли үзаңына хас кеше эталоны тудырыла. Ул түбәндәге сыйфатларга ия зат: физик яктан көчле, чибәр, зифа буйлы, нечкә билле, якты йөзле, кара кашлы, кара күзле, сөйкемле. Шунысы игътибарга лаек: кешенең тышкы кыяфәтенә уңай бәя биргән фразеологизмнар арасында гендерлык принцибы ачык күренә. Хатын-кызларның тышкы кыяфәтендә күбрәк зифа буй, нечкә бил, кара каш, кара күз, якты йөз кебек

сыйфатлар югары бәяләнсә, ир-атларның күбрәк физик ныклыгына (көченә) игътибар бирелә. Моннан чыгып, кешенең тышкы кыяфәтен бәяләүдә иҗтимагый аспект калку чагыла дип әйтә алабыз. Тышкы кыяфәткә югары бәя биргән татар фразеологизмнарында психологик аспект та зур роль уйный. Бу аспект тел / күз кебек лексемалар кергән соматизмлы фразеологизмнарда күренә. Татар кешесе әйтәсе сүзен матур итеп оештыра белгән, җор телле һәм күзне шатландыра алырлык кешеләрне матур дип саный. Фразеологизмнарда яшь аспектының чикләре билгеләнми. Димәк, татар менталитетында матурлык яшь белән турыдан-туры бәйләнештә бәяләнми, ә киресенчә, кешенең тышкы кыяфәте аның холкына йогынты ясавына игътибар ителә. Татарлар рәхимле, игелекле, эчкерсез кешеләрне югары бәялиләр, дуслык, тәҗрибәлелекне өстен күрәләр. Җаваплы, кызганучан, юмарт кеше турында *киң күңелле; алтын йөрәкле, олы йөрәкле (җанлы), изге җан, керсез йөрәк* фразеологизмнарын кулланып сөйлиләр.

Тәвәккәл, көчле характерлы, ышаныч белдергән кешеләрне *имәндәй нык, төпле фикерле, утта янмый, суда батмый* һ.б. фразеологизмнар аша тасвирлыйлар.

Көчлелекне бәяләгәндә *корычтай (тимер) нервлары, типсә (сукса) тимер өзәрлек, басса бакыр өзәрдәй, сукса, тугыз көн чумар ашамассың; сукса, чумарыңны чыгарыр* һ.б., ә тырышлык, уңганлыкны хуплаганда *кулы кулга йокмый, җир җимертеп (эшли), җиң сызганып, җиренә җиткереп* эшли дип сөйлиләр.

Кешенең акыл һәм уңай характер үзенчәлекләрен мактаганда *авыздан чыгуга эләктереп ала, аек фикерле, акылы хәзинә, башлы кеше, башы йомры, гыйлем иясе, бер сүзе мең алтын* һ.б. берәмлекләрне кулланалар.

Күп сөйләшмәү, дәшми калу да татарларда хуплана. Моның өчен *телне тыю (артык сөйләнмәү, кысылмау, дәшмичә калу), телне теш артында тоту, телне йөгәнләү* фразеологизмнары файдаланыла.

Телебезнең кешегә һәм аның гамәлләренә уңай бәя бирә торган фразеологизмнарына күзәтү ясаганнан соң, татарларда тыйнаклык, сабырлык, эшчәнлек, гаделлек, җитезлек, эчкерсезлек кебек сыйфатларның югары бәяләнүе кабат расланды. Әлеге сыйфатлар татар культурасында кеше эталонына туры килә һәм халкыбызга хас үзгәрмәс сыйфатлар булып саклана килә.

Әмма фразеологизмнар аша кешегә тискәре бәя дә бирелә ала. Татар лингвомәдәниятендә чит кеше эшенә тыгылу, ялкаулык һәм комсызлык хөкем ителә, тупаслык һәм алдау күренешләре тискәре бәяләнә. Акылсыз, тиз кызып китүчән кешеләр үз-үзләрен тотышларын контрольдә тотмыйлар һәм еш кына башкаларга уңайсызлыклар китерәләр, шуңа күрә мондый сыйфатлар да начар дип бәяләнә.

Әлеге тикшеренү кысаларында кешегә тискәре бәя бирә торган 85 фразеологик берәмлек анализланды. Тикшерү барышында аларны 12 төркемгә бүлү мөмкинлеге табылды, чөнки акылсызлык, күп сөйләшү, ялкаулык, тәкәбберлек, әдәпсезлек (начарлык), ялагайлану

(бозыклык), усаллык, характерның сәерлеге (эксцентрика), мактану, икейөзлелек, саранлык, ямьсезлек кебек сыйфатларның татар фразеологизмнары аша тискәре бәяләнүе ачыкланды. Мәсәлән, күп сөйләүче, еш кына кеше сүзенә тыгылучыга *озын тел, теле сөяксез* дип әйтү, тәкәбберлекне белдергәндә, *кирәкле кишер яфрагы, олы кылану* сүзтезмәләрен куллану, икейөзле булу, алдауны күрсәткәндә, *күзгә төтен җибәрү, йомшак җәеп, катыга утырту* кебек фразеологизмнары булу билгеләнде. Саран кешеләргә карата *кулы үз ягына караган, туймас тамак, ач күз, ач күзле* дип әйтү, ялкауларга *трай тибү, түшәмгә төкереп яту, җиңен төшереп эшләү* һ.б. берәмлекләр аша тәнкыйть сүзләре җиткерү билгеле булды.

Шул рәвешле, тискәре эмоциональ-бәяләүле мөнәсәбәтне белдергән эмотив фразеологик берәмлекләрдә кешенең ялкаулык, тәкәбберлек, куркаклык, әдәпсезлек, саранлык кебек сыйфатлары тәнкыйтьләнә.

Гомумиләштереп әйткәндә, татар сөйләменә хас фразеологик берәмлекләрдә кеше шәхесе, аның холкы, эш-гамәлләре үзәк урынны алып тора һәм алар төрле яктан бәяләнә. Тотрыклы сүзтезмәләрдә бу бәя бирү ысуллары һәм формалары милли мифология, фольклор, күзаллаулар, ианулар аша формалашып, татар лингвомәдәниятенең бер өлешен тәшкил итәләр.

**Әдәбият**

*Алпатов В.М.* Об антропоцентричном и системоцентричном подходах к языку // Вопросы языкознания. 1993. № 3. С. 12–15.

*Әхәтов Г.Х.* Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 176 б.

*Гумбольдт Вильгельм фон.* Язык и философия культуры: [пер. с нем.] / сост. общ. ред. и вступ. ст. А.В. Гулыги, Г.В. Рамишвили. М.: Прогресс, 1985. 451 с.

*Исәнбәт Н.С.* Татар теленең фразеологик сүзлеге: ике томда. I т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 495 б.

*Исәнбәт Н.С.* Татар теленең фразеологик сүзлеге: ике томда. II т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 365 б.

*Никитина Л. Б.* Образ-концепт «homo sapiens» в русской языковой картине мира как объект антропоцентристской семантики: автореф. дис. … д-ра филол. наук. Омск, 2006. 23 с.

*Сафиуллина Ф.С.* Татарча-русча фразеологик сүзлек. Казан: Мәгариф, 2001. 199 б.

***Гарипова Илзия Зөфәр кызы,***
*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы магистры*

***Денмөхәммәтова Эльвира Николай кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының*
*гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты*

УДК 811.512.145

***Р.Г. Ханнанов***

# ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН СҮЗ СӘНГАТЕНДӘ ӘДӘБИ ТЕЛ НОРМАЛАРЫ: ГРАММАТИК БАШЛАНГЫЧ ҺӘМ ПРОБЛЕМАЛАР

В статье рассматриваются актуальные вопросы языка художественных произведений современных авторов, делаются выводы о часто допускаемых грамматических, стилистических и фактологических ошибках, определяются способы решения данной проблемы.

**Ключевые слова:** литературный язык; грамматические нормы татарского языка; значение (ценность) слова; литературный стиль; литературное редактирование и корректировка.

The article deals with topical issues of the language of works of art by modern authors, draws conclusions about frequently made grammatical, stylistic and factual mistakes and determines ways to solve this problem.

**Keywords:** literary language; grammatical norms of the Tatar language; the meaning (value) of the word; literary style; literary editing and proofreading.

Тел – тере организм. Ул һәрвакыт үсештә, үзгәрештә, хәрәкәттә. Матур әдәбият – телнең көзгесе. Без ничек сөйләшсәк, әсәрләрдәге геройлар да шулай сөйләшә. Әдәбият халыкның, милләтнең тормышын чагылдыра. Халык: «Хәрәкәттә – бәрәкәт», – ди. Туган телнең саулыгы, иминлеге милләтнең сәламәтлегенә бәйле. Милләт кай тарафка, ни рәвешле хәрәкәт итсә, үсешне дә шул яктан көтәргә кирәк. Төп максат – үсешкә илтә торган бурычларны дөрес билгеләү.

Теоремалар дәлиллисе юк. Халык язучысы Марсель Галиев тел организмында барган процессны гади генә аңлата: *Үз байлыгыннан үзе сыгылып торган тел тирәгенең эшчән тамырлары җир тирәнлегендәге чишмәләргә тоташкан да, яшәү сутын гасырлар төпкеленнән ала-ала, өскә, яктыга чөеп, һәммә яфрак-сүз кадеренә микъдарлап тараткан*[1].

Күрәбез ки, язма һәм сөйләм телебезнең сафлыгы хакында сүз йөрткәндә, *җир тирәнлегендәге чишмәләргә тоташкан эшчән тамырлар* турында онытмау зарур. Ягъни хәзинәбез бай, тиешлесен юллап ала белергә генә кирәк. Аеруча бүгенге әдәбиятны барлыкка китерүче каләм ияләренә. Кызганыч, юллау күп вакыт сарыф иткәнгәме, үзгә тел сүзләрен файдаланып юанучылар нур тизлеге белән көннән-көн арта бара.

[1] Мәкаләдә кулланылган барлык мисаллар «Казан утлары» журналыннан алынды. Сүзләрнең мәгънәсен аңлатканда «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977, 1979, 1981) файдаланылды.

Әдәби телгә хәрәкәтчәнлек, җанлылык өстәргә теләүдәнме – сүз сәнгатенә гади сөйләм лексикасы мулдан үтеп керде. Аеруча да чит телләрдән алынган кыска, яңгыравык, «ата торган» сүзләргә баеп барабыз. Алар матур әдәбиятны да шактый чуарлый. *Тәки* (так и) сүзе инде калыплашып урнашып килә, *кәнишне, зерә, жәлке*ләр әкренләп үз урынын дәгъвалый, *патамушты, тучны, пака-пака*лар чиратка тезелгән. Заманында оялып кына «ишек шакыган» *бит* (ведь) сүзенең безнеке түгеллеген хәтерләүче дә сирәктер бүген...

Шул рәвешле, туган телнең сүзләрен читкә тибәреп, башка халыклардан «әҗәткә» кәлимәләр җыябыз. Без моңа мохтаҗмы? Бәхәсле сорау.

*Утта тотылып, сандалда чүкелгәннән соң, үз телебезнең яңгырашына ягымлыланып күчкән* алынма сүзләргә ихтирам, олы хөрмәт белән якын килергә чакыра М. Галиев «Рух» поэмасында. Ә без шулай итәбез дә. Әби-бабайлар, телләрен сындыра-сындыра, аларны әйтергә юкка өйрәнгәнмени?!

Бөек шагыйрь Дәрдемәнд исә заманында болай ди: *Канча*[1] *тартсаң, и мөхәррир, сүзне чит тел сибенә, / Тел ясалмас, гәр туган сүз ятмаса үз ибенә.*

*Үз ибенә яткыручы,* әлбәттә – халык, чөнки тел берәр сүзне син яисә мин ялгыш әйтүдән генә бозылмый. Хак хөкемне халык чыгара. Һәм... вакыт. Шулай да начар гадәт җилем кебек бик тиз ябышкан заманда сак кылану, итәк-җиңнәрне җыеп йөрү мәслихәт.

Туган телдәге үз сүзләребезне, бигрәк тә аларның мәгънәләрен тәгаенләмәү очракларының ишәюе көн кадагында тора. Әдәби әсәрләрдә каләм ияләре еш бутаган синонимик рәтләрнең берсе *дәвер, чор, заман, вакыт, чак, мәл* исемнәре белән бәйле.

«Университетта (мәктәптә, мәдрәсәдә һ.б.) уку дәверендә», дип язуны гадәткә керттек. Кешегә карата әйтелгәнен баштан ук искәртеп куйыйк. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (алга таба – Сүзлек) *дәвер* сүзен түбәндәгечә шәрехли. ***Дәвер*** *– чор, заман. Вакыт. Берәр процессның үсешендәге бер баскыч, стадия.* Күргәнебезчә, дәвер шактый зур вакыт аралыгын үз эченә сыйдыра. «Университетта уку чоры», дию дә телебезгә туры килеп бетми. *Чор* сүзе, гомумән, фигыльләр янәшәсендә кулланылмый диярлек, чөнки кешенең эш-гамәлләрен төгәл билгеләгән фигыльләр аның төсмерен тарайта: «бару чоры», «ашау чоры», «уку чоры», «эшләү чоры» дип сөйләшми татар. Сүзлектә *чор*ның биш мәгънәсе тәкъдим ителә. ***Чор*** *– 1. Нәрсә белән дә булса (мәсәлән, иҗтимагый шартлар белән) чикләнгән вакыт аралыгы, бер процесс, вакыйга барган вакыт. 2. Ниндидер күренекле вакыйгаларны үз эченә алган, үзенә нинди дә булса үзенчәлекләр хас зур вакыт аралыгы. 3. Үсешнең, берәр эшчәнлекнең бер стадиясе, аерым бер моменты. 4. Хәзерге заман, хәзерге вакыт.*

---

[1] *Канча (иск.)* – күпме, никадәр.

*5. Геологик система катлауларының утырмалары барлыкка килгән вакыт аралыгы, эраның бер өлеше.*

Күргәнебезчә, *дәвер* һәм *чор* сүзләре башлыча киңрәк, глобаль; тәгаен бер кешенең эш-гамәле белән генә чикләнмәгән вакыт аралыгын билгеләгәндә кулланылалар. Аларга мәгънәдәш *заман* сүзе бар. Сүзлек аны түбәндәгечә аңлата: ***Заман*** *– җәмгыять яшәвенең бер вакыты, чоры; вакыт.*

«Университетта укыган заманда», дип язсак, тагын кешегә мөнәсәбәте булмаган билгесезлектә яшеренеп калган борынгы чор мәгънәсе килеп чыга, әкият башламына охшаш (борын-борын заманда), еллары төгәл ачыкланмаган калып формалаша.

Ә менә «университетта укыган чакта», «университетта укыган вакытта», дисәк, кешегә карата әйтелүе белән дә, мәгънә ягыннан да дөрес яңгырый. Сүзлектә *чак*ның – ике *(1. Кеше билгеле бер урында яшәгән, булган яисә яшь аралыгына туры килгән вакыт. 2. Нинди дә булса эш-хәрәкәт башкара торган, берәр күренеш бара торган вакыт). Вакыт* сүзенең унбер мәгънәсе бирелә. Безнең очракка туры килгәннәрен генә алыйк. ***Вакыт*** *– 1. Нәрсәнең дә булса секундлар, минутлар, сәгатьләр, еллар, гасырлар һ.б. шундыйлар белән исәпләнә торган яшәеш арасы, дәвамлылыгы. Яшәеш дәвамлылыгын үлчәү берәмлеге. 2. Берәр эш, вакыйга барган чак. 3. Берәр эш өчен билгеләнгән срок. Билгеләнгән срокның чиге.*

Вакыт аралыгын белдергән *мәл* сүзе дә бар (сүзлектә: ***мәл*** *– чак, вакыт*), тик таррак мәгънәле булу сәбәпле, ул безнең очракка туры килми.

Шулай итеп, «университетта укыган чакта», «университетта укыган вакытта» дип язу мәслихәт.

Әдәби телнең сафлыгына хилафлык китерергә әзер торган күренешләр һәрвакыт уяу. Җирле сөйләшләрнең «әрсез» сүзләре, сүз формалары да әнә шундыйлардан.

*Бересе, өчесе, берсесе, бусысы, ансысы, бүгенгесе, дәүрәгрәк* – диалектология фәнендә кушымчаларның плеонастик (икеләштереп) ялгануы аркасында барлыкка килгән әдәби тел хаталары. Алар фәкать урта диалектның казан арты һәм бәрәңге сөйләшләренә карый. Күп кенә язучыларның, мөхәррирләрнең дә шул төбәкләрдән чыгуын исәпкә алганда, әлеге хаталарны булдырмый калырга тырышу өметсез нәтиҗәләр бирә.

«Бүген ничәсе әле ул? *Бересеме?*» «Авылдан мәрхүмә әнкәйнең *өчесен* укытып килдек». «*Бүгенгесе* көндә тормышыбыз җиңел түгел» кебек калыпларны әдәби телебездән кысрыклап чыгара алуыбыз бик шикле. Нишләп алайса «икесесе», «алтысысы» түгел, мәрхүмнәрнең «кырыгысы»н укытмыйбыз? Чөнки әдәби телдә мәсьәләнең хак чишелеше болай яңгырый: *бер+е, ике+се, өч+е, алты+сы, тугыз+ы, кырык(г)+ы.* Тартыкка беткән санга – тартым кушымчасының *-ы/-е*, сузыкка беткән санга *-сы/-се* варианты ялгана. Бутарга ярамый торган бер очрак бар: тартыкка беткән микъдар саны өченче затта тартым

белән төрләнсә, *-ысы/-есе* кушымчасы ялгана. Мисал: «Нәселгә калдырылган унөч сарыгымның ***унысы*** – ак, ***өчесе*** кара иде». Күрәбез, мәгънә гел үзгә. Әгәр бик тә «бутыйсыбыз килә» икән инде, мәсьәләнең асылын болайрак аңлатып була: «Айның утыз көне бар. Бүген безгә шуларның *өчесе* килгән, иртәгә *дүртесе* киләчәк! Шуңа күрә бүген өче түгел – *өчесе*, иртәгә дүрте түгел – *дүртесе*». Тик бу әдәби тел нормасыннан бик ерак тора һәм аның камиллегенә хилафлык китерә.

Әдәби әсәрләрдә сүзләрне урынсыз куллану очраклары белән бәйле хаталар да еш күзәтелә. Мәсәлән, *нинди* һәм *кайсы* алмашлыклары ничек аерыла? Сүзлек болай ди: ***Нинди*** *– кемнең яки нәрсәнең дә булса үзенчәлеге, сыйфаты турында сораганда кулланыла.* Мисал: «Шагыйрь яшәгән заманны күзаллап, аның кечкенә Апуштан зуп-зур Тукай дәрәҗәсенә күтәрелә алуын, бөеклеккә *нинди* фаҗигалар бәрабәренә ирешүен тирәнтен аңларга телим». *(Зиннур Мансуров);* ***Кайсы*** – күпләр арасыннан берсен белү өчен сораганда кулланыла. Мисал: «Бишегемне тирбәткәндә, әнкәй / *Кайсы* көйне икән көйләде?» *(Газинур Морат)*

*Кайда* һәм *кая* алмашлыклары белән дә шул ук хәл. Сүзлектә: ***Кайда*** *– кемнең яки нәрсәнең урынын белергә теләп сораганда кулланыла.* Ягъни, төгәл җирлек күздә тотыла, абстрактлыкка урын калдырмый. Мисал: «Әлү! Кызым... Азалия! Син *кайда?» (Ркаил Зәйдулла)*

***Кая*** *– кайсы җиргә, кайсы якка.* Ягъни, төгәл урын күздә тотылмый, гомумилекне белдерә, абстракт юнәлеш-тарафны билгеләү максатында кулланыла. Мисал: «Аларның һәркайсы Рәискә, фәрештә үк булмасалар да, эш-гамәлләре, сөйләгән сүзләре, язган әйберләре белән *каядыр* биектә, күктә утыручылар булып тоела иде». *(Флүс Латыйфи)*

Күргәнебезчә, *нинди* белән *кайсы*ны, *кайда* белән *кая*ны тиешле урында куллану артык авырлык тудырмый. Инде *белән* бәйлеген куллануның бүген актуаль яңгыраган урынлы-урынсыз очракларына тукталыйк.

Сүзлектә *белән* бәйлегенең унбер мәгънәсе бар. Җиденчесе (безнең очрак) болай: ***Белән*** *– вакыт төшенчәсен биргән исемнәр янында килеп, вакыт хәле* (рәвеш) *ясый.*

Замандаш язучыларның әсәрләрендә тәүлек вакытына нисбәтле бәхәсле очраклар да күзгә еш чалына башлады*: иртә белән, кич белән, төнлә белән.*

Тәүлек вакытларына аерым-аерым тукталыйк һәм сүзлектән аларның мәгънәләрен барлыйк.

***Иртә*** (исем) *– тәүлекнең бер өлеше, көннең беренче сәгатьләре, көннең башы.* Бу исемнән вакыт хәле (рәвеш) ике юл белән ясала: *-н* кушымчасы (суффиксы) ***(иртән*** *– иртә белән, иртәнге вакытта)* һәм *белән* бәйлеге ***(иртә белән*** *– иртән, көннең башында)* ярдәмендә.

***Көн*** (исем) *– тәүлекнең бер өлеше, кояш чыкканнан башлап, кояш батканчыга кадәрге вакыт, иртәдән кичкә кадәр булган ара.* Әлеге

исемнән вакыт хәле (рәвеш) бер генә юл белән ясала: *-дез* кушымчасы ***(көндез*** *– иртә белән кич арасындагы вакытта)* ярдәмендә. (Р. Әхмәтьянов төзегән этимологик сүзлектә болай диелгән: «Бу борынгы сүз «андыз», «балдыз», «кондыз» һ.б. моделендә ясалган булырга тиеш: *-дыз/-дез* морфемасының асылы әлегәчә ачыкланмаган». Ачыкланмаса да, *көндез* сүзенең тамыры *көн* булуда шик тумый.) *Көндез*гә *-ен* кушымчасы ялганып, шул ук мәгънәдәге сүз ясала – *«көндезен».*

Бер **искәрмә** бар. XX гасыр башы татар әдәбиятында *көндез* сүзе исем буларак та кулланылган. Мисал: *«Июньнең башы, ап-ачык кояшлы көннең* ***көндезе****». (Фатих Әмирхан)* Бу очракта: *көндез (*исем*) – иртә белән кич арасындагы вакыт.* Әмма әлеге форма инде актив түгел.

***Кич*** (исем) *– тәүлекнең көн бетеп, төн башлануга кадәр булган вакыт арасы.* Бу исемнән вакыт хәле (рәвеш) ике юл белән ясала: *-ен* кушымчасы ***(кичен*** *– кич булгач, кич вакыты җиткәч)* һәм *белән* бәйлеге ***(кич белән*** *– кич җиткәч)* ярдәмендә.

***Төн*** (исем) *– тәүлекнең кояш батыштан кояш чыгышка, кичтән иртә беләнгә кадәрге өлеше. Төн*нән вакыт хәле (рәвеш) бер генә юл белән ясала: *-лә* кушымчасы ***(төнлә*** *– төнге вакытта)* ярдәмендә.

«Көндез белән», «көндезен белән» димәгән кебек, «төнлә белән» дип сөйләү, язу да хата. Рәвешне тагын да рәвешлерәк итү нигә хаҗәт? Әле аның «иртә белән»е дә колакны сагайта. (Ә менә *таң белән* табигый яңгырый.) *Иртәнге якта, иртәнчәк* кебек сүзләребез юкмыни?!

Күрәбез ки, грамматик кагыйдә нигезендә, *белән* бәйлеге тәүлекнең ике генә (иртә, кич) вакытына нисбәтле вакыт хәле (рәвеш) ясауда катнаша.

Ясау дигәннән, әзер, мөкәммәл сүзнең «тормышы»на тыкшынып, кирәкмәгән кушымчалар өстәп, камил укылышны абындыру очраклары аз түгел. *Мөмкинчелек* – әнә шундыйлардан.

Сүзлектә *мөмкинчелек* сүзе юк! Ә ***мөмкинлек*** *– 1) берәр эшхәлнең булу-булмавын тәэмин итә торган хәл, шарт, җай. 2) мөмкин булу, ихтималы булу, ихтималлык,* дип шәрехләнә.

Сүз ясалышы ягыннан мантыйкка таянып фикерлик: *мөмкинлек – мөмкин* хәбәрлек сүзеннән *-лек* кушымчасы ярдәмендә ясалган исем. «Мөмкинче» кәлимәсе телдә юк. Ә *-чылык* /*-челек* кушымчасының үтәгән вазифасы үзгә бит. Ул ике генә сүз төркеменнән яңа сүзләр ясый: исемнән – исем (*кошчылык, дәүләтчелек* һ.б.), рәвештән – исем (*азчылык, түбәнчелек, кимчелек* һ.б.).

Семантик яктан янәшә булган, ләкин өчесе өч төрле модаль мәгънә төсмерен белдереп килгән, бүгенге әдәби телдә актив кулланылышта йөргән хәбәрлек сүзләребез нибары өчәү генә: *кирәк* (зарурилык / необходимость), *тиеш* (тиешлек / долженствование), *мөмкин* (мөмкинлек / возможность). «Мөмкинчелек» вариантына калган икесен куеп карыйк: «кирәкчелек», «тиешчелек». Яңгырыймы? Юк! Димәк, грамматик хата.

«Өлкән буын телне салмак олыгайтып яшәтсә, яшь буын телне санлап яшәртә. Шушы табигый бизмәннең ике яссылыгы да тигез тибрәнештә булганда гына телнең терек сулышы бөтен мөмкинлегенә киерелеп ачыла», – ди М. Галиев.

Шуңа күрә, әдәби традицияләргә тугры калып, туган телнең сафлыгын, камиллеген хәзерге заман әсәрләрендә дә сакларга омтылырга кирәк. Ата-бабаларыбыздан килгән сүз-сурәт энҗеләре XXI гасыр әдәбиятында да бар тулылыгында чагылсын, киләчәк буыннарга «терек сулышы» зәгыйфьләнмичә барып җитсен иде.

**Әдәбият**

*Галиев М.* Әсәрләр: 6 томда. 2 т. Казан: Идел-Пресс, 2011.

Дәрдемәнд. Фотоальбом / төз. Зөфәр Рәмиев, текст авт. Лирон Хәмидуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.

Татар грамматикасы: 3 томда. 2 т. Мәскәү: ИНСАН; Казан: ФИКЕР, 2002.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977, 1979, 1981.

***Ханнанов Рамил Гомәр улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан шәһәренең «Адымнар – белемгә һәм бердәмлеккә юл» полилингваль белем бирү комплексы туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

УДК 81’33, 81.512.1

***Б.Э. Хәкимов,***
***М.Р. Шәехов***

# РУСЧА-ТАТАРЧА МАШИНА ТӘРҖЕМӘЧЕСЕ ӨЧЕН ПАРАЛЛЕЛЬ ТЕСТ КОРПУСЫНДА ҖӨМЛӘЛӘР ТӘҢГӘЛЛЕГЕ

При подготовке обучающих и тестовых корпусов для систем машинного перевода осуществляется поиск готовых параллельных текстов на двух языках в различных доступных источниках. Обычно считается, что пары предложений из оригинальных текстов и их переводов, если они были опубликованы и имеют официальный статус, являются эквивалентными. Однако в результате анализа таких предложений установлено, что степень их эквивалентности в определенных случаях может не соответствовать задачам разработки систем машинного перевода. В данной статье изучаются типичные случаи, в которых проявляются различия в требованиях к эквивалентности перевода предложений в исходных текстах и в качестве отдельных единиц параллельного тестового корпуса, используемого для оценки качества результатов машинного перевода. В результате исследования установлено, что предложения, извлекаемые из параллельных текстов на двух языках, и их переводы даже при полной контекстной эквивалентности могут потребовать значительного количества лексических, грамматических и других трансформаций.

**Ключевые слова:** машинный перевод, качество перевода, параллельный корпус, эквивалентность перевода, татарский язык, русский язык.

The current practice of preparing training and test corpora for machine translation systems usually involves searching for parallel texts in real use. Pairs of sentences from the original texts and their published translations are considered a priori equivalent. However, a detailed qualitative analysis of such sentences shows that this does not always meet the requirements of machine translation systems. This paper discusses typical differences between the equivalence of texts and the equivalence of parallel corpus units. The results show that sentences from the authentic texts and their translations, despite of their complete parallelism and contextual equivalence, may require a significant amount of lexical, grammatical and other transformations.

**Keywords:** machine translation, translation quality, parallel corpus, translation equivalence, Tatar language, Russian language.

Нейрочелтәрле машина тәрҗемәсе системалары өчен өйрәтүче корпуслар һәм тест корпусларын әзерләүнең төп ысулы мөмкин кадәр күбрәк чыганаклардан ике телдә әзер параллель җөмләләр туплаудан гыйбарәт. Русча-татарча машина тәрҗемәсе сыйфатын бәяләү өчен, махсус параллель корпус төзелде [Хакимов, Шаехов, с. 283–292]. Гадәттә мондый төр корпусларны әзерләгәндә оригиналь текстлардан һәм рәсми, басылып чыккан тәрҗемәләрдән алынган җөмлә парлары тулысынча эквивалент, тәңгәл дип санала. Әмма андый җөмләләргә анализ ясау нәтиҗәсендә аларның тәңгәллек дәрәҗәсе машина тәрҗемәсе системалары таләпләренә җавап бирмәскә дә мөмкин икәнлеге ачыклана.

Эквивалентлык – тәрҗемә гыйлеменең төп мәсьәләләреннән берсе. Тәрҗемә теориясендә ул төрле лингвистик һәм экстралингвистик факторларга бәйле булган чагыштырма характеристика буларак карала. В.Н. Комиссаров эквивалентлыкны тәрҗемә белән төп нөсхәнең максималь мөмкин булган лингвистик якынлыгы дип билгели һәм төп нөсхә белән тәрҗемә арасында аның берничә дәрәҗәсен аерып күрсәтә: коммуникация максаты дәрәҗәсе, ситуацияне тасвирлау дәрәҗәсе, ситуацияне тасвирлау ысулы дәрәҗәсе, әйтелгәннәрнең структур төзелеше дәрәҗәсе, лексик берәмлекләр семантикасы дәрәҗәсе [Комиссаров, б. 167]. Л.С. Бархударов фикеренчә, эквивалентлык – ул төп нөсхә һәм тәрҗемә телендә текстларның мәгънәви яктан туры килүендә чагыла торган семантик категория [Бархударов, б. 150]. Шулай итеп, тәрҗемәнең реципиентка йогынтысы төп нөсхәгә тиңдәш булсын өчен, аларның тәңгәллеге лексик, грамматик һәм синтаксик дәрәҗәдә генә түгел, ә коммуникатив ситуация һәм максат дәрәҗәсендә дә тәэмин ителергә тиеш. Тагын да катлаулырак дәрәҗәләрдәге эквивалентлыкка ирешү өчен, тел чараларының гади тәңгәллегенә игътибар итмәскә мөмкин дип санала.

Әлеге мәсьәлә машина тәрҗемәсе максатларында параллель корпуслар әзерләү процессында үзенчәлекле рәвештә чагылыш таба. Машина тәрҗемәсенең теләсә кайсы конкрет нәтиҗәсенә карата төрле дәрәҗәләрдәге тәңгәллек күзлегеннән барлык таләпләр кулланырлык булса да, мондый прагматик юнәлешле параллель корпусларда урын алган җөмлә парлары аерым үзенчәлекләргә ия.

Төп үзенчәлек контекст күләме белән бәйле. Тәрҗемә ителә торган эчтәлекнең контекстуаль мәгънәсе бөтен текст яки аның бер өзеге дәрәҗәсендә аерылып тора. Кагыйдә буларак, машина тәрҗемәсе максатларына хезмәт итә торган параллель корпусларга аерым җөмләләр контекст бәйләнешләрен сакламыйча гына урнаштырыла, чөнки текстлардан барлык җөмләләр түгел, ә билгеле бер критерийларга туры килгәннәре генә сайлап алына. Димәк, чыганак текстлардагы параллель җөмләләр ике телдә дә коммуникатив ситуация һәм контекст дәрәҗәсендә эквивалент булырга мөмкин (мәсәлән, әдәби әсәрләрдә төп эчтәлек – образлар аша, ә матбугаттагы яңалык текстларында фактлар аша бирелә). Параллель корпуска кертелгәч исә, контексттан максималь бәйсезлек шартларында шул ук җөмләләр структур төзелеш яисә лексик берәмлекләр дәрәҗәләрендә тәңгәллек таләпләренә инде туры килмәскә дә мөмкин. Башкача әйткәндә, тәрҗемә ителгән җөмлә эквивалентлыгының кайбер факторлары әлеге җөмлә конкрет контексттан аерылгач юкка чыга. Шуңа бәйле рәвештә мондый корпусларда параллель җөмләләрне бәяләү һәм аларга төзәтмәләр кертү өчен, билгеле бер кагыйдәләр билгеләү зарурлыгы туа. Мәсәлән, җөмләләр тәңгәллегенә ирешү тагын да төгәлрәк дәрәҗәдә мөмкин булган очракта, тиешле төзәтмәләр кертеп, мөмкин кадәр күбрәк контекстларга туры килерлек вариант барлыкка китерү максатка ярашлы була.

Җөмлә парларының контексттан бәйсез эквивалентлыгы аларның төп нөсхәдәнме, тәрҗемәдәнме булуына караганда мөһимрәк, шуңа күрә дә төзәтмәләр параллель җөмләләрнең икесенә дә кертелә ала. Без аерым очракларда хәтта әдәби әсәрләрдән алынган оригиналь җөмләләрне дә үзгәртергә мөмкин дип саныйбыз, чөнки матур әдәбият тәрҗемәсендә гадәттә югарырак дәрәҗәдәге эквивалентлык турында сүз бара. Бер яктан, корпуста реаль тексттан булган оригиналь җөмләне саклап калу өчен, тәрҗемәгә үзгәрешләр кертү кулайрак. Икенче яктан, әгәр корпус лингвистик күренешләрнең төрлелеге (шул исәптән грамматик формалар һәм лексик берәмлекләр) ягыннан репрезентативлырак булса, машина тәрҗемәсе сыйфатын бәяләүнең нәтиҗәлелеге дә арта. Шулай итеп, төзәтү варианты һәр очракта аерым сайлана. Моннан тыш, һәр вариантны редакцияләүгә сарыф ителә торган вакыт һәм хезмәт күләме дә игътибарга алынырга мөмкин.

Гомумән алганда, машина тәрҗемәсе нәтиҗәләрен бәяләү өчен параллель җөмләләр корпусын әзерләгәндә, экспертка параллель җөмлә парларының максималь эквивалентлыгы һәм тәрҗемәнең табигыйлеге арасында баланс саклау бурычы йөкләнә.

Русча-татарча машина тәрҗемәсе сыйфатын анализлау өчен хезмәт итә торган параллель җөмләләр корпусын төзү барышында, текст составындагы һәм корпусның аерым берәмлекләре буларак җөмләләр эквивалентлыгына карата булган таләпләрдәге аермаларны истә тотып, түбәндәге төр төзәтмәләр кертелде. Әлеге мәкаләдә параллель русча-татарча тест корпусыннан [Хусаинов, Хакимов, Шаехов, 2022] татарча җөмләләрне төзәтү мисаллары китерелә: башта чыганак текстлардан үзгәрешсез алынган җөмләләр, җәя эчендә татарча җөмләнең төзәтелгән варианты бирелә.

1. Контексттан бәйсез вариантка үзгәртү: *Бушуева **сидела** в кабине второй машины. – Бушуева икенче машинаның кабинасында **бара иде** (Бушуева икенче машинаның кабинасында **утыра иде**)*.

Әлеге мисалда транспорт чарасы пассажирына карата *сидеть – барырга* фигыльләренең контекст эквивалентлыгы күзәтелә. Татарча җөмләгә төзәтмә кертү барышында фигыль туры тәңгәллеккә алмаштырыла, югарырак дәрәҗәдәге эквивалентлыкка да зыян килми, җөмләнең табигыйлеге югалмый. Димәк, бу очракта төзәтмә кертү үзен аклый. Тагын бер мисалда тәрҗемә төгәлрәк вариантка үзгәртелә: *Все знают – и никто **не понимает**. – Барысы да белә – һәм беркем **аңлата алмый** (Барысы да белә – һәм беркем дә **аңламый**)*.

2. Параллель җөмләдә туры тәңгәллеге булмаган сүзләрне бетерү: *Вспомнила Суок из сказки «Три толстяка». – «Три толстяка» әкиятендәге Суокны **да** искә төшерде.* (*«Три толстяка» әкиятендәге Суокны искә төшерде)*.

Мисаллардан күренгәнчә, параллель җөмләләр еш кына ачыклаучы яки көчәйтүче функция башкара торган тел чаралары йөрткән мәгънә төсмерләре белән аерылып торырга мөмкин: *По словам Тяминова Артура, картофель хорошо хранится. – Тяминов Артур*

*әйтүенчә, бәрәңге **бик** әйбәт саклана (Тяминов Артур әйтүенчә, бәрәңге әйбәт саклана).*

3. Грамматик форманы үзгәртү: *Минздрав ответил на предложение вернуть курилки в **аэропорты**. – Сәламәтлек саклау министрлыгы тәмәке тарту урыннарын **аэропортка** кайтару тәкъдименә җавап бирде. (Сәламәтлек саклау министрлыгы тәмәке тарту урыннарын **аэропортларга** кайтару тәкъдименә җавап бирде).*

Китерелгән мисалда, җөмләләр эквивалентлыгын арттыру өчен, төп нөсхәдә булган күплек сан формасы тәрҗемәдә дә торгызыла.

4. Стилистик хаталарны төзәтү һәм тәрҗемәне стилистик яктан үзгәртү: ***Убежище** в январе в ЕС получили только 13 граждан Грузии, а 1288 **гражданам дали отказ**. – Гыйнварда ЕСта **сыенуны** Грузиянең 13 гражданы гына алган, ә 1288 **гражданга кире кагылган**. (Гыйнварда ЕСта **сыену мөмкинлеген** Грузиянең 13 гражданы гына алган, ә 1288 **гражданның үтенече кире кагылган**).*

Бу төрдәге мисаллар күрсәткәнчә, чыганак буларак рәсми нәшер ителгән текстлар һәм аларның тәрҗемәләре кулланылуга карамастан, җөмләләрдә хаталар да булырга мөмкин (ешрак стилистик характерда). Тәңгәллек дәрәҗәләре күзлегеннән караганда, мондый хаталарны төзәтү югарыдагы мисаллар белән чагыштырганда капма-каршы нәтиҗәгә китерә, ягъни төзәтмәләр керткәч, бигрәк тә билгеле бер контекст белән турыдан-туры бәйле булмаган очракта, тәңгәллекнең түбәнрәк дәрәҗәсенә генә түгел, ә югарырагына да ирешергә мөмкин.

Түбәндәге мисалда исә төзәтүнең төрле юнәлештәге ике төрен күрергә була: бер яктан, *бумага* сүзенең тәрҗемәсе контекстка бәйле булмаган вариантка алмаштырыла һәм, шулай итеп, тәңгәллек түбәнрәк дәрәҗәгә күчә. Икенче яктан, сүзгә-сүз тәрҗемәне үзгәртү исәбенә (*со словами – мондый сүзләр белән*), сүзтезмәнең гомуми эквивалентлык дәрәҗәсе күтәрелә: *Они должны за подписью руководителя присылать в Роскомнадзор **бумагу со словами**:... – Алар җитәкче имзасы белән «Роскомнадзор»га **мондый сүзләр белән хәбәр** җибәрергә тиешләр:... (Алар җитәкче имзасы белән Роскомнадзорга **мондый эчтәлекле кәгазь** җибәрергә тиешләр:...)*

5. Телләрнең берсендә синонимик лексик берәмлек яки грамматик форма булганда вариант өстәү: *Приглашать в школы **героев** войны. – Мәктәпкә сугыш **геройларын** чакырырга (1) Мәктәпкә сугыш **геройларын** чакырырга. 2) Мәктәпкә сугыш **каһарманнарын** чакырырга).*

Әлеге мисалдагы русча *герой* сүзенең татар телендә ике варианты бар. Димәк, әгәр тест корпусында синонимнарның берсе генә теркәлгән булса, автомат тикшерү вакытында тәрҗемәнең тулысынча эквивалент булган икенче, синонимик варианты төгәл түгел дип бәяләнәчәк. Шул сәбәпле параллель корпуска ике пар җөмлә өстәлә, аларда бер телдә бер генә вариант кулланыла, ә икенчесендә аерыла. Мондый хәл лексика дәрәҗәсендә дә, грамматика дәрәҗәсендә дә барлыкка килергә мөмкин. Түбәндәге мисалдан күренгәнчә, рус телендәге фигыльнең инфинитив формасының татар телендә ике эк-

виваленты бар: *В теории его **сосчитать** несложно. – Теориядә аны **санарга** авыр түгел (1) Теориядә аны **санарга** авыр түгел. 2) Теориядә аны **санау** авыр түгел).*

Телләрнең берсендә теге яки бу грамматик мәгънәнең формаль күрсәткече булмаган очракларда да параллель җөмлә вариантларын өстәргә кирәк була. Мәсәлән, рус телендә үткән заманда фигыльнең зат күрсәткечләре юк, татар телендә исә бу грамматик мәгънә ачык белдерелә: *Так и **скупила** все в этом маленьком магазине. – Шулай итеп, бу кечкенә кибеттәге бөтен әйберне **сатып алып та бетердем** (1) Шулай итеп, бу кечкенә кибеттәге бөтен әйберне **сатып алып та бетердем**. 2) Шулай итеп, бу кечкенә кибеттәге бөтен әйберне **сатып алып та бетерде**).*

Тагын да төгәлрәк караганда, соңгы мисалда *сатып алып та бетердең* дигән тагын бер вариантны өстәргә кирәк. Ә татар телендә үткән заманның төп ике формасы булуын да исәпкә алсак, мөмкин булган вариантлар саны икеләтә арта. Бу очракта ике стратегия булырга мөмкин: мөмкин булган барлык вариантларны кертү яисә статистик яктан ешрак очрый торганнарын сайлау.

Тикшеренү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, еш кына чыганак текстлар һәм аларның тәрҗемәләре арасында тулы контекстуаль эквивалентлык булганда да, аерым җөмлә парлары буларак махсус корпуска өстәгәндә, шактый күләмдә лексик, грамматик һәм башка трансформацияләр таләп ителә. Шундый лингвистик мәгълүмат җыелмаларының гади тел эквивалентлыгы күзлегеннән караганда төгәлрәк булуы машина тәрҗемәсенең сыйфатын арттырырга мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

*Бархударов Л.С.* Язык и перевод. М., 1975. 230 с.

*Комиссаров В.Н.* Общая теория перевода (лингвистические аспекты): Учеб. для ин-тов и фак. иностр. яз. М.: Высшая школа, 1990. 253 с.

*Федоров А.В.* Основы общей теории перевода. М.: Высшая школа, 1983. 300 с.

*Хакимов Б.Э., Шаехов М.Р.* К вопросу создания параллельного тестового корпуса для задачи машинного перевода в русско-татарской паре // Восьмая Международная конференция по компьютерной обработке тюркских языков «TurkLang-2020». (Труды конференции). Уфа: ИИЯЛ УФИЦ РАН, 2020. С. 283–292.

*Хусаинов А.Ф., Хакимов Б.Э., Шаехов М.Р.* База данных тестового параллельного корпуса на русском и татарском языках. Свидетельство о регистрации базы данных 2022620573, 17.03.2022.

*Koller W.* Equivalence in Translation Theory // Ed. A. Chesterman, Readings in Translation Theory. Helsinki: Oy Finn Lectura Ab., 1989. P. 99–104.

***Хәкимов Булат Эрнст улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының билингваль һәм цифрлы белем бирү кафедрасы доценты,*
*ТР ФА Гамәли семиотика институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Шәехов Марат Рәшит улы,***
*ТР ФА Гамәли семиотика институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 7. 046.3+82-141

*А.А. Хасавнех,*
*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# ӘБҮ БӘКЕР КАЛАНДАР РУМИНЫҢ «КАЛАНДАР-НАМӘ» ИСЕМЛЕ СУФИЧЫЛ ӘСӘРЕНДӘ МӘХӘББӘТ КЛАССИФИКАЦИЯСЕ

В статье авторами анализируется 25 глава суфийской поэмы золотоордынского автора Абу Бакра Каландара Руми. Подробно излагаются комментарии с подробным изъяснением смысла используемых поэтом терминов, понятий, художественных образов, метафор и аллегорий, аллюзий на Коран, хадисы пророка Мухаммада и произведения других авторов. В исследовании рассматриваются и вопросы классификации термина «любовь» в суфийской парадигме и отражения его в «Каландарнаме». Его автор, рассуждая о различных ипостасях термина «Божественная любовь», как: «беззаветной любви», «правительницы над всем и вся», ее извечности (кадим) и т.д., подводит к заключению о том, что истинную любовь к Аллаху можно познать с помощью мистического «вкушения» или озарения (заук).

**Ключевые слова:** Каландар Руми, Каландар-наме, суфизм, золотоордынская поэзия, аллегория, озарение, вкушение, притча.

The article analyzes the 25th chapter of the Sufi poem by the Golden Horde author Abu Bakr of the Rumi Calendar. Comments are presented in detail with a detailed explanation of the meaning of the terms, concepts, artistic images, metaphors and allegories used by the poet, allusions to the Quran, hadiths of the Prophet Muhammad and works by other authors. The study examines in detail the classification of the term «love» in the Sufi paradigm and its reflection in the «Qalandarnam». Its author arguing about the various hypostases of the term «Divine love», such as: «selfless love», «ruler over everything and everything», its eternity (Kadim), etc., leads to the conclusion that true love for Allah can be known through mystical «tasting» or illumination (zauk).

**Keywords:** Kalandar Rumi, Kalandar-name, Sufism, Golden Horde poetry, allegory, illumination, tasting, parable.

«Каландар-намә» дип аталган суфичыл поэма XIV гасырда Алтын Урдада, дәүләтнең чәчәк ату чорында, Үзбәк һәм Җанибәк ханнарга багышлап иҗат ителгән. Аның авторы – Анатолия каландарларының аз мәгълүм тармагы вәкиле, Ушшакийан (гарәп теленнән ‘ушшак – «гашыйклар») тарикатенә нигез салган Әбү Бәкер Каландар Руми. Исеменнән үк аңлашылганча, тарикатьнең нигезендә Илаһи мәхәббәт мистик идеясе ята. Әлеге идея Илаһи мәхәббәтне мәңгелектән алдагы башлангыч, галәм белән идарә итә торган көч дип саный. Мондый төр мәхәббәткә ирешүне Әбү Бәкер Каландар Руми дини культтан, иман һәм имансызлыктан өстен куя [Ал-‘Авади, ‘Аднан Хусайн, с. 40].

Бүгенге көндә Әбү Бәкер Каландар Руминың «Каландар-намә»се, Мәхмүд әл-Болгариның «Нәһҗел-фәрадис»ы кебек, үз чорының аеруча мәгълүм һәм иң күләмле шигъри әсәрләреннән санала. Биш дәфтәрдән (китаптан) гыйбарәт «Каландар-намә» 16121 бәеттән тора, гадәти укучы өчен авыр аңлаешлы катлаулы дидактик-мистик характердагы әсәр фарсы телендә язылган, үз эченә күпләгән суфичыл образларны, метафора, аллегорияләрне ала. Һәр дәфтәр үзе суфичылык доктринасының төрле мәсьәләләренә һәм аспектларына багышланган бүлекләргә бүленгән. Әсәрдә шулай ук Алтын Урда тарихына, авторның замандашлары тормышына кагылышлы мәгълүматлар бар [Әбу Бакр Каландар Руми]. Мәсәлән, автор үзенең рухи остазы шәех Гали Зәгъфәрани, шәех Салтук һ.б. хакында яза. Фикер образлылыгында һәм шигъри камиллектә кайтышрак булса да, структурасы белән «Каландар-намә» Җәлалетдин Руминың «Мәснәви»ен хәтерләтә. Поэмада мантыйкый эзлеклелек бар дип әйтеп булмый, бүлекләрнең эчтәлеге шактый хаотик характерда, шуңа да махсус аңлатма таләп итә [Читтик, с. 6–7].

Әсәрнең 21 икеюллыктан тора торган, «Илаһи мәхәббәткә, гашыйклык сыйфатларына, сөйгәнен искә алу халәтенә аңлатмалар» дип аталган 25 нче бүлеге тулысынча Илаһи мәхәббәт темасына багышланган, шигырьләр мистикларның мәхәббәт лирикасы белән турыдан-туры бәйле суфичыл терминология белән өретелгән.

Аллаһыга мәхәббәт (*махабба*) – иң биектәге соңгы тукталыш (*мәкама*), үзләренең рухи яшәешендә суфилар ирешә торган иң югары нигъмәт. «Илаһи мәхәббәт» суфичылык теориясендә таяну ноктасы булып санала, суфиларның дөньяны танып белүе нәкъ менә шуңа нигезләнә. Кайбер белгечләр искәртүенчә, «суфи» сүзенең бердәнбер дөрес аңлатмасы бу сүзнең шифрланган хәлдә Мәхәббәт концепциясен үз эченә алган булуына барып тоташа» [Шах, с. 52].

Коръәндә «мәхәббәт» сүзе (*хубб*, *махабба*) күп мәртәбә телгә алына. «Мәхәббәт» сүзенең Коръәндәге мәгънәсе дигәндә, Аллаһның үзенең колларына кызгану яисә аларга мәрхәмәт хисе күздә тотыла. Бу – мәхәббәтнең беренче дәрәҗәсе. Икенче дәрәҗәсе исә колның Раббысына булган хисләрен күрсәтә. Өченче дәрәҗәдәге мәхәббәтнең нигезен Аллаһ белән аңа табынучы арасында булган үзара мәхәббәт хисе тәшкил итә. Мәхәббәтнең Аллаһ атрибуты булуы Коръәндә ике төрле уйларга юл калмаслык итеп расланган, аларда Раббының бәндәгә, бәндәнең Аллаһыга (икенчесе беренчесеннән килеп чыга) булган үзара мәхәббәт мөнәсәбәтләренең иерархик характерда булуы күздә тотыла. «Әйт: Аллаһны яратасыз икән, артымнан барыгыз, шул вакытта Аллаһ та сезне яратыр һәм гөнаһларыгызны кичерер». (3: 31). «Әй, сез, иман китерүчеләр! Әгәр сезнең арадан кем дә булса диннән чыгып китә икән, ... Аллаһ үзе яраткан һәм үзен яратучы, иман китергәннәр белән килешүче, имансызлардан өстен булган, Аллаһ юлында көрәшүче һәм шелтәләүчеләрдән курыкмаучы бәндәләрен китерер. Бу Аллаһның юмартлыгы, ул аны кемгә теләсә, шуңа бирә, чөнки

Аллаһ – бөтен нәрсәне күрүче, белүче!» (5:54) һ.б. Илаһи мәхәббәт темасы шулай ук хәдисләрдә киң яктыртылган. Әнәс, Бохари, Мөслим тарафыннан язылган хәдисләрдә, мәсәлән, пәйгамбәр сүзләре китерелә: «Өч нәрсәгә ия булган теләсә кем иман тәмен татыр: Аллаһны һәм аның илчесен башка бар нәрсәдән артыграк сөюгә ия булганнар, Аллаһ хезмәтендәгеләрне Аллаһ ризалыгы өчен дип сөя белгәннәр. Түбәндәге доганы исә Пәйгамбәр Мөхәммәд с.г.в. гә нисбәт итәләр: «Я, Аллаһ, миңа үзеңне яратырлык һәм сине яратучыларны яратырлык мәхәббәт бир һәм мине синең мәхәббәтеңә якынайта торган һәр нәрсәне ярата алырлык ит, синең сөюең минем өчен (эссе көндә) салкынча судан кыйммәтрәк булырлык ит!» [Шиммель, с. 108]. Шуны искәртү мөһим: Илаһи мәхәббәт темасы ислам мистицизмында Коръәндә һәм хәдисләргә караганда да тирәнрәк үсеш алган, биредә ул Аллаһ алдында басынкылык һәм буйсынучанлык мотивлары кысасыннан бик нык чыгып киткән.

Иртә суфичылыкта мәхәббәт темасы күпләгән бәхәсләр чыганагы һәм фикер төрлелегенең сәбәпчесе булса да, барлык суфилар Аллаһка мәхәббәтнең *(махабба)* иң югары чик, тукталыш *(мәкама)*, суфилар үтә торган рухи юлның иң олы нигъмәте булуы белән бердәм килешәләр.

Гарәп телендә «мәхәббәт» дигән мәгънәгә ия сүзләрнең уналты варианты бар. Шул ук вакытта бу төркемдәге һәрбер сүз үзенең билгеле бер мәгънә төсмеренә ия. Мәсәлән: *(сабаба)* – тирән дәрт; *(хайаман)* – акылсыз мәхәббәт, сусау; *(вәҗд)* – экстаз халәтендә дулкынлану кичерү, тәэсирләнү һ.б. Суфилар аңлавында мәхәббәт ул – күтәрелә бара торган халәт. Илаһи мәхәббәтнең максаты мәкамага максималь ирешүдән, ягъни яратучының *(мөхиб)* яратылучыга *(мәхбүб)* килеп җитүеннән гыйбарәт. Суфичылык контекстындагы «мәхәббәт» мәгънәсенә ия сүзләрнең күпләгән вариантларын үтә катгый эзлеклелектә карарга кирәк, ягъни үзенең үсеш процессында чираттагы баскычка җиткәннең соңында мистика әлеге мәкамага туры килгән мәхәббәт халәтен кичерә [Хасавнех, с. 116].

«Каландар-намә» текстында да «мәхәббәт» термины төрле вариантларда кулланыла. Иң еш кулланылганы – *ʻишк (гыйшык)*, «дәртле мәхәббәт» һәм шул ук тамырдан ясалган *ʹашик (гашыйк), маʹшук (мәгъшук), ʹашикан* – 26 тапкыр; *хубб (хөб)*, *махабба (мәхәббә)* – 3 тапкыр күзгә чалына. Аллаһка мәхәббәтне аңлатуда *махабба* термины өстенлек алган гарәп суфи поэзиясеннән аермалы буларак, фарсы әдәбиятында *ʻишк* сүзе һәм әлеге сүзнең чыгарылмалары булган *ʹишк, ʹāшик, маʹшук* термины күбрәк кулланыла. Бу терминны хөкем сөрә торган диннең кагыйдәләренә каршы килә торган буш сүз сөйләп йөрүдә бик күпләр тарафыннан гаепләнүче Нури керткән дип санала. Ә ул үз-үзен яклап, «яратучы-*гашыйк* – Аллаһка якынаер өчен Аллаһ тарафыннан әлегә рөхсәткә ия булмаган кеше, ә яратучы-*мөхиб* үз мәхәббәте белән ләззәтләнәнүче дип тәкърарлаган» [Шиммель, с. 113]. Тулаем алганда фарсы суфи әдәбиятында *ʹишк, ʹāшик, маʹшук*

терминнарын куллану гаять традицион күренеш дип әйтү дөреслеккә туры килә.

Әмма фарсы суфи поэзиясен тикшерүче күп кенә галимнәр фикеренчә, *'ишк*ка караганда *махабба* югарырак тора. Әйтик, В.А. Дроздов «*'ишк*тан югарырак форма – сөйгән кешедә эри торган *махабба* үсеп чыга» дип саный [Дроздов, 2005, с. 368]. Шулай ук тормыш сере нигезендә мәхәббәт (*хөб)* сүзенең тамырын тәшкил итә торган ике гарәп хәрефе [х] һәм [б] ята дип исәпләү дә кабул ителгән.

Фарсы әдәбияты үрнәге булган «Каландар-намә»нең әйтелгән бүлегендә беренче шигырьдә «үз-үзен аямый торган» мәхәббәт хакында сөйләнелә. Суфиларның Аллаһка югары стадиядәге мәхәббәте шәхси кызыксынуга гына корылмаган. Үзләренең элеккеге гамәлләре яисә киләчәктә кыйласы эшләре өчен бүләккә ия булачагына өметләнгән кеше суфи була алмаган. Суфичылык тарихында Хәсән әл-Бәсри[1], Җүнәйд[2] кебек һ.б. мистиклар белән бер рәттә Рабига Гадәвия[3] исеме дә тора. Ул үзенең тәкъвалыгы һәм Аллаһтан куркуы белән дан алган. Аны «бөек гашыйк» дип йөрткәннәр. Раббыга карата «үз-үзен аямый торган» мәхәббәт дигән төшенчәне дә беренче мәртәбә ул керткән дип санала. Аның түбәндәге гыйбарәсе мәгълүм: «Әгәр мин җәһәннәмнән курыкканга сиңа хезмәт итәм икән, мине тәмугыңа ат. Әгәр мин синең җәннәтеңә өметләнеп сиңа хезмәт итәм икән, мине оҗмахыңнан мәхрүм ит» [Әл-'Авади, 'Аднан Хусайн, с. 247]. Җәлалетдин Руми[4] фикеренчә, оҗмахка әлегергә омтылу яисә тәмуг утыннан курку – болар бар да тән теләге. Үзенең мәшһүр «Мәснәви»ендә ул болай дип яза: «Шәех әйтте: «Әй, бар итүче! Мин – гашыйк. Синнән башка кемгә дә булса сусасам, мин гөнаһ эшләгән булам. Әгәр мин сигез оҗмахка өметләнеп яисә җәһәннәм утыннан куркып, сиңа хезмәт иткән булсам, мин үз куркынычсызлыгым өчен кайгыручы дин тотучы булып чыгар идем. Ник дигәндә, боларның һәр икесе – тән теләкләре генә» [Читтик, с. 242]. Үз-үзен аямый торган мәхәббәт мотивы (ягъни нәрсәдер бәрабәренә булмыйча, нәрсәгә дә булса кызыгуга нигезләнмичә) фидакярләрчә Аллаһка мәхәббәт белән өретелгән мөселман Шәрыгы суфилар поэзиясендә һәм шул ук вакытта күпләгән татар суфи шагыйрьләре әсәрләрендә киң үсеш алган булган [Мөхәммәтҗанова, б. 107].

Беренче шигырь дәвамында «гашыйклар эзләнү халәтендә булалар», дигән фикер яңгырый. Монда суфиларның яшәү дәверендә

---

[1] Хәсән әл-Бәсри, Әбү Сәид (642–728) – иртә исламда күренекле дин белгече, суфичылыкка нигез салучыларның берсе. Мәдинәдә туган, Бәсрада яшәп, шунда вафат.

[2] Җүнәйд, Әбелкасыйм бине Мөхәммәд әл-Хазз, Тавис әл фөкарә («Юксыллар тависы (кошы)») (үлгән елы – 911) – Багдад шәехе, чыгышы белән фарсы. Аскет, «маламати» нишапур мәктәбе тәгълиматын үстерүче.

[3] Рабига Гадәвия (713 яисә 714–801) – беренче суфи фидакяр хатын-кызы һәм шагыйрәсе.

[4] Руми, Җәлалетдин (1207–1273) – бөек фарсы шагыйре һәм суфи. Мәүләви дип аталган суфилар җәмгыятенә нигез салучы.

билгеле стадияләрне (*мәкам*) үтүе күздә тотыла. «Каландар-намә» юлларында да шушы идея алга сөрелә.

Икенче шигырьдә яратуның башы һәм ахыры турында әйтелә. Бу мәхәббәт дәвамында мистиклар әүвәл акылсызлык кичерәләр, аннары аларга осталык килә. Үзләренең рухи үсеш башында мистиклар, бер тукталыштан икенчесенә хәрәкәт итү барышында, яраткан затларыннан, ягъни Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләдән ерагаю турындагы уйлар башларына керсә, күңел газаплары кичерәләр, үз-үзләрен ашау, юксыну кебек хисләрдән арына алмыйлар һ.б. Үзләренең чарасызлыгында суфилар күңел борчуларыннан арындырырлык канәгатьлек тапканнар, бу канәгатьлелеккә ирешүне төрле чикләүләр, тирән кайгыруларда тапканнар. Бу төркем каләм әһелләре сагыш, Ватаннан читтә яшәү, сукбайлыкта йөрү, сәйяр тормыш һ.б. хакында сөйли торган кыска күләмдәге чәчмә әсәрләр һәм шигырьләр иҗат иткәннәр. Алар өчен «яшәеш ул – сагыш һәм шатлыктан йөрәк очраклы рәвештә барып бәрелә торган бер әйбер» [Әл-‘Авади, ‘Аднан Хусайн, с. 145]. Әлеге хакыйкать ачкычы суфи әсәрләрендә аһ ору, елау-сыктау, ыңгырашу, кычкыру һ.б. формасында чагылыш таба. Югарыдагыларга нигезләнеп, Аллаһны сагыну чагылыш тапкан шигырьләрдәге хискичерешләрнең сизгерлеген һәм киеренкелеген аңлатырга мөмкин. Үткән юлларының ахырында, суфилар *бәка* дип аталган иң югары стадиягә җиткәч, «килеп җиткәч» яисә «Аллаһ белән кушылгач», алар тормышында булган барлык каршылыклар һәм күңел газаплары юкка чыга; яратучы һәм яратылучы зат арасында торган фани һәм тынычсыз «мин» яшәешнең юклыгына китә. Шул рәвешле мистиклар осталыкка ирешә. «Каландар-намә»нең фәлсәфи-мистик характердагы әлеге юлларын әлеге фикерләү рәвеше аңлаешлы итә.

Өченче шигырь мәхәббәтне бөтен нәрсә белән идарә итүче буларак тасвирлый, укучының игътибары Илаһи мәхәббәтнең өстенлекле позициядәге ярату булуына юнәлтелә. Мәхәббәт – аны үзенең мистик мәхәббәткә багышланган мәшһүр *«Саваних фи ал-‘ишк»* («Мәхәббәт турында ачыктан-ачык») трактатында Әхмәт Газали күргәнчә, мәңгелектән алдагы һәм барлык нәрсәләрнең мәңгелек беренчел сәбәпчесе, нинди дә булса кимчелекләрдән азат Аллаһ гамәле. Көнчыгышны өйрәнүче немец галиме Х. Риттер искәрткәнчә, «мистик мәхәббәт дөньяви мәхәббәттән шуның белән аерыла, анда мәхәббәт дөньясы сферасына трансцендент, абсолют объект җәлеп ителә. Шуның хисабына мәхәббәтнең кыйммәте шулкадәр югары күтәрелә ки, ул иң өстенлекле биеклеккә менә, өстәвенә, мәхәббәт күңелнең башка төрле ашкыну-омтылышларыннан да абсолют өстенлек ала» [Ritter, s. 90]. Суфилар фикеренчә, мәхәббәт – хәрәкәт иттерүче көч, яшәүнең иңиң мөһим чыганагы. Мәхәббәт – ул үзе тормыш. Суфи шагыйрьләр дөньяга мәхәббәт призмасы аша караганнар да. «Каландар-намә» авторы да мәхәббәтне яшәешнең барлык чагылышында күргән.

Чираттагы дүртенче һәм бишенче шигырьләр Илаһи мәхәббәтнең мәңгелеге *(кадим)* хакындагы бәйләп торган тема аша үзара бер-

ләшкәннәр. Радикаль мистик-пантеистик юнәлешнең билгеле вәкиле, Әбү Язид әл-Бистами[1] һәм әл-Җүнәйднең дәвамчысы Мансур әл-Хәллаҗ[2] әйткән:

العشق في ازال الازال من قدم
فيه، به، منه، يبدو فيه ابداء

[Әл-‘Авади, ‘Аднан Хусайн, с. 230]

Мәңгелектәге мәхәббәт – гомер-гомергә...
Бөтен нәрсәнең башы да шул[3].

Суфиларның үзләренең мәхәббәтне Аллаһ нигъмәте дип санауларына нигезләнгән күзаллаулары бу хиснең мәңгелек булуына бәйле. Мәхәббәт хисен Раббы үзен яратучылар йөрәгенә үзе салган. «Аллаһ җаннарны бар иткәннең соңында җан, иманлы хәлендә, үзен бар итүчегә таба юнәлткән». Бу Илаһи бүләк хакында беренче төрки суфи шагыйре Әхмәт Ясәвинең дә фикер йөрткәнлеген беләбез[4]. Аның фикеренчә, мәхәббәт – Аллаһтан бирелгән зур нигъмәт, аның бәһасе юк. Аллаһ мәхәббәт нурын чәчә һәм үзенең йөзен «гашыйкларга» ача. Әгәр бу хисне җиһанны бар итүчегә тугрылыкны аңлата торган хис дип карасак, барлык җаннарның да Аллаһ биргәннәргә тугрылык сакламавына килеп чыгабыз. Фәкать «мәхәббәт әһелләре»нә *(ахл ал-хубб)* генә аеруча булган мондый төр хис бирелгән, мондый яратуга алар гына сәләтле. Алар хакында Зу Нун әл-Мисри (үлгән: 860 ел)[5] болай ди: «Аллаһ үзен яратуны бурыч итеп керткән. Моның өчен кайберәүләрне бик күптән, әле беренче бәндәсен бар иткәнче үк, сайлап алган һәм аларның йөрәгенә болар хакында гыйлемне дә салган» [Хасавнех, с. 102].

Алтынчы шигырьдә сүз яшерен хәзинә буларак мәхәббәт турында бара. Бу шигырьнең эчтәлеге изге хәдис *(кудси)* белән аваздаш, шуңа күрә укучыны әлеге чыганакка юллый. Хәдис түбәндәгечә: «Мин яшерен хәзинә идем, кешеләрнең мине белүен теләдем һәм иҗатны бар иттем» [Әл-‘Авади, ‘Аднан Хусайн, с. 143]. Мәхәббәт яшәешне яшәешнең юклыгыннан китереп чыгара. Суфилар өчен җирдәге дөньяви тормыш – «Аллаһ күләгәсе», аның барлыкка килүе Аллаһның үзенең барлыгын күрсәтүгә омтылышы, Аллаһның шул рәвешле үз асылын күрергә теләве нәтиҗәсе. «Алай да Аллаһның

---

[1] Баязид Бистами, Тайфур бине Гайсә бине Адәм бине Сурушан (үлгән: 875 ел тирәсе) – күренекле фарсы мистигы, суфичылыкта төп агымнарның берсенә нигез салучы, ортодоксаль ислам тарафдарлары тарафыннан эзәрлекләүләргә дучар булган кеше.

[2] Әл-Хәллаҗ, Әбел-Могыйс әл-Хөсәен (б. Мансур) (чама белән: 858 – 922). Күренекле суфи, хөкем сөрә торган диннең кагыйдәләренә каршы килә торган төркем оештыруда гаепләнеп, җәзалап үтерелгән. «Мин – Аллаһ» фразасы белән мәгълүм.

[3] Монда һәм алга таба гарәп теленнән Алсу Хасавнех тәрҗемәсе.

[4] Әхмәт Ясәви (1103–1166) – суфи шагыйрь, төрки дөньяда беренче мистик суфилардан. Ясәвия тарикатен оештыручы. Чыгатай телендә иҗат иткән.

[5] Зу-н-Нун әл-Мисри (чама белән: 796 – 860/861) – Мисырда иртә суфичылыкның күренекле вәкиле. Суфи биографик әдәбиятында Зу-н-Нун образы аскет, могҗизалар тудыручы һәм алхимик буларак, легендар дәрәҗәдә телгә алына.

манифестациядә катнашуы тулысы белән түгел, ахырына җитү юк, даими рәвештә нәрсәдер «яшерелгән» хәлдә кала килә. Ул табигый хуш исле караңгылык пәрдәсе артына кача, чөнки дөнья тупас һәм нәзек матдәдән бар ителгән» [Степанянц, с. 398]. Җәлалетдин Руминың мондый юллары бар «Бер генә яратучы да бергәлек эзләмәс иде, әгәр Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә үзе шуны ук эзләмәсә» [Шиммель, с. 114]. Алтынчы шигырь үзенең эчтәлеге һәм идеясе белән шушы ук фикерләрне баета.

«Каландар-намә»нең сигезенче шигырендә ярату диңгез *(бәхер)* белән, ә гашыйк бәндә үзе елга белән чагыштырылган. Бу – әлбәттә, шартлы чагыштыру, чөнки суфи терминологиясендә *бәхер* сүзенең «тормыш» дигән мәгънәсе дә, «тәрикать» дигән мәгънәсе дә бар. Шулай булгач, «Каландар-намә» авторының интерпретациясенә караганда, диңгез Илаһи мәхәббәтне аңлата булып чыга, суфи иң элек Илаһи мәхәббәт диңгезенә элгә, аннан, елга котылгысыз төстә диңгезгә кушылган кебек, шул диңгездә эреп бетә.

Алдагы тугызынчы һәм унынчы шигырьләр үз эчтәлеге белән алдагы өченче шигырьгә аваздаш: мәхәббәткә бар булган нәрсә буйсына, вакыйгаларның яхшысы да, яманы да мәхәббәткә бәйле генә хәрәкәттә була ала, дип карала әлеге юлларда.

Унберенче шигырьдә гашыйкның сөйгәненә охшашлыгы турында әйтелә. Үз үсешенең кайсыдыр бер мизгелендә гашыйкның «мин»е мәгъшугы эчендә эреп бетә. Шул мизгелдән алып мәхәббәт бәйләнешендә объект һәм субъектка бүленеш юкка чыга. Гашыйк суфи мәгъшугы ихтыяры объектына әверелеп кала. Суфичыл мәхәббәт теоретикларының күпчелегенең яратылучысы белән тәңгәллеккә ирешү теләге турындагы карашлары Әфлатун тәгълиматына барып тоташа. Әфлатун тәгълиматында да җаннарның беренчел туганлыгы хакында сүз бара. Мистиклар әлеге вакыйгада яшәешне югалтуга, үз «мин»еңне югалтуга кайтып кала торган *фәна* төшенчәсен кулланалар. «Каландар-намә» дә шушы катлаулы процесслар хакында сөйли.

Уникенче шигырьнең тасвирлау үзәгендә суфи әдәбиятындагы традицион образ – шәм *(шам')* суфиларда Аллаһ символы буларак аңлатыла. Мәгълүм буларак, мистик поэзиядә шәмнең мәхәббәт пары итеп күбәләк күрсәтелә, ул гашыйк суфины гәүдәләндерә. Суфи шигъриятендә мондый аллегорик образлар гомумән бик киң таралыш алган.

Ә менә ундүртенче шигырьдә нәкъ менә алдагы унөченче шигырьдә телгә алынган пар – шәм һәм күбәләк турында сөйләнелә. Суфилар фикеренчә, чын мәхәббәт үз нәфесеңнән, хисси теләкләрдән тулысынча ваз кичүне таләп итә, бу таләп үзеңнең «мин»еңнән ваз кичү дәрәҗәсенә җиткерелә. Мистикның ахыр максаты – индивидуальлек хисләренең бөтенләй юкка чыгуы, гашыйкның мәгъшугына әверелеп бетүе. «Каландар-намә»дә күбәләкнең үзенең дә шәм ялкынында мизгел эчендә ялкынга әверелүе суфи поэзиясендәге әнә шул иң бөек максатка ирешүне гәүдәләндерә. М. Хәллаҗның «Китаб әт-тавасин»ында да күбәләк символы аша өч мистик стадия күрсәтел-

гән: ерактан шәм яктысын күреп алган күбәләк *«ʻилм ал-йакин»* халәтен, ягъни белемгә һичбер шиксез ия булу халәтен кичерә. Ә инде шәмгә якын очып килеп, аның җылысын сизгәннең соңында *«ʻайн ал-йакин»* халәтенә керә, ягъни һичбер шиксез күрә алу стадиясенә ирешә. Ниһаять, шәм ялкыны күбәләкне, яндырып, үзенә алгач, әлеге этап *«хакк ал-йакин»* халәтенә күчеш дип санала, бу – һичбер шиксез, чынбарлык халәте.

Оппозициядәге суфичылыкның иң күренекле вәкиле Мансур Хәллаҗ мәхәббәтне иманнан өстенрәк куйган булса кирәк. Ул болай ди: «[Мәхәббәт] – Аллаһның мәңгелектән алдагы мәрхәмәте, аннан башка Китапның ни икәнен дә, иманның нәрсә булуын да аңлый алмаган булыр идегез» [Шиммель, с. 176]. Фәхреддин Гыйраклы мөселманнарның иман китерү сүзләрен шигъри яктан хәтта узып киткән кәлимә дә әйтә: Аллаһтан башка илаһ юк дигән мәгънәне үзгәртеп, ул болай ди: *«Лә илаһа илла ал-ʻишк»*, ягъни «Мәхәббәттән башка Аллаһ юк». Шул рәвешле, «Мәхәббәт имансызлыктан да, иманнан да көчлерәк» дигән сүзләре белән «Каландар-намә» авторы Аллаһка карата булган мәхәббәтне гап-гади генә итеп адәм теле белән дә, традицион иман яки имансызлык аша да аңлатып-төшендереп җиткереп булмый, аңа фәкать мистик дәрәҗәдәге кичерү, сиземләү, тою аша яисә ачылып балку, нурлану аша ирешеп кенә була.

Юкка чыгу *(фәна)* һәм Аллаһка килеп җитү *(бәка)* темасы уналтынчы һәм унҗиденче шигырьләрдә тирәнәйтелә. Мәхәббәтнең башы *(фәна)* – ул югалу, юкка чыгу, ә ахыры – мәңгелек яшәү *(бәка)*. *Фәна* терминына билгеләмә биргән барлык мистиклар арасында иң уңышлысы дип Җүнәйд әйткән фикерне күрсәтергә мөмкин. Мәхәббәт тәэсирендә килеп чыга торган үзгәрешләрне ул түбәндәгечә билгеләгән: «Мәхәббәт яратучыны, ягъни юкка чыгучыны үтерә, яратылучыны исә үз асылында раслый» [ʻАйса, ʻАбд әл-Кадир, с. 321]. Башкача әйткәндә, суфиларның катгый ышануына караганда, кеше Мәңгелектән алдагы Васыять көнендәге халәтенә кире кайтырга тиеш. Мондый халәтне мистиклар «берлек, җыелганлык» дигәнне аңлата торган *джамʻ* термины белән билгелиләр. Мәхәббәт тә *(мәхәббә)*, юкка чыгу *(фәна)* да – Илаһи нигъмәт, мәрхәмәнең аерылып тора торган билгесе. Ул табып алынган, тырышып ирешелгән халәт түгел һәм ул фәкать сайлап алынганнар өчен генә. Кайвакыт кайбер суфилар, Мансур әл-Хәллаҗ күрсәткән кебек, гадәти мәгънәсендәге үлемне эзләгәннәр, моның белән үзләренең гашыйк һәм мәгъшук арасында торучы, бетүчән һәм тынычсыз «мин»ннәрен читләштермәкче булганнар.

*Фәна* халәтеннән соң мистик чираттагы *бәка* стадиясенә ирешә ала, бу – Аллаһка «килеп җитү» яисә «яшәүгә ирешү». Бу этапта инде үзгәреш кичереп әверелгән суфи тулысынча Аллаһ арадашлыгында гамәл кыла башлый. «Каландар-намә»дә алдарак каралган ундүртенче һәм унбишенче шигырьдә күбәләк һәм шәм аллегориясе хакында сүз барган булса, алар әлеге чираттагы шигырьдәге поэтик юлларны тормышка ашыралар кебек аңлашыла.

Поэманың әйтелгән бүлеген тәмам итеп килә торган унтугызынчы – егерме беренче шигырьләрдә легендар Анка кошы образы килеп керә. Ул кош Каф тавы өстендә яши. Әлеге образның тамыры гарәп-мөселман мифологиясенә барып тоташа булса кирәк. Фарсы әдәбиятында әлеге образны Сәмруг кош белән тәңгәлләштерәләр. «Суфичылыкта Анка кошы изгеләр рухын яисә изгеләрнең үзен символлаштыра, ә Каф тавы – Илаһ урыны [Pellat, s. 1359].

«Каландар-намә»дә Анка кошы турында [Pellat] сөйләгәндә, «бөтен җирне әйләнеп очып чыккан булса да, аның һичбер билгесе юк», диелә. Бу шуны аңлата: әлеге кош исеме белән мәгълүм, әмма аның тәне юк. Шуңа күрә дә бу кош күп кенә чыганакларда яшәешнең юклыгын аңлатуда метафора урынына кулланыла. Шул ук вакытта төрле халыкларның легендар хикәятләрендә һәм риваятьләрендә Анка кошы, мифологик персонаж буларак, бик олы кош итеп тасвирлана, ул зур оя кора, филне күтәрерлек көчкә ия, 1700 ел яши һ.б. [Мифологический словарь].

Шул рәвешчә, «Каландар-намә» авторы түбәндәге нәтиҗәгә килә: «Илаһи мәхәббәт»не гади тел белән генә аңлатып булмый, ул катгый рәвештә фәкать мистик сиземләү, кичереш аша гына яисә кинәт ачылып киткән ниндидер бер балкуга *(зәвык)* ирешеп кенә танып беленә ала. Рухи юлындагы әлеге югары стадиягә суфи аннан алдагы стадияләрне *(мәкам)* җиңү аша ирешә.

Шулай итеп, «Каландар-намә» әсәре Алтын Урда шагыйренең гаять катлаулы суфи-дидактик поэмасыннан гыйбарәт, әсәрнең нигезендә мәңгелектән алдагы башлангычтагы Илаһи мәхәббәт идеясе ята, бу исә поэманы пантеистик тәгълиматларга якынайта. Әсәр катгый композицион структурага һәм бердәм сюжетка ия түгел, төрле эчтәлектәге өзекләрнең җыелмасын тәшкил итә. Биредә үзәк урынны суфи гыйлемен тапшыруда төп форма булган гыйбрәтле хикәя, кыйссалар алып тора. Әсәрдә суфи авторлар еш мөрәҗәгать иткән символ *(рәмез),* аллегория *(тәмсил),* хикәяләү *(дастан),* күзалланган персонажлар арасында бәхәс *(моназарә),* ишарәләр аша күрсәтеп бирү *(ишарә)* һ.б. метафорик формалар бик еш кулланылган. Әлеге поэма алга таба тарихчы, исламны өйрәнүчеләр, лингвистлар, әдәбиятчылар өчен гаять киң тикшеренү мәйданы булып тора. «Каландар-намә» әсәре – Алтын Урда чорының башка әдәби ядкярләре кебек үк, әдәби-мәдәни хәзинә. Һәм ул – белгечләр тарафыннан алга таба да тирәнтен өйрәнелергә хаклы әсәр.

**Әдәбият**

*ʻАйса, ʻАбд әл-Кадир.* Хакаʼик ʻан ат-тасаввуф. Халаб: Дар ал-ʻИрфан, 2010. 566 с.

*Әбу Бакр Каландар Руми.* Каландар-наме. Рукопись. 800 л. Личный архив И.М. Миргалеева.

*Әл-ʻАвади, ʻАднан Хусайн.* Аш-Шиʻр ас-суфи. Багдад: Дар алʻулум, 1979. 386 с.

*Дроздов В.А.* Мистическая любовь в иранском суфизме // Востоковедение: Филологические исследования. Вып. 26: Сб. статей. СПб.: Изд-во С.-Петерб. ун-та, 2005. С. 128–138.

*Дроздов В.А.* Учение о шахиде в средневековой суфийской литературе // «Рассыпанное» и «собранное»: стратегии организации смыслового пространства в арабо-мусульманской культуре / отв. ред. А.В. Смирнов. М.: ООО «Садра»: Языки славянской культуры, 2015. С. 344–390.

Мифологический словарь / гл. ред. Е.М. Мелетинский. М.: Советская энциклопедия, 1990. 672 с.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Урта гасыр язма чыганакларында теркәлгән татар эпик истәлекләре // Золотоордынское наследие: Сборник статей, посвященный 700-летию со дня рождения средневекового татарского поэта Сейфа Сараи. Выпуск 4. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2021. С. 106–110.

*Степанянц М.Т.* Мусульманская концепция творения мира // История философии. Запад – Россия – Восток. Книга первая. Философия древности и средневековья. М.:Греко-латинский кабинет, 1995. С. 396–402.

Татарская социально-философская мысль средневековья (XIII – сер. XIV в.): в 2-х кн. Кн. 1 / АН РТ, Ин-т яз., лит. и истории им. Г. Ибрагимова. Казань: ИЯЛИ, 1993. 235 с.

*Хасавнех А.А.* Ахметзян Тубыли: жизнь и творчество татарского поэта-суфия XIX века. Saarbrücken: LAP LAMBERT Academic Publishing, 2012. 206 с.

*Читтик У.* В поисках скрытого смысла. Суфийский путь любви. Духовное учение Руми: Пер. с англ., арабск. / сост., предисл. М.Т. Степанянц. М.: Ладомир, 1995. 543 с.

*Шах И.* Суфизм. М.: «Клышников, Комаров и К», 1994. 445 с.

*Шиммель А.* Мир исламского мистицизма. 2-е изд. М.: Алетейа: Энигма, 2000. 414 с.

*Pellat Ch.* ‘Anka’ // The Encyclopaedia of Islam. New Edition. Vol. 1. Leiden; London, 1960. 1359 p.

*Ritter H.* Philologika VII. Arabische und persische Schriften uber die profane und die mystische Liebe // Der Islam. Bd 21. Berlin; Leipzig, 1933. S. 89–91.

***Хасавнех Алсу Әхмәдулла кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 82.091

***Н.Ә. Хөббитдинова***

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫНДА МИЛЛИ-МӘДӘНИ АНТРОПОЛОГИК ОБРАЗЛАР:
## сәнгатьчә универсалияләр һәм интертекстуальлек

Исследование художественных универсалиев или универсалиев культур в контексте интертекстуального метода изучения является актуальным направлением в фольклорно-литературоведческой области филологической науки. Оно более всего актуализируется при сравнительно-сопоставительном изучении национального материала, родственных башкирской и татарской литератур, в частности, на примере творчества татарского классика Габдуллы Тукая. Так, было выявлено и рассмотрено ряд реминисценций и аллюзий в таких произведениях поэта, как «Шурале», «Водяная», в которых автор рассматривает такие образы мифологической культурной антропологии, как шурале, ярымтык, мэскэй, водяная дева и т.д. Эти древние образы нашли художественное отражение в поэмах поэта, который с определенной иронией и теплотой поэтизировал их в своем творчестве.

**Ключевые слова.** Габдулла Тукай, культурные, художественные универсалии, культурная антропология, интертекстуальность, образ, миф, герой, поэма, шурале, водяная.

The study of artistic universals or universals of cultures in the context of the intertextual method of study is an actual direction in the folklore and literary field of philological science. It is most actualized in the comparative study of national material, related to Bakshirian and Tatar literatures, in particular, on the example of the work of the Tatar classic Gabdulla Tukay. Thus, a number of reminiscences and allusions were identified and considered in such works of the poet as «Shurale», «Vodyanaya», in which the author considers such images of mythological cultural anthropology as shurale, yarymtyk, meskei, water maiden, etc. These ancient images found artistic reflection in the poems of the poet, who with a certain irony and warmth, poeticized them in his own work.

**Keywords:** Gabdulla Tukay, cultural, artistic universals, cultural anthropology, intertextuality, image, myth, character, poem, shurale, vodyanaya.

Татар халык шагыйре Габдулла Тукай (1886–1913) әсәрләрендә татар халык иҗаты традицияләренең сәнгати чагылышы белән бергә башкорт халык иҗаты белән интертекст бәйләнешен, ягъни уртаклыкларын күзәтергә мөмкин. Монда ике кардәш халыкның поэтик үзенчәлекләре охшашлыгын, бер яктан, генетик охшашлык дип тапсак, икенче яктан, аларны мәдәни, сәнгатьчә универсалиянең бер өлеше итеп карау да кызыклы.

Гомумән, мәдәни яки сәнгатьчә универсалия дигәндә, әлбәттә, охшаш тарихи чор, бөтен Россиядә барган билгеле иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрнең тугандаш әдәбиятларның да бер үк юнәлештә үсешенә юл ачуы күздә тотыла. Татар әдипләре дә тел сафлыгы, милли аң-

ның уянуы өчен актив эш алып бара (Г. Тукай, Дәрдемәнд, Г. Камал, Ф. Әмирханов, Ш. Камал, Г. Ибраһимов һ.б.). Матбугат битләрендә дә алар үзләре ишетеп белгән яки үзләре җыйган халык иҗаты өлгеләре хакында ялкынлы мәкаләләре белән милли узаңны уятырга, зиһеннәрен рухи кыйммәтләр белән баетырга тырыша (Максутов «Татар җырлары хакында» (Шура, 1911), Ә. Вәлиди «Җырларыбыз хакында» (Шура, 1911), Г. Юлдаш «Ил җырлары» (Шура, 1911) һ.б.) [Миңнуллин, б. 28].

Шушы милли аңның уянып, үз-үзен этнос итеп таныган бер мәлендә халыкның мифологик карашына, ышану-инануына, авыз-тел иҗатына нигезләнеп язылган поэтик әсәрләрендә Г. Тукай татар халкының бай рухи дөньясын тасвирлауга ирешә. Мәсәлән, ул халык хорафатын яхшы белеп, борынгы карашка ярашлы булган һәр җирсу, тау-таш, өй-кура иясе һәм хуҗасы образларына мөрәҗәгать итә. Ә мифик затларның «…күбесе антропоморф зат дип исәпләнгән. Берәүләре, мәсәлән, адәм кебек үк, туй үткәреп, ирле-хатынлы, бала-чагалы була, җәйләүгә күчә. … (шулай да) аларның кайберләре (албасты, убыр, шүрәле) – хатын-кыз заты гына» һ.б. [Башҡорт халыҡ ижады, 1992, б. 12].

Шундый мифик заттан булган шүрәлегә тап була Г. Тукайның «Шүрәле» (1907) шигырендәге герой.

*... Нәрсә бу? Качкынмы, җенме!*
*Йә өрәкме, нәрсә бу?*
*Кот очарлык, бик килешсез,*
*Әллә нинди нәрсә бу!*
*Борыны кәп-кәкре бөгелгәндер,*
*Тәмам кармак кебек.*
*Ялтырай, ялт-йолт киләдер*
*Эчкә баткан күзләре...*
*Урта бармак буйлыгы бар*
*Маңгаенда мөгезе.*
*Кәкре түгелдер моның бармаклары,*
*Бик төз-төзен,*
*Тик килешсез, һәр бере лә*
*Ярты аршыннан озын...–*

дип сурәтләнә ул әсәрдә [Тукай, б. 58].

Шагыйрь шүрәленең кешеләрне кытыклап үтерүе хакындагы «мәгълүматтан» яхшы хәбәрдар була. Башкорт хорафатларыннан билгеле булганча, ул, гадәттә, «салынкы имчәкле, сап-сары йөнтәс бичә кыяфәтендә була, ди. Кешене көлдереп, кытыклап үтерә», – ди. «Шүрәленең култык асты куыш була, аягы артка карап тора, йөрәге күренеп тора. Бер-бер тап булып кытыклый башласа, тәгәрәп киткән уңайга култыгының астына аягыңны тыгасың», – дип сөйли торганнар иде. Шулай итсәң, шүрәле үлә дә куя, ди», дип язып алынган халык авызыннан [Башҡорт халыҡ ижады, 1995, б. 55]. Татар халык

иҗатында да ул шулайрак тасвирлана: ир затыннан булган шүрәле мөгезле, ә хатыннар затыннан – шулай ук «салынкы имчәкле». Ике затның да озын тырнаклары була, имеш. Башкорт һәм татар демонологик образларына русларның ***лешие***, чувашларның ***арсурасы*** якынрак торадыр.

Г. Тукай шигырендә герой алай-болай итеп тормый, әлбәттә. Аның уенда бу заттан котылуның башка ысулы була. Шүрәленең:

*...Тик кытыкларга яралгандыр*
*Минем бармакларым,*
*Булгалыйдыр, көлдереп,*
*Адәм үтергән чакларым.*
*Кил әле син дә бераз*
*Бармакларыңны селкет, әй,*
*Яшь егет! Килче икәү*
*Уйныйк бераз кети-кети», –*

диюенә үз хәйләсен корып, түбәндәгечә шарт куя:

*... Сөйләем шартымны сиңа,*
*Яхшы тыңлап тор, әнә.*
*Шунда бар бит бик озын һәм*
*Бик юан бер бүрәнә...*
*Бүрәнәнең бер очында*
*Бар ачылган ярыгы,*
*Шул җиреннән нык кына син тот,*
*Әй урман сарыгы! –*
[Тукай, б. 58]

дип, агач ярыгына озын бармакларын тыгарга тәкъдим итә. Беркатлы зәхмәтле җан бармакларын ярыкка тыккан арада, егет ярыкны киереп тотып торган чөйне балтасы белән сугып чыгаруы була, тегенең бармаклары ярыкта кысыла да кала.

Егетнең урман иясен шулай хәйлә корып, алдап котылу мотивы «Алдар» дигән халык әкиятенә эксплицит сылтама ясап, шагыйрь әсәре белән әкият тексты арасында интертекстны (бәйләнешне) хасил итә. Чынлап та, «әкият хәйләкәре … теләсә нинди кыенлыклар алдында да югалып калмый…, үзенең үткерлеге, җитезлеге, тапкырлыгы белән балкып китүчән» [Сөләйманов, б. 171]. Телгә алган «Алдар» тибындагы хәйләкәрләр турындагы әкиятләрнең үзәгендә дә шушындый зирәк һәм үткер герой тора. Әкияттән исә, билгеле булуынча, шулай ук утынга дип урманга барган Әбҗәлил исемле егет әлеге шүрәлене хәтерләткән җен-шайтан белән очраша. Монда да герой алданып баручан хәйләсез урман иясен төрле шартлар куеп йөдәтеп, алдап китеп котыла [Башҡорт халыҡ иҗады, 1992, б. 28–30].

Шулай башкорт һәм татар халыкларына әкият һәм хорафатлардан билгеле булган шүрәле яки җен образын ярым юмор, ярым ирония аша җылы поэтиклаштырган да инде Г. Тукай.

Шүрәле яки җен-шайтанның беркатлы шөкәтсез зат булуы башкорт халык легендаларында да чагылган. Алардан котылуы да кыен түгел, имеш, тик зирәк һәм үткер генә булырга кирәк. Башкорт йола фольклорыннан билгеле булганча, аннан төрлечә котылып була икән. Мәсәлән, Башкортстанның Баймак районы Фәйзулла авылында Мәгирә Хәлитова (1910 елда туган) сөйләве буенча, Бөек Ватан сугышы алдыннан, печән чапканда, шүрәлегә тап булган. Аннан качып бара торгач, елга аша чыгуы була, шүрәле шунда ук артта кала. Баксаң, шүрәлеләр судан курка, имеш.

Урман иясенең шулай беркатлы булуы хакында Г. Тукай әсәре герое да «яхшы хәбәрдар». Ул да хәйлә белән эш итә. Аның бармакларын, алда әйтеп үтелгәнчә, агач ярыгына кыстыра да, үзенең исемен «Былтыр» дип әйтеп китә. Шушы җирдә шулай ук башкорт халык иҗаты белән аллюзия туа. Ул да булса – исеменнән үк аңлашылып торганча, шайтан тиклем шайтанны, шүрәле тиклем шүрәлене төп башына утырткан Алдар егет. Ул да үзен урманда кытыклап үтерергә ниятләгән шүрәлене охшаш ысул белән «эшкәртеп», үзен «Былтыр» дип атап китә. Егет, шулай итеп, халкыбызның борынгы ышану-инануына таянып, үзенең зирәклеген эшкә җигеп, акылга җиңелрәк беркатлы урман иясеннән котыла.

Күргәнебезчә, Г. Тукайның татар халык мифологиясенә нигезләнеп язылган «Шүрәле» әсәрендә чагылыш тапкан мифик затның да, шигырь корылган сюжетның да, асылда, халык иҗатына эксплицит аллюзия – сылтама барлыгы, шуның белән интертекст бәйләнешнең булдырылуы күзәтелә. Ике кардәш халыкның мифологиясеннән билгеле булган бу персонаж әсәрдә мәдәни антропология (культурная антропология) образы буларак күзаллана. Ягъни халыкларның борынгы мәдәниятендә сакланган образның тулы сынын поэтиклаштырып мәңгеләштерелүе белән кыйммәтле бу шигырь.

Гомумән, башкорт халык иҗатында шүрәле белән адәм затының үзара бәйләнеше хакындагы легендалар бихисап. Мәсәлән, «Шүрәле араһы», «Ярымтыҡ (шүрәле) нәҫеле» яки «Шүрәле кыуағы» кебек һәм башка антропономик, топонимик легендаларның булуы билгеле. Монда сүз кеше белән шүрәле кызының өйләнешеп, бала-чагалы булып, нәселнең дәвам итүе хакында бара.

Әмма сюжет уртаклыгы, тулылыгы булган хәлдә дә, мифик затның бер аермалы әгъзасы булуы ачыклана: ул да булса – маңгаендагы тырпаеп торган бердәнбер мөгезе.

Әлегәчә каралган «Башҡорт халыҡ ижады»ның академик басмасы булган «Йола фольклоры» томында шүрәленең мөгезле булуы хакындагы мәгълүмат табылмады. Башкорт халык әкиятләрендә дә бу хәл күзәтелми. Әмма моның хакында ремарка рәвешендә читләтеп кенә шуны әйтеп булыр иде. Татар халык иҗатында «татар» шүрәлесенең – урман иясенең, чынлап та, мөгезле булуы хакында билгеле» [Татар мифологиясы…, б. 25], диелә Фатих Урманче төзегән «Татар мифологиясе» энциклопедик сүзлегендә. Димәк, Г. Тукай

Шүрәлесенең дә мөгезе булуына гаҗәпләнерлек түгел, һәм бу хакта сүз куертып тору да файдасыз кебек. Әмма гомумән мифик кире затның мөгезле булу ихтималын безнең җирлектә шулай да күзәтергә мөмкин. Мәсәлән, бу үзенчәлекле мөгезле образ башкорт халкының «Курай тураһында легенда» яки «Курай тураһында әкият» дигән әкиятләрендәге мөгезле хан образына имплицит аллюзия тудырган. Әкияттән мәгълүм булганча, урманда яшәгән бер хан тирә-як авыл егетләрен үзенә хезмәткә алдырта да кире кайтармый икән. Алар киткән җиреннән гаип була, имеш. Баксаң, ханның мөгезен кырыр өчен алынган алар. Бу хәл олы сер булганлыктан, эшне башкарган һәр егет үтерелгән, ди. Ул мөгез исә очлы шеш кебек тырпаеп торган яки ханның маңгаенда тәкәнең мөгезедәй мөгез булган, имеш, дип әйтелә әкияттә [Башҡорт халыҡ әкиәттәре, 1952; 1956]. Мөгезле хан хакындагы әкият, асылда, мөгезле Искәндәр яки Александр Македонский хакындагы әкият һәм легендалар тибына караган сюжетлар белән уртаклык тудыра – интуитив рәвештә шул ишетелгәнне булса да искә төшерә. Әмма ничек кенә булмасын, Тукайның мөгезле Шүрәлесен башкорт һәм татар халыклары мифик аңының реминисценциясе дип танырга мөмкин. Ягъни поэмада уртак мәдәният универсалиен тәшкил иткән мифик образның сынландырылуы шиксез.

Г. Тукай төрки һәм башка халыкларның борынгы хорафатларында, ышануларында сакланган янә бер мифик зат – су анасы образына да мөрәҗәгать итә. Бәлки, чынлап та, «Су анасы» (1908) поэмасының исемендә билгеләнгәнчә, шагыйрьгә бу хәлне «бер малай авызыннан» ишетергә насыйп булган. Һәрхәлдә, укучы тарафыннан әсәрнең сюжеты кемнеңдер, ягъни малайның башыннан үткән хәл-вакыйгага корылган кебегрәк кабул ителеп, шуңа ышанырга мәҗбүр итә, янәсе. Асылда, шагыйрьнең максаты да шуннан гыйбарәт.

Бу әсәрдә сурәтләнгән су анасы мифик образы шулай ук кызыклы. Анда сүз, билгеле булганча, бер малайның су коенып йөргәндә, озын чәчен алтын тарак белән тарап утырган бер адәми булмаган, әмма хатын-кыз затыннан булган бер җанны – Су анасын күрүе, аның алтын тарагын кулына төшереп алып качуы һ.б. сурәтләнә.

Әйтергә кирәк, Су анасы образын татарда гына түгел, шулай ук башкорт, чуваш, мари һ.б. халыкларның хорафати карашларына нигезләнгән мифларда очратырга мөмкин. Мәсәлән, чуваш һәм фин-угор халыклары мифологиясендәге Һыу инәһе – ***Су анасы, Су бабасы*** яки Һыуһылыу – ***Су-сылу*** киң таралган герой. Чувашларда ул – ***Шыв амашы***. Бу халыкта Су атасы да бар, имеш. Ул да булса – ***Шыв ашше***. Шулай ук мифологик ышануларда су башлыгы – ***шывхуси***, ***шыври – водяной*** мәгънәсендә дә йөри. Ягъни су иясенең төрле «вазифасы» булган, дип белгәннәр. Галим С.Г. Кляшторный әйтүенчә, фин-угорлардан аларга күчкән ***Шыврызиың кызы – Вуташының*** булуы да, ихтимал [Кляшторный]. Һәм дә Вуташ, бездәгечә, сылу кыз төсендә озын чәчләрен алтын тарак белән тарап утырган, имеш [11]. Мариларда су анасы ***Вюд*** тип атала һәм ул йә сылу хатын-кыз, йә кар-

чык төсендә күзгә чалынган. Мари мифологиясе буенча, аның тарак белән тараган озын чәчле булуы да билгеле һ.б. [Иликаев, б. 28].

Башкорт халык иҗатына да бу персонаж таныш һәм эпосларыбызда Һыуһылыу образы буларак сынландырылган: Мәсәлән, «Акбузат» эпосында – Нәркәс, «Заятүләк белән Һыуһылыу»да Һыуһылыу буларак билгеле. Монда исә сылу бер дә кешеләрнең башына җитүче явыз, мәкерле заттан булып түгел, ә егетләрне үзенә гашыйк иттерерлек чибәр һәм ягымлы яшь кыз итеп тасвирлана. «Заятүләк белән Һыуһылыу» эпосында ул гадәттә «...күлдең ситендә генә яҫы таш өҫтөндә толомдарын таратып» тарап утырган килеш сурәтләнә. Менә шул толымнарыннан Заятүләк килеп тотып ала да инде. Әмма Г. Тукай шигырендә телгә алынган Су анасы озын чәчен тарап утырган алтын тарак исә башкорт җирлегендә чагылыш тапмаган диярлек. Эпосның 1964 елда Башкортстанның Әлшәй районы Мәкәш авылында Биктимер Вәлиуллиннан Мөхтәр Сәгыйтов язып алган чагыштырмача тулырак варианты исәпләнгән бер тексты белән «Башкирская русалка» исеме астында 1843 елда «Москвитянин» дигән журналда рус лексикографы һәм язучысы Владимир Даль тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, беркадәр тулыландырылган версиясендә генә Сусылуның әнә шул алтын тарак белән чәчен таравы хакында әйтелә [Башҡорт халыҡ ижады, 1998, б. 18; Даль, б. 182]. Эпосның башка вариантларында исә алтын тарак телгә алынмый, кызның чәч тарап яки тарап һәм үреп яисә бармаклары белән язып утыруы хакында гына әйтелә. Башка вариантларда хәтта кызның озын чәче бака ефәге, суүсем кебек суда уралып ятуы да телгә алына.

Эпоста алтын таракның телгә алынмавын халыкның алтынга әллә ни әһәмият бирмәве, шунлыктан хәтердән төшеп калуы белән аңлатып буладыр. Сусылуның, адәми зат кебек, чәчен тарап яки язып, үреп утыруы кызыграк һәм тормышка якынрак булып тоелгандыр. Эпик әсәрнең XIX гасыр урталарында ук теркәлеп дөньяга чыгарылган рус версиясендә алтын тарак образының телгә алынуы, бу эпос текстының борынгырак булуы хакында сөйләве ихтимал. Шулай булгач, димәк, 1964 елгы Әлшәй вариантының да шушы борынгы традицияне саклавы хакында сөйлидер. Соңыннан бу образның халык хәтерендә сакланмыйча (вак деталь кебек) телдән төшеп калуы мөмкиндер.

Г. Тукай поэмасындагы алтын тарак та, димәк, борынгырак, бәлки, сакраль карашка нигезләнгән. Тик әсәрдә ул, башкорт эпосындагы Сусылудан («Заятүләк белән Һыуһылыу») яки Нәркәстән («Акбузат») аермалы рәвештә, усал характер буларак сурәтләнә. Бу да – халык хәтереннән килгән күренеш. Борынгы мәҗүси караш буенча, алда санап үтелгән мифик затлар – урман-тау, су-күл, йорткаралты, мал ияләре, җен-пәри, мәскәй, убыр һ.б. изге заттан булып, дөньяны саклаучы ярдәмчеләр дип күзалланган. Ягъни эпосларыбызда бу чит мохит затларыннан булган Сусылуларның уңай геройлар рәтенә керүе эпик әсәрләрнең күпкә борынгырак булуы белән бәйледер. Ә инде ислам дине тарала башлагач, Х.Г. Күроглы әйтүенчә,

мондый мифик образларга усал төс бирелеп, чир-зәхмәтләр таратучы явыз көчләр – кире аллалар пантеоны рәтенә кертелгән [9]. Татар галимнәре (В.Я. Проппның «Исторические корни волшебных сказок» (1946) дигән китабына таянып) фикеренчә, Убырлы карчык, борынгы ышанулар нигезендә, мәсәлән, яшь егетләргә балигълык йоласын башкаручы (инициация) зат буларак изгеләштерелгән. Ә инде яңа дин таралып, иске тәртипләр бетерелгәч, мифик карчык кире типлар рәтенә кертелгән: аның кылган барлык эш-хәрәкәтләре явыз, кире эш дип беленә башлаган [Татар халык иҗаты, б. 11]. Шул заманнан алып төрки халыкларның рухи дөньясында мифик затлар демонистик төс алган. Чөнки ислам күп аллалыкны тыя һәм бер аллага табынуны, аңа гына гыйбадәт кылуны яклый һ.б. Күпчелек халыклар аңында бу үзгәрешләрнең охшаш рәвештә барлыкка килүе дә, урнашуы да әлеге мәдәният универсалияләре күренеше булуы белән бәйле.

Димәк, Г. Тукайның «Су анасы» поэмасында бу борынгы мифик зат күз алдына исламлаштырылган демонистик зат буларак килеп баса. Икенче төрле әйткәндә, бу очракта борынгы мәҗүси карашлы мәдәният икенче яки яңа мәдәни катлам – заман кешесенә таныш һәм якын булган, аның дөньяга карашы белән туры килгән ислам традициясе элементы белән азыкландырылган.

Ә Су анасының яман холыклы, ачулы бер зат булуы әсәрдә шулай белдерелә. Поэмадан билгеле булганча, Су анасы чәчен тараганнан соң, басмада алтын тарагын онытып, суга төшеп китә. Шуны күреп калган герой:

*...Инде мин акрын гына килдем дә мендем басмага,*
*Җен оныткан, ахыры, калган тарагы басмада.*

*Як-ягымда һич кеше лә юклыгын белдем дә мин,*
*Чаптым авылга, таракны тиз генә алдым да мин...*

Шулай йөгерә торгач, малай артына борылып караса, ни күзе белән күрсен, артыннан теге Су анасы бастырып килә, имеш:

*...Кычкыра ул: «Качма! Качма! Тукта! Тукта, әй, карак*
*Нигә алдың син аны, ул бит минем алтын тарак!»*
[Тукай, б. 103]

Су анасының затлы әйберенә кул сузганга көенеп, ничек тә аны кире кайтарып алырга сәләтле булуы хакында халыкның борынгыдан килгән ышану-инанулары да билгеле. Беренчедән, халыкта, гомумән алганда, төрле чир-зәхмәт, бәла-казадан, кире көч, мифик заттан булган җен кебек төрле ияләрнең шәхси әйберләренә кагылырга ярамаган; икенчедән, су өстендә аткан төнбоеклар су анасының әйберләре дип саналган һәм, әлбәттә, аларны өзү катгый тыелган. Югыйсә үч алулары яки төрле чир-зәхмәт таратулары ихтимал, дип белгәннәр [Башҡорт халыҡ иҗады, 1995, б. 58]. Шуның өчен дә Тукайда герой анасына алтын таракны кемнән чәлдерүен әйткәч, әнисе, куркуга төшә. Ә инде Су анасы төн уртасында килеп:

*...Һич өзлексез «шык» та «шык!» безнең тәрәзәне кага*
*Ул коточкыч чәчләреннән, чишмә төсле, су ага! –*

дип тәрәзә шакыгач, әни кеше *алтын таракны тиз генә эзләп табып, Атты да тышка, тиз үк куйды тәрәзәне ябып,* дип котыла таракттан. Ә инде геройның шулай арт сабагы укытылгач, *Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым, «Йә, иясе юк!» – дип, әйберләргә тими башладым,* дигән карарга килүе дә – әнә шул ышанулар һәм курку-тыелулар сөземтәсе. Ике мохит – кеше һәм башка тылсым, мифик, демонистик затлар дөньясы – арасында тигезлек (равновесие) бозылмасын өчен дә кирәк дип табылгандыр әлеге борынгы ышанулар, тыю һәм тыелулар. Монда шулай ук тирә-як мохиткә, табигатькә карата сакчыл карау, аның гармониясен бозмау кебек этнопедагогик тәрбияви төшенчәләрнең дә ятуы көн кебек ачык.

Гомумән, күпчелек халыклар мифологиясендә Су анасы, Шүрәле ише образлар халык аңында үзенчәлекле тудырылган. Ә. Сөләйманов әйткәнчә, «мифологик фикерләү сөземтәсендә, хыялда туган сихри затларны бабаларыбыз җанлы итеп күзаллаган» [Сөләйманов, б. 171]. Ахырда, шушы хыял һәм карашлар нигезендә кеше аңында төрле легендалар, хорафати хикәяләр туган. Үзе һәм иҗаты этнокультурология объекты буларак өйрәнелгән Г. Тукай да әнә шуларны әлеге поэмасында художестволы сурәтләгән дә инде. Халыкның мәдәни антропологиясе образлары булган шушы демонистик персонажларны җылы поэтиклаштыруы белән шагыйрь санап үтелгән мәҗүси карашлар, ышанулар теле, мәдәнияте охшаш халыкларның хорафати карашларын тулыландырып гармонияләштерә, рухи дөнья картинасының бөтенлеген, тулылыгын хасил итәргә мөмкинлек бирә, шуның белән мәдәният универсалияләрен баета.

**Әдәбият**

Башҡорт халыҡ ижады: Шаян әкияттәр һәм көләмәстәр / төз. Ә.М. Сөләйманов; баш сүз авт.: Л.Г. Бараг белән Ә.М. Сөләйманов. Өфө: Башҡ. кит. нәшр., 1992. 464 б.

Башҡорт халыҡ ижады: йола фольклоры / төз., баш сүз авт.: Ә.М. Сөләйманов, Р.Ә. Солтангәрәева. Өфө: Китап, 1995. Т. 1. 557 б.

Башҡорт халыҡ ижады: Эпос / төз. Ә. Сөләйманов; инеш мәҡәлә М. Сәғитовтыҡы; сүз ахыры Ә. Сөләймәновтыҡы; аңлатм. М. Сәғитов белән Ә. Сөләймәновтыҡы. Өфө: Китап, 1998. Т. 3. 446 б.

Башҡорт халыҡ әкияттәре / төз. А. Усманов. Өфө, 1952. 230 б.

Башҡорт халыҡ әкияттәре / төз. Г. Ишбулатов. Өфө, 1956. 260 б.

*Даль В.* Башкирская русалка // Башкирия в русской литературе. Уфа: Баш. кн. изд-во, 1989. 508 с.

*Иликаев А.С.* Мифы народов Башкирии. Боги и герои. Уфа: Вагант, 2012. 221 с.

*Кляшторный С.*Г. Летопись трех тысячилетий [Электронный ресурс] URL: http: //www. tatforum.info

*Короглы Х.Г.* Взаимосвязи эпоса народов Азии, Ирана и Азербайджана. М.: Наука, 1983. 355 с.

*Миңнуллин К.М.* Һәр чорның үз җыры. Казан: Мәгариф, 2003. 400 б.

Мифологический словарь / гл. ред. Е.М. Мелетинский. М.: Советская энциклопедия, 1990 г [Электрон песурс]: http://www.twirpx.com/file...

*Сөләйманов Ә.М.* Әкияттә хәкикәт: Башкорт тормош-көнөүреше әкияттәренең жанр составы, сюжет төрлөлөгө, тормош ерлеге. Өфө: Китап, 1997. Б. 171.

Татар мифологиясы. Энциклопедик сүзлек / төз., баш сүз, аңлатм. авт. Ф. Урманче. Казан: Магариф, 2008. 1 т. 303 б.

Татар халык иҗаты: Әкиятләр / төз., искәрмәләр авт.: Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярмин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 2 кит. 448 б.

*Тукай Г.* Шигырзар, поэмалар / төз.: С. Сафуанов, М. Сиражи. Өфө: Башк. кит. нәшр. 1986. 238 б.

***Хөббитдинова Нәркәс Әхмәт кызы,***
*филология фәннәре докторы, РФА Уфа федераль тикшеренү үзәге*
*Тарих, тел һәм әдәбият институты,*
*М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университетының*
*Башкорт фольклоры гыйльми тикшеренүләр үзәгенең*
*баш гыйльми хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*С.Г. Сәмитова*

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ИҖАТЫНДА МИЛЛИ ПРОБЛЕМАЛАРНЫҢ ГАИЛӘ ЯССЫЛЫГЫНДА ЧАГЫЛЫШЫ

## («Ул икеләнә иде» (1915) һәм «Ул өйләнмәгән иде» (1916) повестьлары мисалында)

Данная статья посвящена анализу повестей Гаяза Исхаки «Ул икеләнә иде» («Он сомневался»; 1915) и «Ул өйләнмәгән иде» («Он еще не был женатым»; 1916) с точки зрения рецепции и интерпретации проблем национального и религиозного аспектов межгендерных отношений. В рамках настоящей статьи нами было раскрыто, что Гаяз Исхаки был сторонником модернизации и прогрессивной трансформации татарского общества – в том числе через диалогическое восприятие достижений русской культуры. Однако при этом, как было нами продемонстрировано, писатель осознавал, что татарская нация находится под угрозой ассимиляции, ведущей к вырождению, исчезновению («инкыйраз») народа с богатейшим историко-культурным наследием. Выявлено, что в творчестве Г. Исхаки мотив борьбы за сохранение национальной идентичности на концептуальном уровне связан с женскими образами, что диктуется особой ролью женщины как хранительницы семейного очага. Изучение специфики взаимоотношений героев названных повестей Хамита и Марии, а также Шамси и Анны позволил определить позицию классика татарской литературы касательно перспективы смешанных браков: даже духовное родство, общность интересов и интеллектуального уровня не способны послужить надежным фундаментом для формирования гармоничной семьи, в которой сохранялась бы этноконфессиональная симметрия; доминирование в доме языка, менталитета, религии и культуры представителя более крупного народа, как указывает Гаяз Исхаки, неминуемо приведет к кризису семейной жизни.

**Ключевые слова:** татарская литература, Гаяз Исхаки, национальная идентичность, трансформация общества, религия и культура.

This article is devoted to the analysis of Gayaz Iskhaki's novels «Ul ikelənə ide» (1915) and «Ul əylənməgan ide» (1916) from the point of view of reception and interpretation of the problems of national and religious aspects of intergender relations. In the framework of this article we have revealed that Gayaz Iskhaki was a supporter of the modernization and progressive transformation of the Tatar society including through the dialogical perception of the achievements of Russian culture. However, at the same time as we have shown the writer was aware that the Tatar nation was under the threat of assimilation, leading to the degeneration, disappearance («inkyraz») of a people with a rich historical and cultural heritage. We found that in the works of G. Iskhaki the motive of the struggle for the preservation of national identity at the conceptual level is associated with female images which is dictated by the special role of women as the guardian of the family hearth. The study of the specifics of the relationship between the characters Khamit and Maria, as well as Shamsi and Anna allows us to determine the position of the classic of Tatar

literature regarding the prospect of mixed marriages: even spiritual kinship, common interests and intellectual level are not able to serve as a reliable foundation for the formation of a harmonious family in which ethno-confessional symmetry; the dominance of the language, mentality, religion and culture of a representative of a larger nation in the house, as Gayaz Iskhaki points out, will inevitably lead to a crisis in family life.

**Keywords:** Tatar literature, Gayaz Iskhaki, national identity, transformation of society, religion and culture.

Гаяз Исхакый – халкыбызны «өсте-башы бөтен, аш-суы иркен, йөзе-күзе күркәм, көе-җыры көчле, сүзе-соңы татлы, кыйланышлары килешле, җайлы, йөреше борынгы тугры» итеп күрергә теләгән әдип. Ул туган халкының үткәндәге фаҗигаларын якыннан белеп, аның бүгенге хәле өчен сызлана, шул хәлдән чыгуның юлларын табарга тырыша. Үзенең барлык гомерен шушы изге эшкә багышлый. Язучыны милләтнең торган саен ныграк торгынлыкка төшүе, киләчәгенең билгесез булуы, тәрәккыят юлына баса алмавы борчый. Ул милләтенең башка халыклар арасында дәрәҗәсен күтәрү турында хыяллана, өметләнә. Аның мәгърифәт, мәдәният, матбугат, әдәбият турында туктаусыз кайгыртуы, шул юлда үзен аямыйча хезмәт итүе – һәммәсе милләт мәнфәгатен кайгыртуын раслый. Бу яктан ул бөек Тукайның идеалларына аваздаш. «Милләт образауный кешеләргә һәм халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мәнафигыннан вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә гаҗиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ. Милләт аталарга, аналарга, мөгаллимнәргә, мөгаллимәләргә, мөрәббиләргә, чын мөхәррирлек табигатьләренә вә сәляхиятләренә мохтаҗ. Безнең милләт тә, башка милләтләрдәге кеби, хамисез, мәлҗаэсез, фәкыйрь вә эшче халыкларның файдаларына тырышучы, бик фәкыйрь кешене бер бай этенә алмаштырыр вакытлар үткәнен аңлаучы егетләргә мохтаҗ. Безнең милләт тә Пушкиннарга, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ. Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйләрендә булган чын мөхәррирләргә, бардакханәдән чыкмаган яңа милли шигырьләргә, музыкантларга вә гайреләргә, вә тереләргә мохтаҗ» [Тукай, б. 186]. Г. Исхакыйның бөтен төр эшчәнлегенең, иҗатының нигезен татарларның милләт буларак бөтенлеге, иминлеге мәсьәләсе тәшкил итә. Ул милли телнең, мәдәниятнең үсеш юлларын өйрәнә. Төрки-татарларның шушы хәлгә төшү сәбәпләрен чал тарихтан эзли. Үзенең дәүләтчелеге булган бу халык шундый кимсетелүләргә түзеп яшәргә тиешме, дигән сорауга җавап табарга тырыша.

Әдип үзенең күпкырлы (әдәби, иҗтимагый-сәяси, тарихи, фәлсәфи) эшчәнлеге аша халыкның иҗтимагый-рухи яшәешен, тормыш тәҗрибәсе һәм акыл зирәклеген, уй-омтылышлары һәм хыялларын яктырта; колониаль хәлгә төшерелгән татар халкына яшәргә, үзенең милли йөзен һәм рухын саклап калырга көч бирә.

XX гасыр башы татар әдәбиятының актуаль проблемаларын җентекләп өйрәнү барышында Г. Исхакый милләтне инкыйразга илтүче сәбәпләрне ача һәм хатын-кызлар мәсьәләсенә аеруча зур игътибар бирә. Хатын-кыз ролен гаилә яссылыгыннан киңрәк мәйданга, татар халкының иҗтимагый тормышында тоткан урынына басым ясап, берничә әсәр иҗат итә. «Теләнче кызы» (1914), «Мөгаллимә» (1913), «Остазбикә» (1915), «Зөләйха» (1917) һ.б. Г. Исхакый хатын-кызларны ирләрнең сөйгән хатыны итеп кенә түгел, бәлки милләт язмышын хәл итүче зыялыларны тудырып тәрбияләүче көч, ягъни милләтнең телен, традицияләрен алдагы буыннарга җиткерүчеләр буларак тасвирлый. Шушы хакыйкатьне аңлаган әдип, әлеге проблеманы яктыртып, «Ул икеләнә иде» (1915) һәм «Ул өйләнмәгән иде» (1916) повестьларын иҗат итә.

Гаилә, дәүләтнең мөстәкыйль бер өлеше буларак, милләт үсешендә хәлиткеч көчкә ия. Кеше бәхетен гаилә бөтенлеге белән бәйләп, әлеге әсәрдәге вакыйгаларны шәрехләү өчен, автор шәһәр мохитенә мөрәҗәгать итә. Бу дөрес тә. Биредә кеше инде милли тирәлектән киңрәк мәйданга чыга, ягъни башка халыклар белән тыгыз элемтәгә керә, аларның яшәү рәвеше һәм мәдәнияте белән очраша, заман цивилизациясе йогынтысына бирелә. Әйтергә кирәк, нигездә, кеше дәүләтнең төп халкы булган рус милләте белән аралаша һәм, үзен алардан ким итеп сизмәс өчен, аңлы рәвештә рус мохитенә тартыла. Бу хәл гаилә кору өлкәсендә дә үз юлын таба. Шунлыктан бүгенге көнгәчә актуальлеген югалтмаган (бәлки тагын да кискенләшкән генә) катнаш гаилә мәсьәләсе көн тәртибенә куела. Бу проблема милләтчел рухлы зыялыларны борчый. Г. Баттал татарлар арасында катнаш гаиләләр артуны тарихка бәйләп, «Русия инкыйлабыннан соң байтак зыялыларымыз мөселман кызлары арасында үзләренә тиң кызлар тапмадыкларыннан рус, поляк, француз яки яһүди кызларына илә өйләнмәккә башладылар», дип искәрмә биреп үтә [Баттал, б. 153]. Татар кызларын да егетләр кебек укытып, белемле итеп, дөнья күтәрлек дәрәҗәгә күтәрүне бу хәлдән котылуның бердәнбер чарасы итеп күрсәтә. Ул гына да түгел, хатын-кызлар гаиләдә генә бикләнмичә, татар халкының иҗтимагый тормышында да катнашырга тиешлеген ассызыклый.

«Ул икеләнә иде» (1915) һәм «Ул өйләнмәгән иде» (1916) повестьлары, исемнәреннән күренгәнчә, тематик һәм проблематик яктан, сюжет бирелеше һәм композиция төзелеше ягыннан да бер-берсенә бик якын, хәтта төп геройлары да бер-берсен кабатлый сыман. А. Әхмәдуллин язганча, бу әсәрләр «рус әдәбиятының тәэсире астында калып, үз милләте кызларына хурлап караган бер җаһилнең хәяте яки рус мәктәпләрендә укыганга һәм рус чаралары белән тәрбияләнгәнгә, үз милләтенә булган мыскыллы мөнәсәбәтләр»гә багышлана [Әхмәдуллин, б. 138]. Әсәрләрнең төп геройлары – Хәмит («Ул икеләнә иде») һәм Шәмси («Ул өйләнмәгән иде»). Икесе дә белемле, укымышлы татар егетләре. Егетләр белемне Петроград шәһәрендә

рус мәдәнияте нигезендә алган, рус мохитендә тәрбияләнгән. Шунлыктан аларның дөньяга карашы чит мәдәният һәм традицияләр йогынтысында формалашкан.

Ике герой үзләренә кәләш эзләү белән мәшгуль, тик әйләнә-тирәдә алар дәрәҗәсендә белемле, тәрбияле туташлар гына күренми. Хәмит башта халкыбыз йолаларыннан тайпылмый гына чибәр һәм укымышлы татар кызына өйләнергә ниятли: «Мәсәлән, ул шул шәһәрнең Фатыйманы алса? Әйе, Фатыйма бунын хатыны булса?.. Төсе-буе... Зарарсыз...

Әллә Хәдичәме? Хәдичә моның хатыны булып, шулай менә бүген Габдрахманнарда булган кебек, хуҗа булып, кунаклар каршы алырмы?.. Бер-бер нәрсә йитмәсә, ябык кибетне ачтырып китерергә асрауны йибәререме?» [Исхакый, б. 315]. Бу хыяллары белән ул икенче повестендагы Шәмсигә бик якын. Ул да бит ике баласы туганнан соң да үзен буйдак егеткә санап, һаман да алдагы көндә күркәм татар кызына өйләнүенә өметләнә, булачак кәләшен чит шәһәрләргә барып эзли, таныша. Тик кызлар белән күрешеп аралашкач, күңелендә йөрткән «кием-салым йөртә белүче, йорт тотарга өйрәнгән, уңган, матур» [Исхакый, б. 316] милли туташ образы эреп юкка чыга. Татар кызлары тәрбиясенең йорттан гайре китә алмавы, аларның гади генә темаларга да әңгәмә кора белмәве сәбәпле, каһарманнарның татар кызларына мөнәсәбәте кискен үзгәрә.

Бу ике әсәрендә дә автор милли туташлар белән рус кызлары арасында параллель үткәрә һәм бу чагыштыру, әлбәттә, беренчеләре файдасына түгел. Г. Исхакый бу әсәрләрендә татар милләтен хурламый, ул аның белем, мәдәнилек дәрәҗәсен кимендә рус милләте белән янәшә торырлык биеклеккә күтәрү зарурлыгын исбатлый. Милли туташлар арасында Анна Васильевна яки Мария Ивановнага тиңләрлек кызлар булса, Хәмит белән Шәмси читтән эзләрләр идеме икән?!

Г. Исхакый ирекле мәхәббәт темасын да читләтеп үтми. Бу күренешнең тумыштан сабыр, итагатьле татар кызлары арасына үтеп кермәвен күрсәтә. Кызларның халкыбыз традицияләренә таянып яшәвенә хәтта шатлана, тик алдынгы фикерле Хәмитнең күңелен мондый «тәрбиялелек» белән генә яулап алу мөмкин түгеллеген дә ассызыклый. Хәмит кыз белән янәшә барганда, үзен ахмак итеп хис итә һәм бу уйлары аның ачуын чыгара, ә кызның «инсафлылык өчен башын иеп, чалышрак чүмәкләп, чүкәләп, бүксәсенә тутырган үрдәк кебегрәк чайкалып-чайкалып» атлап килүе [Исхакый, б. 316] Хәмитнең ачуына соңгы тамчы була һәм ул бар нәрсәне ташлап, беркемгә дә әйтми кайтып китә. Бу мәхшәрдән котылгач, янәдән Мария Ивановнаны искә төшереп, күңеленә сихәт ала һәм бүләкләр алып, алдагы көннәргә планнар төзи башлый. Бу планнар инде Мария Ивановна белән тыгыз бәйләнә.

«Ул әле өйләнмәгән иде» повестеның төп герое Шәмси бернинди икеләнү кичерми, чөнки ул татарда зирәк, укымышлы кызның булуы мөмкин түгел, дигән фикергә Касыйм шәһәре кызы белән аралашкан-

нан соң килә: «Тукай шигыре, Тукай шигыре дип сөйләгәндә, – Тукай соң ул кем? – дип, Шәмсине хәйранга калдырды. Тукайның кемлеген, хәзер кайда торганын белмәгән бу татар кызының кай төшендә татарлыгын эзләп йөри?» [Исхакый, б. 17].

Тукайның кем икәнен белми торган милли туташларның, әлбәттә, рус мәдәнияте, рус мохите тәрбияләгән мондый зыялы егетнең игътибарына лаек була алмавы бәхәссез.

Татар әдәбияты тарихына күз салсак, бу чорда татар кызларының асыл образларын күрсәтергә мөмкин. «Тупас Мамайның монгол йөзле нәселендә шундый» дип, Хәяткә хәтта алдынгы фикерле рус егете дә гашыйк була [Әмирхан, б. 129].

Әсәр тукымасыннан күренгәнчә, Шәмси кызлар белән аралашып карый, тик аны гел «Татлы җимеш» – рус кызы тартып тора. Башта ул бу гамәлне «Мин өйләнмәгән бер егет, ул бер хөр хатын», дип кабул итә һәм бу очрашуларда бернинди дә хилафлык күрми, әлеге мөнәсәбәтләрнең вакытлы булуына, үзенә тиң татар кызын очрату белән бу эшкә нокта куелачагына ышана. Аның фикеренчә, бу очрашулар – нибары рәхәт кичерү өчен генә. Аннары ниндидер үзенә генә хас сөю белән яратса да, «әти, әнисе белсә, бит котлары очачак, дуслары ишетсә, бит дөньяга күренә алмаячак» дип, аның белән кавышу мөмкин түгеллеген дә аңлый [Исхакый, б. 354]. Икенче героебыз Хәмит бу хакта: «Ул өйләнде, ди. Дуст-ише аны тәбрикләп килә. Килмәсә? Бу бит марҗага өйләнү... Кардәш-кабилә туйга җыела... Нинди туй? Марҗа белән туй буламыни? Тагы алар берсе дә килмәсә? Килмәсә генә түгел, моның өйләнүене өйләнү дип карамаенча, тик марҗа белән тору гына, тәүфыйксызлыктан килгән бер бәхетсезлек дип караса?» – дип, шөбһәләнә [Исхакый, б. 334]. Шул ук вакытта үз-үзенә каршы килеп: «Аларның алай карарга ни хакы бар? Сөю, мәхәббәт милләтне белми. Аңарга байлык та, ярлылык та киртә-кальга була алмаган кебек, милләт, дин аермасы да аны тотып кала алмый. Мин сөйгәч, кемнең хакы бар?» [Исхакый, б. 334]. Һәр икесе шундый амбивалент утта яна: бер яктан, хатыннарга булган ярату-сөю хисе, икенче яктан, чит мохиттә үсүгә карамастан, гаиләдә тәрбияләнгән милли аң һәм дини хисләр.

Хәмит белән Шәмси – чын мәгънәсендә татарның алдынгы яшьләре, алар чорына күрә укымышлы, зыялы, татар голәмәсе белән тыгыз бәйләнештә. Геройларның төрле милли кичәләргә, театрларга йөрүе, дини бәйрәмнәрдә катнашуы, нәсел-нәсәп белән хисаплашуы, туганнар-дуслар фикеренә игътибар итүе – аларның татар тормышыннан читләшмәвенә ачык мисал. Руслар белән янәшә яшәп, аларның алдынгы гамәлләрен үзләштерүгә карамастан, икесе дә – милли традицияләр һәм дини кануннарга таянып эш итүче кавемнән чыккан егетләр.

Сюжет сызыгы Шәмси белән Аннаны елга ярына илтә. Сихри табигать кочагында рәхәт ял итү дәвамында мөнәсәбәтләрнең кабул ителгән әхлак чикләреннән чыгып китүен Шәмси («Ул әле өйләнмә-

гән иде») аңламый да кала сыман. Ул мәхәббәт хисенә бирелеп, Анна белән якынлык кыла, ә Анна Васильевна исә, тәҗрибәле хатын буларак, егетне үз кармагына нинди юл белән каптырып булганны яхшы аңлый, ул балага уза. Димәк, өйләнү-өйләнмәү мәсьәләсе Шәмсинең аңлы рәвештә фикер йөртүеннән элек, җенси ләззәт, инстинкт хөкеме нәтиҗәсендә хәл ителә. Хәмит («Ул икеләнә иде») исә бу фикергә тынгысыз көннәр, йокысыз төннәр аркылы килә. Хәмитне биләп алган хис әсәр дәвамында ныгый, үсә бара. Бу – икеләнү, шикләнү хисе. Аны кешенең фикерләү сәләте тудыра. Аны үз-үзеңә булган эчке ышанычның җитеп бетмәве, шәхес буларак үзен түбән бәяләү кебек сыйфатлар тудыра. Икеләнү дөрес карар кабул итүне тоткарлый. Кеше никадәр икеләнсә, шулкадәр үз мөмкинлекләренә ышанычы кими, һәм ул дөрес тәнкыйди фикерләп кабул ителгән карарлардан читкә китә, ә ашыгып эшләгән гамәлләр, нигездә, ялгыш нәтиҗәләргә китерә. Шундый икеләнү нәтиҗәсендә Хәмит тә Мария Ивановнаны үзе өчен иң кулай пар саный: «Нинди һәйбәт, инсафлы, мәхәббәтле кыз. Шундыйны кайдан табасың?» – дип уйлый. Гаяз Исхакый Хәмитнең эчке халәтен, кичергән шик-шөбһәләрен нечкә психологик штрихлар ярдәмендә сурәтли. Ул кабат-кабат уйлана, үзенчә төрле яклап тикшерә, алдагы көннәрен дә күз алдына китерә. Бар теләге – Мария Ивановнаны сайлауның иң дөрес юл икәненә башта үзен ышандыру, аннан инде әйләнә-тирәдәге якыннарын. Үзе өчен бинибая күп дәлилләр китерә, хәтта үзе дә шуңа ышана, тик тынычлану гына килми. Үзенә: «Мария Ивановна иптәш булмыймыни? ... Җомга көн иртә белән ул пәрәмәч китерерме? Гарәфә көнне ул бәйрәм ашы ясый белерме?» – дигән сорауларга җавап эзли.

Әсәрләрдән Г. Исхакыйның геройларын тирән тоеп, алар белән янәшәдә генә «яшәп» иҗат иткәнлеге аңлашыла. Геройларның эчке халәтен ачуда ул пейзаж кебек лирик чигенешләрне эшкә җигә. Бөтен әйләнә-тирә табигать тә Хәмит белән Шәмсинең кичерешләренә органик кушылып сыкрый, әйтерсең лә алар яшь күңелнең, канатлы хисләрнең, җәмгыятьнең кыргый законнары басымы астында изелгәнлегенә тавышсыз гына сулкылдыйлар, ике яшь күңелдә дөрләгән мәхәббәт хисләрен хуплыйлар, аларга теләктәшлек итәләр.

Шәмсине бала турындагы хәбәр өнсез итә. Аның рухи халәтен әдип үтә җете буяулар ярдәмендә тасвирлый: «...тормышның шул фактысы алдында тез чүкте. Ләкин ике арага, әллә нигә, бер суыклык катышты. Шәмсинең күңеленең бер кырыенда Анна аның бәхетене урлаучы, аны мәңгегә өйләндермәенчә, никахсыз калдыручы кебек иттереп килеп басты. Җылыда беленми торган салкын бер боз очратты...» [Исхакый, б. 358]. Ни гаҗәп, бу хәлләрдән соң да ул Анна белән гаилә төзү турында уйламый, аны бары өйләндермәүдә гаепли. Моны гаиләдәге тәрбия белән аңлатып булыр иде. Чөнки мөселман кешесе, ислам кануннарыннан башка гаилә төзүне мөмкин эш дип тә уйламый, гәрчә инде ул күптән рус хатыны белән ир-хатын мөнәсәбәтләрендә яшәсә дә. Шул рәвешле ул бала өчен җаваплылык

алырга әзерләнә. Бу хакта ул беркемгә дә әйтми, әти-әнисеннән, туган-тумачалардан читтә Шәмсинең гаилә хәле үзенең теләү-теләмәвеннән бәйсез хәл ителә. Язмышка буйсынуына карамастан, ул һаман уйлана, хыяллана. Туачак балага атасының исемен биреп, мөселман итеп тәрбияләү теләге белән яна. Анна да бит бик тырыша: төрле милли бәйрәмнәргә ашлар әзерли, бәйрәмгә хәтта хәзрәтне чакыра. Ул бөтен барлыгы белән татар дөньясына керергә омтыла, әмма бу эшләрнең файдасы гына тими, чөнки Шәмсинең марҗа белән торуы турында сүз башта колактан колакка гына сөйләнсә, соңрак мәйданга чыгып, ачык итеп сөйләнә, аннан акрынлап дуслары читләшә, ул үзе дә, оялып, халык күп йөри торган урыннарга бармый башлый.

Алга таба реаль тормыш барыбер үзенекен итә. Анна бер-бер артлы балалар таба, ирен дә, өен дә карый, һәммәсенә өлгерә, өзгәләнә, тормыш итә, Шәмси исә тормышны уңайлы-җайлы итү өчен бөтен көчен-куәтен кызганмый. Ләкин рухи яктан алар арасында үтеп чыга алмаслык упкын хасил була, еллар узган саен, ул тирәнәя, зурая гына бара. Гасырлар буе буыннан буынга күчеп килгән милли хис, дин тәрбиясе аларның икесенең дә күңеленнән бер генә минутка да китми, киеренкелек тудыра.

Шушы ук хисләр белән Хәмит тә яна. Автор геройларның, җан тынычлыгы эзләп, Корьәнгә мөрәҗәгать итүләрен, елый-елый намаз укуларын тасвирлый.

Вакыт уза, тормыш үзенекен итә. Анна да акрынлап чиркәүгә якыная, христиан бәйрәмнәренә үзе белән балаларын да ияртеп йөри башлый. Көннәр буе гаиләне матди яктан тәэмин итү артыннан йөргән Шәмсинең балалары татарча «әти» , «әни» дигән сүзләрдән гайре берни белми үсәләр. Шулай булуга карамастан, Шәмсинең күңелен балаларын мөселман итү хыялы һаман рухландырып тора. Ләкин очраклы рәвештә әниләре белән чиркәүдән чыгуларын күрү аны ихтыярсыз итә. Ул ни эшләргә белми, Мәскәү поездына утырып, туганнарына китә. Ул туганнары аңа кәләш сайларга ярдәм итәр дип уйлана, тик балаларын чукындыру күренеше күз алдыннан китми.

Мулла кызына өйләнергә киткән җиреннән Шәмси кабаттан Аннасы һәм балалары янына кайта. Хатынының хәйләкәр адымы аның Шәмсигә юллаган хатында ачыла. Ул ирен бөтенләй ачуланмый, бары балаларының һәм үзенең сагынуы турында яза һәм кызларының фотосурәтен дә сала, Шәмсине яңалык көткәнен, ягъни угыл табачагын хәбәр итә.

Әсәр катнаш никахтан нинди балалар туа, дигән сорауга җавап бирә. Баланың гаиләдә кем булып үсүен ул анага бәйләп аңлата. Христиан дине, рус милләте традицияләре ярдәмендә тәрбияләнгән хатынның татар милләтенә балалар тәрбияләве бик шикле. Телне, гореф-гадәтләрне, ислам динен белмәгән кеше ничек итеп мөселманча тәрбияләсен. Ә катнаш никах бәхет китерәме? Г. Исхакый бу повестьлары мисалында әлеге сорауга җавап эзли. Җавапны тирән психологизм аша таба. Ике конфессия вәкиле корган гаилә бәхетле була

алмый, дигән фикерне үткәрә. Әгәр психология фәненә мөрәҗәгать итсәк, шушы проблема гаилә кризисларының иң беренчесе итеп күрсәтелә. Икенче кризис бала тугач башлана. Бусы инде – балага исемне кайсы дин кануннарына таянып кушу мәсьәләсе. Г. Исхакый бу сорауга: «...тәрбия белән кем шөгыльләнә, шул билгели баланың милләтен дә, динен дә», – дип җавап бирә.

Дини һәм милли каршылыкларга нигезләнгән гаилә мәсьәләсен яктыртып, әдип проблеманың иҗтимагый-сәяси һәм рухи асылын ачып бирә, әлеге күренешнең фаҗигага илтүен үзенең геройлары мисалында исбатлап, мондый гаиләнең киләчәге юк, дигән фикерне үткәрә.

**Әдәбият**

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр. 4 томда. 2 т.: повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 478 б.

*Әхмәдуллин А.* Гаяз Исхакый әсәрләренең исемлеге // Казан утлары. 1989. № 6. Б. 137–138.

*Баттал Г.* Казан төркиләре (тарихы)// Казан утлары. 1995. № 3. Б. 151–184.

*Исхакый Г.* Ул икеләнә иде. Повесть // Мирас. 1998. № 1. Б. 11–21.

*Исхакый Г.* Зиндан. Сайланма проза һәм драма әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 660 б.

*Тукай Г.* Әсәрләр. 5 томда. 2 т.: Шигырьләр. Поэмалар. (1909–1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 399 б.

*Тукай Г.* Әсәрләр. 5 томда. 3 т.: Проза. Публицистика. (1904–1906). Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 341б.

***Сәмитова Сәвия Гималтын кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан милли тикшеренү технология университетының ике телдә укыту кафедрасы доценты*

УДК 821.512.145

***Р.Ф. Сафиуллина***

# ТАТАР ШАГЫЙРЕ ГАБДЕЛҖӘББАР КАНДАЛЫЙ ШИГЪРИЯТЕНДӘ ӘДӘБИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР: ЗАМАНЧА КАРАШ

В 2022 году исполнилось 225 лет со дня рождения выдающегося татарского поэта Г. Кандалый. Это знаковое событие для татарской гуманитарной науки, культуры и искусства. Творчество поэта стало важным этапом в переходе татарской литературы от Средневековья к Новому времени. В то же время творчество поэта сыграло важную роль в интеграции татарской литературы с литературой мусульманского Востока.

В статье обращается внимание на то, что татарская литература обогащалась, пользуясь общими тюркскими сокровищами, внося при этом значительный вклад в общетюркскую сокровищницу. Автор рассматривает роль татарского поэта Габдельджаббара Кандалый в процессе интеграции литератур. Особое внимание в статье уделено на то, что поэт в своем творчестве с юных лет был приверженцем традиции общения литератур. В качестве примера приводятся ранние поэмы Габдельджаббара Кандалый «Рисаләи-л-иршад» и «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм». Автор подчеркивает, что данные поэмы созданы в традициях суфийской и религиозно-дидактической литературы мусульманского Востока. Это связано с тем, что с официальным принятием религии ислам Волжской Булгарией в X веке, татары стали тесно взаимодействовать не только с тюркскими, но и арабо- и персоязычными народами, имеющими единую религию и письменность. Взаимодействие, прежде всего, основывалось на культурных и литературных связях. Автор приходит к выводу, что творчество Г. Кандалый явилось своеобразным связующим звеном, мостом между татарской литературой и литературой Востока.

**Ключевые слова:** татарская литература, Габдельджаббар Кандалый, поэма «Рисаләи-әл-иршад», «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм», принятие ислама Волжской Булгарией.

2022 marks the 225th anniversary of the birth of the outstanding Tatar poet G. Kandaly. This is a significant event for the Tatar humanitarian science, culture and art. The poet’s work marked the transition of Tatar literature to a new level, became an important stage in the transition of Tatar literature from the Middle Ages to the New Age. At the same time, the poet’s work played an important role in the integration of Tatar literature with the literature of the Muslim East.

The article draws attention to the fact that Tatar literature was enriched by using the common Turkic treasures, while making a significant contribution to the common Turkic treasury. The author examines the role of the Tatar poet Gabdeljbbar Kandaly in the processes of literature integration. Particular attention is paid to the fact that the poet in his work from a young age was an adherent of the tradition of communication between literatures. As an example, the early poems of Gabdeljbbar Kandaliy «Risali-l-irshad» and «Kyyssai Ibrahim Addham» are given. The author emphasizes that these poems were created in the traditions of the Sufi and religious-didactic literature of the Muslim East. This is due to the fact that with the official adoption of the religion of

Islam by the Volga Bulgaria in the 10th century the Tatars began to closely interact not only with the Turkic but also with Arabic and Persian-speaking peoples who have a single religion and script. The interaction was primarily based on cultural and literary ties. The author comes to a conclusion that the work of G. Kandaly was a kind of link, a bridge between the Tatar literature and the literature of the East.

**Keywords:** Tatar literature, Gabdeljbbar Kandaly, poem «Risalai-l-irshad», «Kyyssai Ibrahim Addham», adoption of Islam by the Volga Bulgaria.

2022 елда мәшһүр татар шагыйре Габделҗәббар Кандалыйның тууына 225 ел тулды. Татар гуманитар фәне, мәдәнияте һәм сәнгате өчен бу – гаять мөһим вакыйга. Шагыйрьнең иҗаты татар милли әдәбиятын, сәнгатен яңа дәрәҗәгә күтәрде, кыскача гына әйткәндә, Г. Кандалый иҗаты татар әдәбиятының урта гасырчылыктан яңа заманга күчүендә мөһим бер этап иде. Шул ук вакытта аның иҗаты татар әдәбиятын Көнчыгыш әдәбияты белән тоташтыруда да күпер ролен үти.

Мөселман динендәге Шәрык халыкларының телләре, әдәбиятлары элек-электән үзара аралашып, уртак кануннар буенча яшәгән, биниһаят зур уртак пространствода үсеш алган. Аеруча төркиләр әдәбияты гомуми бер зур мәдәни мирасны формалаштырган. Әлеге саекмас хәзинәдән төрки халыклар, шул исәптән татарлар да, үзләрен кызыксындырган дәрәҗәдә файдаланган да, уртак мирасны үзләреннән өлеш кертеп баеткан да. Татар әдипләреннән Г. Кандалый иҗатын әдәбиятлар аралашу кебек күркәм тарихи традициянең бер чагылышы итеп карый алабыз.

Шагыйрьнең биографиясен искә төшереп үтик. Г. Кандалый 1797 елда Самара губернасының Ставрополь өязе (хәзерге Ульяновск өлкәсе Иске Майна районы) Иске Кандал (Иртуган) авылында мулла гаиләсендә дөньяга килгән [Сафиуллина, 2007, б. 3]. Шагыйрьнең «Кандалый» дигән тәхәллүсе авыл исеменнән алынган. Габделҗәббар үз нәсел шәҗәрәсен: Йосыф – Ибраһим – Биктимер – Ибниәмин – Габделмәҗид – Габделҗәббар дип теркәп калдырган.

Башлангыч белемне булачак шагыйрь үзенең атасыннан – авыл имамы Габделмәҗид хәзрәттән алган. Булачак шагыйрь белем эстәүне Идел буенда мәшһүр Кышкар, Оры, Шонталы һ.б. мәдрәсәләрдә дәвам иттергән. Г. Кандалыйның беренче шигъри тәҗрибәләре шәкертлек чорына карый. Әйтергә кирәк, элек заманнарда татарлар арасында шагыйрьлеккә юл шул рәвешле – дини белем алудан, шәркыймөселман әдәбияты белән танышудан башланган. Г. Кандалыйның татар, гарәп, фарсы, төрек, рус, чуваш телләрен белүе, татар әдәбиятыннан һәм фольклорыннан, Шәрык мәдәниятеннән яхшы хәбәрдар булуы мәгълүм. Г. Кандалый 1824 елдан туган авылында мулла булып тора, балаларга белем бирә. 1843 елда авылда икенче бер мәхәллә ачып, соңыннан анда имам вазифасын үти. Укымышлы һәм шигъри сәләтле Г. Кандалый табигате белән хис-тойгыларга бай һәм тынгысыз холыклы, туры сүзле һәм хөр фикерле кеше була. Холкына мөнәсәбәтле рәвештәме, әллә башка сәбәптәнме, шагыйрьнең кулга алынып, ике елга якын гомерен зинданда үткәрүе мәгълүм. Зинданда

утыру еллары төгәл генә билгеле булмаса да, шагыйрьнең тоткынлыкта Суфи Аллаһиярның «Сөбат әл-гаҗизин» поэмасына хашия (аңлатмалар) язуы турында мәгълүмат сакланган. Әлеге факт та Г. Кандалыйның Көнчыгыш әдәбияты белән ныклы бәйләнешен, төрле телләр һәм әдәбиятлардан белемнәре саллы булуын раслый.

Шагыйрь-хәзрәт үз авылында гомер кичерә, 1860 елда 63 яшендә бакыйлыкка күчә һәм Иске Кандалда дәфен кылына. Шулай итеп, шагыйрь ярты гасырга якын иҗат итә. Ул зур күләмле поэмаларны да, кыска җыр-такмакларны да, икеюллык афоризм-шигырьләрне дә бердәй оста, күңел биреп язган. Мисал өчен, аның «Вакыт һәм якут», «Кайгыга дәва», «Белсә һәм белмәсә», «Аерма» һ.б. ике-, дүртьюллыклары – фикер һәм мәгънә тыгызлыгы, шигъри сәләт ягыннан осталык һәм камиллек үрнәге санала:

Якутлар табыладыр вакыт берлән,
Вакытлар табылмыйдыр якут берлән...
[Кандалый, б. 96]

Г. Кандалый әдәбиятка XIX гасырның беренче дистәсе азагында килеп кергән. Мәдрәсә шәкерте булган чагыннан ук инде зур күләмле шигъри әсәрләр иҗат итә башлаган. Шагыйрьнең беренче шигъри тәҗрибәләре – нигездә, борынгы шәркый шагыйрьләр әсәрләренә нәзыйрә. Шуларны ук төрки-шәркый мөселман халыклары арасында мәдәни багланышларның конкрет мисалы итеп тә китерә алабыз.

Г. Кандалыйның иҗаты традицион рухтагы, дини-әхлакый, дидактик эчтәлекле әсәрләр язудан башлана. Габделҗәббар шәкерт чагыннан ук мөселман-Көнчыгыш әдәбиятын, суфи шигъриятен яхшы белгән һәм нечкә шигъри зәвыкка ия булган. Аның табигый талантыннан тыш, суфи әдәбиятын оригинал телләрендә укуы, дин канунnarын, ислам тарихындагы мөһим шәхесләрнең тормышын һәм эшчәнлеген белүе дә ярдәм иткән. Әлбәттә, суфи шигъриятен өйрәнгәндә Габделҗәббар Шәрык шагыйрьләре кулланган темалар уртаклыгын, образларның билгеле бер формулаларга, төп төрләргә кайтып калуын үзләштерә, аларны үз иҗатында актив рәвештә куллана. Мәсәлән, аның әүвәлге поэмаларында да, җитлеккән чор шигырьләрендә дә мәхәббәт темасы киң чагылыш таба. «Рисаләи-әл-иршад» һәм «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмаларында бу – Аллаһка мәхәббәт. Шагыйрьнең соңрак язылган әсәрләрендә – шулай ук мәхәббәт, ләкин монысы инде – суфи шигъриятенә хас символлар һәм образлар ярдәмендә үз тойгыларын гади татар кызларына белдерү. Шагыйрь иҗатында суфи поэзиясенең тагын бер традицион мәкамәсе (чагылышы) – сабырлык. Суфичылык шигъриятендә суфи, үзендә түземлек һәм сабырлык сыйфатларын үстермичә, илаһи (Аллаһка) мәхәббәткә ирешә алмый. Шул рәвешчә, Г. Кандалый яшь чагыннан ук татар әдәбиятын борынгы һәм кыйммәтле шәркый әдәбият алымнары, символлары белән баетып, әлеге байлыкны киредән уртак төрки-мөселман әдәбиятына трансляцияләүче булды.

Г. Кандалый «Рисаләи-әл-иршад» («Тугры юлга күндерүче китап») исемле зур күләмле (барлыгы 28 бүлектән тора) дини-дидактик поэмасында, мәсәлән, кешеләрнең үз-үзләрен тоту кагыйдәләре, башкалар белән мөгамәләсе, әдәп-әхлак мәсьәләләре, гаилә-никах, балалык чоры, ир-хатын мөнәсәбәтләре; тәмуг һәм җәннәт; җәннәт нигъмәтләре һ.б. хакында сүз алып бара. Поэма атаклы фарсы шагыйре Фәрид-әддин Гаттарның «Пәнднамә»сен, шулай ук башка суфи шагыйрьләрнең, беренче чиратта, вәгазь һәм нәсыйхәт традицияләрен дәвам иткән.

Әсәрнең максаты автор тарафыннан башисемдә үк декларацияләнә: «Рисаләи-әл-иршад»ны «вәгазьләр китабы» дип тә тәрҗемә итәргә мөмкин. Үзенең нәсыйхәтләренең адресаты итеп шагыйрь мәгърифәтле һәм шул ук вакытта тормышта үз юлын, урынын эзләүче, яшәү мәгънәсе турында уйланучы кешене күрә:

Нәсыйхәт дыңлаган угълан
Зәляләтдин үзен йолган,
Сәгадәтне ала куйган –
Һидайәт эчидә улган.

[Кандалый, б. 246]

Нәсыйхәт һәм вәгазь – борынгыдан ук мөселман халыкларында сүз иҗатының иң киң таралган төрләреннән. Үгет-нәсыйхәт һәм вәгазь, шигъри калыпка кертелгәч, дидактик лирикага әверелгән. Ислам дине төрле дәүләтләргә киңрәк таралган саен, гарәп һәм фарсы суфи шигърияте нә хас жанрлар, стиль, сурәт һәм сюжетлар системасы төрки телле халыкларның әдәбиятын һәм халык иҗатын баетты. Борынгы Көнчыгыш шагыйрьләрен һәм фикер ияләрен кешенең әхлагын камилләштерү, белем бирү һәм тәрбияләү, кешенең асылы һәм җәмгыятьтәге урыны һ.б. ничек борчыган булса, X гасырда Идел Болгарында ислам дине дәүләт дәрәҗәсендәге дин буларак кабул ителгәннән бирле, бу мәсьәләләр дини-дидактик шигырьләр иҗат иткән татар шагыйрьләрен дә борчый. Уртак төрки телле, гарәп имлялы халыклар арасында татар әдәбияты да, борынгы дәүләтебезгә ислам килгәннән бирле, үз һәм якын. Шул рәвешле, татар әдәбияты милли кысалар чиген узып, еракларга таралды. Моны татар шагыйрьләренең бихисап нәзыйрә һәм оригиналь әсәрләре, шулай ук дини фольклорның зур үсеш алуы раслый.

Димәк, дини-дидактик поэмалар язган Г. Кандалыйны да әдәбиятта Көнчыгыш һәм үзебезнең милли җирлек өчен уртак шәркый-мөселман традицияләре тарафдары, чын-чынлап иҗтиһат итүче, дип карыйбыз.

«Рисаләи-әл-иршад» поэмасында автор татар, гарәп, фарсы һәм төрки телләрдәге чыганакларга нәзыйрә формасында мөселманнарның балачактан алып картлык көннәренә кадәр дөньялык вә ахирәт өчен күркәм холык-әдәпләре турында сөйли, тәкъвалык һәм күркәмлеккә үгет-нәсыйхәт алып бара, дип, тормыш, яшәеш хакында үзенең күзаллауларын бәян итә [Сафиуллина, 2007, б. 45].

Әсәрдә бәндәнең (лирик каһарманның) кылган хата-гөнаһларына үкенү, тәүбә мотивлары тулып ята. Әлеге мотивларны без суфичыл әдәбиятка хас мәләмәтия күренеше – лирик геройның үз-үзен, Кодрәтле Аллаһның мәхлук бер колы буларак, гөнаһлы һәм зәгыйфь бәндә икәнлеген тануы, тәнкыйтьләве – белән бәйләп карый алабыз. Мәсәлән:

Халем дишвар, улып закъәт,
Тәнемдә зәррә йук такъәт,
Ки юктыр кыйлдыкым тагъәт,
Вә ләкин әйләдем тогъйан.

[Кандалый, б. 313]

Бу күренеш дини-дидактик поэзиягә хас. Аның мәгънәсе: кеше – Бар итүченең колы. Кеше табигать алдында көчсез, үз язмышын үзгәртергә ирексез, гөнаһ кылудан азат түгел, тик ул, Ходай каршында үз зәгыйфьлеген аңлап, тәүбә итә һәм аның шәфкатен сорый ала.

Бу күренеш Ф. Гаттар, Ә. Ясәви, С. Бакыргани, Мәҗлиси, С. Аллаһияр, Хәмдәми кебек күп кенә шагыйрьләр иҗатында очрый. Әйтик, XVI гасыр татар шагыйре Мөхәммәдьяр үзен «фәкыйри» дип атый. «Фәкыйри» дип атау традициясе нәкышбәнди тарикатендә күзәтелгән. Ислам кабул ителгәннән соң, Идел буе татарларында әлеге суфи этикасы шактый киң таралган булган. Димәк, Г. Кандалый поэмаларында лирик геройның үзен «кимсетүе», төрки-татарларда киң таралган күп гасырлык дини һәм әдәби традицияләргә тугрылыкка ишарәли. Моннан тыш, лирик геройның «тыйнаклыгы» – поэманың укучыга эмоциональ йогынтысын, образлылыгын һәм чагылышын арттыруга юнәлдерелгән өстәмә чара.

«Рисаләи-әл-иршад» поэмасында автор хатын-кызларга аерым игътибар бирә. Мисал өчен, «Кызлар өчен улан нәсыйхәтләр, вәгазьләр» бүлеген карыйк. Исеменнән күргәнебезчә, бүлек кызларны вәгазьләүгә багышланган. Идел Болгарында ислам кабул итү белән, халкыбыз шәригать кануннарына күчкәннән соң, хатын-кызның намуслылыгына, әхлагына игътибар арткан, шуның белән бергә хатын-кызның, ананың роле үскән.

Поэмада авторның сүз-аралашу сәнгате, игелекле сүз, күркәм аралашу темасына дикъкать итүе кызыксыну уята. Шагыйрь матур һәм урынына күрә әйтелгән сүзләрне, тыңлаучыга йогынты ясау көче буенча, энҗе белән чагыштыра. Ләкин сүз җәрәхәтләргә дә мөмкин, дип белдерә автор:

Сүәксез дел яратды Хакъ,
Сүзи та кыйладыр йомшак,
Җәрахәт дел белән кыйлмак
Яман әз-нәйзаи Бәһрам.

[Кандалый, б. 263]

Татар халкы сүзгә, сөйләмгә элек-электән сизгер, һәм бу факт фольклорның барлык жанрларында да, әдәбиятта да киң чагылыш

тапкан. Әлеге өзектә телгә алынган Бәһрам – Урта гасыр фарсы-таҗик дастаннары персонажы. Риваятьләрдә әлеге каһарманның прототибы – Бәһрам V, ягъни Бәһрамгур, ул Ирандагы Сасанилар династиясенең ундүртенче падишаһы булган (439 елда вафат). Әлеге персонаж кыюлыгы һәм каһарманлыгы белән дан тоткан, шуннан әлеге исем батырлык символына әверелгән. Бәһрамның башка мәгънәсе дә бар: Марс планетасы. Ул Рим мифологиясендә сугыш алласы хөрмәтенә шулай аталган. Г. Кандалый әсәре аша татар әдәбиятына шундый персонажларның килүе, билгеле, очраклы хәл түгел. Бу күренеш мөселман-гарәп-фарсы-төрки илләр һәм этнослар арасында бәйләнешләрнең әдәбият аша урнаштырылуын раслый. Мондый үрнәкләр Г. Кандалый иҗатында бик күп. Ихтимал, әлегедәй бәйләнешләрнең әһәмияте, кыйммәте әле ахыргача тикшерелеп, тулысынча бәяләнмәгәндер дә. «Рисаләи-әл-иршад» поэмасы мисалына игътибар итсәк, беренчедән, шагыйрь татар әдәбиятын яңа образлар, символлар, идеяләр белән баеткан. Татар әдәбияты һәм фольклорының бер-берсен тулыландыру һәм баету үзенчәлеге мәгълүм, димәк, Габделҗәббар бине Габделмәҗиднең иҗаты, һичшиксез, татар халкының фольклор фондын да баеткан. Икенчедән, әдәбиятара бәйләнешләр исәбенә Г. Кандалый иҗаты татар әдәбияты кысаларында гына калмый: ул башка әдәби, мәдәни һәм тел традицияләрен йөртүчеләр өчен актуаль һәм әһәмиятле була башлый.

«Рисаләи-әл-иршад»та тел, сөйләм, аралашу темасын дәвам итеп, шәригать кануннарының тел һәм сөйләм мәсьәләләренә дә зур игътибар бирүен әйтергә мөмкин, чөнки тел – кешеләр арасында аралашу коралы. Шәригать буенча, кешеләр бер-берсенә ачуланырга тиеш түгел. Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисләрендә кешегә күпчелек бәлаказаларның тел аркасында килүе ассызыклана.

Яман тел һичкемә вирмә,
Дәхи гайбәт кылып йөрмә,
Бу форсатны йилә вирмә,
Шәйатин салмайа та дам.

[Кандалый, б. 263]

Бу өзек шигъриятебездә сүзгә карата сакчыл, игътибарлы караш традициясенең никадәр көчле булуын һәм шагыйрьнең әлеге традициягә тугры калуын күрсәтә.

Шулай итеп, «Рисаләи-әл-иршад» – исеме һәм эчтәлеге белән адәм балаларын игелекле, тугры юлга өнди торган дини-дидактик әсәр, дигән нәтиҗәгә киләбез.

Икенче бер поэмасын – «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм»не Г. Кандалый шулай ук мәдрәсәдә укыган вакытта иҗат иткән. Әсәр тулысынча сакланмаган. Безнең көннәргә поэманың 14 бүлеге килеп җиткән. Ул «Рисаләи-әл-иршад» кебек үк дидактик поэма жанрына карый. Әсәрдә сүз мөселман дөньясында киң билгеле суфи шәехе Ибраһим бин Әдһәм турында бара [Сафиуллина, 2007, б. 60]. Ибраһим Әдһәм – Урта гасыр мөселман дөньясының тәкъвалыгы һәм изгелеге белән атаклы

шәхесе, суфи шәехе. Г. Кандалый поэмада дәрвиш Ибраһим Әдһәмнең ил гизүе, аның белән булган гыйбрәтле хәлләрне тасвирлый.

Кем сәнең зикрең, Хода, Рабб-әл-Кәрим,
Инҗир-ү-хөрмәм ирер улды бәнем.
Мәүләи зикреҗ гөлстаным дорыр,
Дөнйа-ахирәт вә гүәдел дадем дорыр.
[Кандалый, б. 325]

Автор иске киемле, фәкыйрь тормышлы бу затның иманлы, тәкъва, үз сүзендә нык торучы, намуслы кеше булуына басым ясый. Бу каһарман татар әдәбиятында үзенчәлекле романтик, мәгърифәткә һәм хакыйкатькә омтылучы персонаж буларак та гәүдәләнә.

Г. Кандалыйның әлеге поэмасы, нигездә, татар телендә язылган, шулай да поэмада гарәп-фарсы, төрек телләреннән алынмалар бихисап. Аны төрки әдәбиятта киң таралган нәзыйрә (мәгълүм сюжетка нигезләнеп, җавап итеп яки охшатып язылган әсәр) жанрына кертергә мөмкин.

Әсәрдә дөнья малы туплауга, хакимияткә теш-тырнагың белән ябышуга тискәре мөнәсәбәт белдерелә. Дөньяның фанилыгы, кешегә биредә изге гамәлләр кылу, Аллаһ ризалыгына ирешеп яшәү кирәклеге дәлилләнә. Шулай ук Г. Кандалый иҗатында гыйлемлелек, белем алырга омтылу, мәгърифәтле булу темасы фәлсәфи дәрәҗәгә җиткерелә.

Җәһаләтлек – яманлыкдыр,
Бере аның – наданлыкдыр,
Болардан һич яман юкдыр
Гизәрсең гәр зәмин-асман.
[Кандалый, б. 248]

«Рисаләи-әл-иршад» һәм «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмаларының тел-стиле, образлар системасы бүгенге укучылар өчен шактый авыр аңлаешлы. Шуңа да карамастан бу әсәрләр шагыйрьнең зур талантка ия булуы, үзеннән элгәре татар әдәбияты казанышларын яхшы белүе, шулай ук асыл кыйммәтен бәяләрлек кеше буларак, уртак төрки мирасны үз халкы белән уртаклашуын ачык күрсәтә.

XIX гасырның 20 нче елларында Г. Кандалый иҗатчы буларак тәмам оешып җитә, аның шигъри таланты тирәнәя, һәм шагыйрь татар телендә оригиналь әсәрләр яза башлый. Аның башлангыч иҗатын татар галимнәре Урта гасырлар әдәбиятына, иң соңгы әсәрләрен – XVII гасыр – XIX гасыр уртасы әдәбияты чорына кертеп карыйлар. Бу чорда Г. Кандалый әсәрләрен, элекке әдәбият традицияләреннән китеп, саф татарча иҗат итә. Мәсәлән:

Йөзең күргәч дидем: «Әлхәмдүлиллаһ»,
Буең күргәч укыдым «Куль һү Аллаһ»!
Каләм алдым – тагын азрак язасы,
Китә төшсен абыз тутаймазасы.
[Кандалый, б. 248]

Г. Кандалый иҗатының җитлеккән чорына «Шәфгый», «Сәхипҗамал», «Бәдыйга һәм Бәгыйдә, «Фатыйма», «Нәзъме Йосыф», «Фәрхисорур» һ.б. поэмалары, шулай ук башка күләмле лирик әсәрләре, күпсанлы шигырьләре карый. Әлеге лирик әсәрләрнең күпчелеген мәхәббәт темасы берләштерә. Мәхәббәт, гашыйклык темасы – мөселман-төрки һәм тулаем Көнчыгыш әдәбиятында традицион күренеш: борынгырак шагыйрьләр еш кына Аллаһны ярату хисләрен тасвирлаган, иманлы-тәкъва каһарман образларын калку итеп күрсәткән, шуларга караган идеяләр, мотивларны, символларны, бизәкләү чараларын Г. Кандалый да киң кулланган. Соңрак шагыйрьнең безгә мәгълүм әсәрләрен тулаем яки теләсә кайсы шигырен аерым гына алып карасак та, гади кешенең хис-кичерешләрен, уй-фикерләрен, шатлык яки кайгыларын күрәбез. Аның иҗатының үзәгендә – кеше, абстракт һәм романтик персонаж гына түгел – шагыйрьнең үз замандашы. Шагыйрьнең татар һәм гомумтөрки әдәбиятына керткән яңалыгы да шунда.

Шагыйрьнең мәхәббәт темасына багышланган, «Сәхипҗамал»да, «Бәдыйга һәм Бәгыйдә», «Беләлмадым», «Җаным корбаның улсын», «Бер нәзарда», «Сән һәм бән», «Сәламнамә» шигырьләре дә гаять халыкчан, матур образларга бай булулары белән әсир итәләр. Г. Кандалый шигърияткә халык авыз иҗатыннан да сәнгатьчә фикерләү үрнәкләрен керткән; үзенчә баетып, халык сәнгатен иҗади үстергән. Моны без шагыйрь иҗатының традицион халык җырлары, мөнәҗәтләр, бәетләр, мәкаль-әйтемнәр белән гаять мул бизәлүендә күрәбез.

Татар әдәбияты тарихында Г. Кандалый исеме кешенең матурлыгын җырлаучы шагыйрь буларак язылып калды. Кандалыйның поэтик осталыгы, шигырьләренең сәнгатьчә эшләнү үзенчәлекләре хәзерге заманда да галимнәр тарафыннан тикшерелә. XVIII гасыр шагыйре иҗатын элгәреге милли әдәбият һәм фольклор белән бәйләнешләре, тел-стилистикасы, поэтикасы ягыннан, мәшһүр Көнчыгыш әдәбиятындагы жанрлар, образлар традициясе күчемлелеге нисбәтеннән һ.б. өйрәнү әле дә дәвам итә.

**Әдәбият**

*Кандалый Габделҗәббар.* Шигырьләр һәм поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 558 б.

*Садекова А.Х.* Идеология ислама и татарское народное творчество. Казань: Иман, 2000, 261 с.

*Сафиуллина Р.Ф.* Традиции фольклора в творчестве Габдельджаббара Кандалый: дис. … канд. филол. наук: 10.01.09. Казань, 2007. 167 с.

*Сафиуллина Р.Ф.* Традиции фольклора в творчестве Габдельджаббара Кандалый. Казань:ИЯЛИ, 2020. 168 с.

***Сафиуллина Рузия Фәһим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398.1

***И.Г. Закирова***

# СТАДИАЛЬ ЯКТАН ИҢ СОҢГЫ ЧОР ЭПИК ӘСӘРЕ БУЛАРАК «ӘЙТҮКӘ» РОМАНИК ДАСТАНЫ: ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫ ҺӘМ РЕКОНСТРУКЦИЯ

В статье освещается история сбора и изучения «Әйтүкә җырлары» («Песни Айтуки»). Строфы, известные в народе под названием «Әйтүкә җырлары», записанные учеными в разные годы в Новосибирской области, в статье собраны в один текст и дополнены сказаниями и преданиями об этих событиях. В статье представлен реконструированный текст. Произведение «Айтука», на наш взгляд, представляет собой стадиально поздний, до конца не сформировавшийся романический дастан.

**Ключевые слова:** Айтука, романический дастан, барабинские татары, Новосибирская область, Хафиз Рахматуллин, любовная лирика.

The article highlights the history of the collection and study of «Aytuka җyrlary» («Songs of Aituki»). The stanzas, known among the people under the name «Aytukә җyrlary», recorded by scientists in different years in the Novosibirsk region, are collected in one text in the article and supplemented with legends about these events. The article presents a reconstructed text. The work of «Aituk» in our opinion is a stage-by-stage late not fully formed Romanesque dastan.

**Keywords:** Aituka, romantic dastan, Baraba Tatars, Novosibirsk region, Khafiz Rakhmatullin, love lyrics.

Татар халкында бәхетсез мәхәббәтне бәян иткән дастан-кыйссалар, легендалар, тарихи җырлар гаять популяр. Аларның дистәләгән вариантлары булып, бәхетсез гашыйклар тарихын белмәгән кеше юктыр. Таһир белән Зөһрә, Ләйлә белән Мәҗнүн, Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу мәхәббәтләре турындагы дастаннарны халык яттан белгән. Сезгә тәкъдим ителә торган Әйтүкә җырлары да – мәхәббәт җырлары. Бу җыр – эчтәлеге белән романик дастанга якын әсәр. Дөресрәге, реаль вакыйгаларга нигезләнгән Әйтүкә җырлары җыр белән дастан арасында тора.

Хәзергә кадәр Себергә оештырылган комплекслы экспедицияләр вакытында «Әйтүкә җыры» турында ишетергә туры килә. Информантлар бу җырның Әйтүкә исемле егет белән Батыш исемле кызның бәхетсез мәхәббәтен бәян иткән җыр булуын хәтерләсәләр дә, соңгы елларда ул онытыла бара, информантлар аерым строфаларын гына искә төшерәләр. Җыр Новосибирск өлкәсендә яшәгән татарларда бик популяр булган. Җырда тасвирланган вакыйгалар, җыр чыгуга сәбәп булган мәхәббәт тарихы күпсанлы, еш кына бер-берсенә каршы килгән риваятьләрдә, истәлекләрдә дә саклана.

«Әйтүкә җыры» Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Себер татарларының фольклорын өйрәнү максаты белән оештырылган экспедицияләр вакытында күп тапкырлар язып алына. Җырны иң беренче язып алган кеше Хафиз Рәхмәтуллин була. Ул 1894 елда Омск өлкәсенең Усть-Ишим районы Тау авылында туган. Хафиз Рәхмәтуллин 1928 елдан 1936 елга кадәр Новосибирск өлкәсендә төрле вазифалар башкарган. 1932–1936 елларда «Азат Себер» газетасында редактор урынбасары һәм баш редактор булып эшли. Ул киң эрудицияле, күпкырлы талантлы шәхес булып, Себер татарларының рухи байлыгын туплау һәм киләчәк өчен саклап калу өчен зур хезмәт куя. Әлеге шәхес язмага теркәү сәбәпле, Себер татарларының күпсанлы җырлары сакланып калган. Новосибирск өлкәсендә эшләгәндә Хафиз Рәхмәтуллин «Әйтүкә җыры»н да язып алган.

В.В. Радлов эзләре буенча оештырылган 1940 елгы экспедиция вакытында бу җырларны һәм Әйтүкә тарихын Хәмит Ярми белән Мөхәммәт Садри (В. Хаҗиев) теркәгән. М. Садри «Әйтүкә җыры» турындагы риваятьләрне 1964 елда «Совет әдәбияты» журналында басылган мәкаләсендә искә ала (1964, № 8. Б. 135–136), аннан җыр текстын «Казан утлары» журналында бастырып та чыгара (1978, № 9. Б. 118–120), бу җыр әдипнең «Иртешкә сәяхәт» дигән җыентыгында да урын алган (Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 115–119).

Хәмит Ярми җитәкчелегендәге экспедиция 1967 елда тагын Новосибирск өлкәсендә эшли. Әйтүкә җырын, Әйтүкә белән Батышның мәхәббәт тарихын, тормышларын яктырткан риваятьләрне Х. Ярми, Һ. Мәхмүтов, Ф. Урманчеев, Ф. Әхмәтова, Х. Гатина, В. Хаҗиев язып алалар. Ике тапкыр оештырылган экспедицияләр барышында Әйтүкә белән Батыш турында кызыклы риваятьләр, шактый гына җыр текстлары туплана.

«Әйтүкә җыры» диалектологлар игътибарыннан да читтә калмаган. Диалектолог Л.В. Дмитриева 1967–1968 елларда Новосибирск өлкәсенең Чан районы Тармакүл авылында җырның унҗиде строфасын язып алып, аларны үзенең «Язык барабинских татар» дигән китабында бастыра (Л.: Наука, 1981. С. 73–77). «Әйтүкә җыры»н һәм риваятьләрен Новосибирск өлкәсендә узган экспедицияләр вакытында диалектолог Ф. Йосыпов терки. «Барабинские татары. Страницы духовной культуры» дигән коллектив монографиядә галим үзе язып алган вариантлар белән диалектологлар Л.В. Дмитриева, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова һәм М. Садри бастырган текстларны да биреп, бу җырның билгеле вариантларын бергә туплый (Казань: Казанский университет, 2013, С. 253–274).

Диалектологлар Ф.С. Баязитова белән Д.Б. Рамазанова «Әйтүкә җыры»ның сүзләрен Себер татарларының этнокультура лексикасына багышланган җыентыкларына керткәннәр (*Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы. Казан, 2009. Б. 546–547; *Рамазанова Д.Б.* Себер диалектларыннан материаллар. Казан: Фикер, 1998. Б. 98–100).

Риваятьләр һәм истәлекләр буенча, Әйтүкә белән Батыш Себердә Үңәр дигән авылда (хәзерге Новосибирск өлкәсе Чан районындагы Тармакүл авылы) туып үскән кешеләр. Әйтүкәнең тулы исеме – Әйтмөхәммәт, Батыш – Фатыймадан кыскартылган. Озын исемнәрне кыскарту күренеше элегрәк татарларда киң таралган була. Геройларның биографиясе риваятьләрнең берничә вариантларында бәян ителә.

Беренче риваять буенча, *Батыш Үңәр авылындагы Балыйк (Халыйк, Халик) исемле байның кызы була. Әйтүкә бик ярлы гаиләдән була. Атасы аны ун яшендә Балыйк байга сата. Үсеп җиткәч, ул шул байның хезмәтчесе булырга тиеш була. Әйтүкә Батыш белән бергә уйнап үсә.*

*Әйтүкә йөзгә чибәр, күркәм холыклы егет булып җитешә. Шул ук вакытта егетнең тавышы шулкадәр матур була, аны ишетеп-күреп, бер кеше дә битараф кала алмый. Әйтүкә үзе җырлар да чыгара, дөресрәге егет чичән-җырау сәләтенә ия була, ул һәр вакыйганы җыр белән шәрехләп бара. Батыш белән Әйтүкә бер-берсен ярата башлыйлар. Бай, Әйтүкәне кызына тиң күрми, бу мәхәббәткә чик куярга теләп, Батышны бер байга кияүгә бирә. Тәбсәү (туй) көнне Әйтүкә белән Батыш ат менеп качып китәләр. Алар урманда качып яшиләр. Бер-ике елдан, сагынуларына түзә алмыйча, кире әйләнеп кайталар.*

*Ләкин бай Әйтүкәне кияве итеп танырга теләми. Байлар, муллалар Әйтүкәне шәригать буенча хөкем итәләр. Кыйнап кулын сындыралар. Шул вакыйгаларның шаһиты булган халык Әйтүкәне яклап чыга, байлар кулыннан тартып ала. Шуннан соң Әйтүкә белән Батыш җыр белән үзләренең мәхәббәтләрен сөйлиләр.*

Икенче риваять буенча, *Батыш ярлы кызы була. Аны Үңәр бае көчләп үзенә кияүгә ала. Соңыннан Әйтүкә Батышны байдан тартып алып кача.*

Бу риваятьләрне 1940 елда Хәмит Ярми Новосибирск өлкәсе Чан районының Аялу авылында Нур Ибраһимовтан язып алган.

1967 елда Ф.И. Урманчеев Чан районының Тармакүл авылында Гази Шәмсетдиновтан язып алган риваятьләр алдагы риваятьтә бирелгән мәгълүматларны тагын да тулыландыра.

*Әйтүкә Тармакүлдә туып үскән. Уналты яшендә үзе яраткан Фатыйманы алып, авылдан качкан. Өч ел буена бу авылдан 100 чакрым җирдә, Казакъ илендә яшәгән. Аның яшәгән җирен күргән кешеләр дә булган. Фатыйма бу якта иң матур кыз булган. Үзе биюче дә булган. Маңгаена ... (сүз танылмый. – И.З.) белән су куеп биегән. Әйтүкә бәхер (ярлы) булганга күрә, Фатыйманың әтисе аны Әйтүкәгә бирәсе килмәгән. Шуннан соң Әйтүкә, өйләнмәгән булса да, Фатыйманы алып качкан.*

*Фатыйманың биш агасы булган. Фатыйманы Балык дигән бай кешегә биреп куйган булганнар. Кодалатып куйган булганнар. Әйтүкә белән Фатыйма әүвәл сөйләшеп, аннан качып киткәннәр. Кайбер кешеләрнең Әйтүкәне күргәннәре дә булган. Әйтүкәне тотып, алып*

*килгәннәр. Аннан соң Әйтүкә үзенең җырларын җырлаган. Җырларны русчага тәрҗемә иткәннәр. Шуннан соң пристав Әйтүкәне җибәргән. Фатыймага атасы аңа кияүгә чыгарга рөхсәт итмәгән. Шулай итеп, Әйтүкә белән Фатыйма, бер-берсен яратсалар да, кушылып бергә яши алмаганнар. Фатыйма ялгызлыкта гомер уздыра, Әйтүкә соңра өйләнгән булса кирәк. Ләкин анысын тәгаен белүче юк. Бу вакыйгалар моннан бер йөз ел элек булган.*

Ф. Әхмәтова 1961 елда Новосибирск өлкәсе Бараба районының Бакчакүл авылында 1891 елгы Ажбаков Мөслим бабайдан, 1967 елда Новосибирск өлкәсе Куйбышев районының Шагыр авылында 1897 елда туган Баязитова Оркыя әбидән, 1878 елгы Сәлимҗанов Хәмидулла бабайдан «Әйтүкә җыры»ның аерым строфаларын да, геройлар турында сөйләк-риваятьләр дә язып алган. Бу язмаларда кайбер геройларның исеме башка булса да, Әйтүкә белән Батыш турында алдагы язмалардан аерма күп түгел.

*Тармакүл авылында (Үнәр элеккечә) Ибраһим хәзрәт була. Аның Әйтүкә исемле батрагы була. Әйтүкә хәзрәтнең Батыш исемле кызын ярата. Калым түләр хәле юк, хәзрәт бирми дә аңа кызын. Яшьләр бер-берсен яратышып, казакъ далаларына качып китәләр. Шулай шактый йөргәннән соң, туган якларына кайтырга булалар. Кайбер легендалар буенча, тотып алып кайталар. Үнәрдә халыкны җыеп, Әйтүкәне камчы белән суктырмакчы булалар. Хөкем алдыннан Әйтүкә үзе чыгарган җырларны җырлап күрсәтергә тәкъдим итә. Батышның матурлыгын, аңа булган мәхәббәтен җыр аша әйтеп бирә. Бу җырларны тыңлаган авыл картлары, мондый саф көчле мәхәббәт өчен җәза бирү гөнаһ булыр, дип, хәзрәттән яшьләрне кичерүне үтенәләр.*

*Әйтүкәне төрмәгә утыртканнар. Аның төрмәдә җырлаган җырлары да бар, диләр.*

*Әйтүкә Батышны ташлап, башка хатын янына, үзенең кызы белән калган элекке хатыны янына кайткан, дип тә сөйлиләр.*

«Әйтүкә җыры» халыкта бик популяр булып, аны туйларда каракаршы җырлаганнар. Җырның көйләре бик күп булган, ул борынгы бик озын көйгә дә, кыска көйләргә дә башкарылган. Бараба районы Тандау авылында яшәгән информант Бигушева Сәбидә әбидән Ф. Урманчеев язып алган мәгълүмат буенча, аның яшьлегендә туйда ике кеше «Әйтүкә җыры»н башкарганнар. Аларның берсе – Әйтүкә, икенчесе Батыш булып җырлаган.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан төрле елларда язып алынган материал хәзерге вакытта Институтның Язма мирас үзәгенең фольклор фондында саклана. Бу мәкаләдә әлеге архив материалларын бер цикл буларак туплап, аерым строфаларны, эчтәлекләреннән чыгып, эзлекле бер хәлгә китереп, укучыларны таныштыруны максат иттек.

Фольклорчы галимнәр җырның берничә көйгә җырланганын искәртәләр.

Әйтүкә җырларын башкарылу сәбәбенә, вакытына, кемгә аталуына карап, берничә төркемгә аерырга мөмкин. Бу җырлар арасында кыска гына аңлатма биреп барабыз. Җырларның эчтәлеге һәр ситуацияне аңлаткан риваятьләр белән ярашып бара.

### Әйтүкә җыры

«Әйтүкә белән Батыш» җыры геройларның бер-берсенә мәхәббәтен аңлаткан җырлар белән башлана. Алар бу җыр аша бер-берсенә соклана, бер-берсен мактый, бергә булырга сүз бирешә.

*Әйтүкә:*

Йөгерәләй куян, йөгерәләй,
Мамык тикләй йонын туздыралай.
Бер яхшы берлән ай бер яман,
Әй җаныкай гынам, сылуым,
Шатлык белән гомер уздыралай.

*Варианты:*

*Йөгерә лә куян баласы,*
*Мамыктай ла йонын туздыра.*
*Ике лә яхшы бер кушылса,*
*Әй җаныкай гынам, сылуым,*
*Шатлык берлән гомерен уздыра.*

Ике лә генә кырның уртасында,
Ятадыр ла куян баласы.
Дөнья-ахирәт, мәхшәр сәхрасында,
Әй җаныкай гынам, сылуым,
Корыладыр мизан тарасы.

*Батыш:*

Тәрәзәләрдән ник бактың?
Кар йомарлап, җаныем, ник аттың?
Берләр лә атмай, җаныем, ике аттың,
Әй җаныкай гынам, сылуым,
Яшь йөрәккәемә ут яктың.

Сикереп ләй төштем бакчага,
Бакчадагы пешкән алмага.
Бер матур белән уйнаймын дип,
Әй җаныкай гынам, сылуым,
Гөнаһкяр ла булдым Аллага.

*Әйтүкә:*

Әй җанкәм лә җанкәм, түзә алмыйм мин,
Тәрәзәдән күрсәм күз алмыйм мин.
Үңәр урамнарын әй үткәндә
Синеләй күрмәй үтәлмим мин.

Урамыгыздан узганымда
Ике генә күзем, тулды яшем.

Кара ла кашым, асыл ташым,
Исән булсын газиз башың.

Әй урамыгыздан әй узамын,
Яшел лә ефәк мин сузаем.
Яшел лә ефәкләр җитмәсә,
Тәхлил-бәет әйтеп мин узаем.

Ай тулган ла җанкәм, әй ай тулган,
Ай туган чакта ла син туган.
Тулган айдай якты ла йөзең,
Бу җиһанда синдәен кем булган.

Әй кыйгач ла кашым, карлыгачым,
Сине лә кайда күрәем мин?
Кызыл алмадай ай йөзеңне,
Кай җирләрдән суырып үбәем мин.

Җырларда өч тапкыр Түкә кәмшек телгә алына. Язып алынган материаллар бу кешенең кем булуы турында мәгълүмат сакламый. Түкә ул Төхфәт дигән исемнең бозылган варианты булырга мөмкин[1]. Кәмшек сүзе кыегайган, ямьшәйгән дигән мәгънәдә. Бу очракта ул Төхфәтнең исеме белән янәшә кулланыла торган кушаматы булырга тиеш. Төрки халыклар эпосында, яшьләрнең мәхәббәтенә комачаулап йөргән хезмәтче традицион образ да булуын истә тотсак, Түкә Батышның атасында хезмәттә булган, кызны саклау да аңа йөкләтелгән хезмәтчесе булырга мөмкин.

*Батыш:*

Әй җанкәм лә, җанкәм, күзем туймас,
Бу җиһанда синдәен егет булмас.
Йөгереп чыгып үбәр идем,
Түкә лә кәмшек капка ачмас.

Таллардин ла очар талга кунар,
Кара бакчай кошының баласы (кара бакчай – сыерчык).
Билдинләй кысып, авыздан сөйсәң,
Яхшы ла әткәйләрнең баласы.

Әй Уралдай биек тау бармы икән,
Барып ла күргән ир бармы икән.
Авырлыклар күрмәй әй ярын алган,
Бу җиһанда андаен яр бармы икән.

Чобырлай чобыр тамчы тамар,
Тамчылары сары май кебек.
Кешеләр күзләренә әллә ничек,
Үз күземә тулган ай кебек.

[1] Себер татарларында кеше исемен кыскартып куллану хәзерге көндә дә бар.

*Әйтүкә:*

Әй иртә лә торып юлга чыксам,
Олы ла юлда урыс ямщик.
Урыс ямщигенә әй, охшаган
Үңәр урамында Түкә лә кәмшек.

Әй йөгерепләр лә йөгереп җитәлмим мин,
Тал, читәннәрдән үтәлмим мин.
Билгеләре шулдыр сөюемнең,
Катындыйн (янынан) ташлап китә алмыйм мин.

*Батыш:*

Әй иртә лә торып тәрәзә ачып,
Таң атуларын көтәмен мин.
Йөрәгемә тулган гыйшык уты,
Сине лә уйлап уңамын мин (уңу – саргаю, сулу).

Батышны икенче кешегә ярәшкәннән соң, яшьләр өйләнешүдән өмет өзә, алар үзләре өчен качып китү генә калганын аңлыйлар. Җыр буенча фикер йөртсәк, Батыш качып китүне үзе тәкъдим итә.

*Батыш:*

Әй китәек җанкәм, әй китәек,
Кара урманнардан әй үтәек.
Аяк аска басып дошман сүзен,
Үз теләгебезгә без җитәек.

Үңәр лә күле әй киң икән лә,
Сулары ястыкка тиң икән.
Ике лә күңел әй бер булганда,
Аеручы ла дошман әй кем икән.

Әй баш имәм, җанкәм, баш имәм мин,
Үз теләкләремне итәрмен мин.
Аягыма богау салсалар да,
Аны да ла тибеп өзәрмен мин.

*Әйтүкә:*

Әй китәрбез, җанкәм, әй китәрбез,
Үз теләкләребезне әй итәрбез.
Безгә каршы килгән әй дошманның,
Битләренә төкереп без үтәрбез.

*Батыш:*

Әй күктә лә йөзгән бер йолдызга,
Әйтәләр лә икән Чулпан дип.
Дошман ла сүзен читкә каккан
Егетләрне әйтәләр солтан дип.

*Әйтүкә:*

Каен төпләренә балта чапсаң,
Гөрләп оча аның әй тургае.

Үз сүзләреңдә әй тугры булган,
Син җанкәем кызның әй солтаны.

*Батыш:*

Ашасаң ла шикәр, әй бән куямын,
Ашаганыңны ла әй күрәем.
Ашаганыңны ла әй бән күрәем,
Сәнеңләй өчен бән үләем.

Әй кырларда үскән куш каенның,
Төпләренә билге кем юнган.
Сөйгәндә лә ярына туры булган
Бу җиһанда синдәен кем булган.

Яшьләр үзләренең мәхәббәтен дә, киләчәктәге бәхетсезлекләрен дә язмыш дип кабул итә. Җырда язмыш мотивы төрле яктан ачыла.

*Әйтүкә:*

Майдалай кәккүк әй кычкырадыр,
Язынлай көзен һич белмидер.
Халаек безне күп сөйлидер,
Хак язганын һич белмидер.

Туй көнне Әйтүкә Батышны алып качып китә. Качып барганда, аларның бияләре колынлый. Ат, колыны белән мавыгып бармый башлый. Бу вакыйга ике төрле бәян ителә. Беренчесендә колынлы бия тиз бара алмаганга, Әйтүкә колынны суярга тели. Әмма Батыш колынны кызганып, бу эшкә юл куймый. Әйтүкә дә, Батыш каршы килгәч, колынга тими. Риваятьнең икенче вариантында, киресенчә, колынны кызганудан Әйтүкәнең аны суярга кулы күтәрелми. Батыш, атның туктап калуы аркасында, бөтен планнарының җимерелү куркынычын аңлап, колынны үзе суя. Җырда да шушы хәлләр тасвирлана:

*Әйтүкә:*

Кара ла колын кешнәгәндә,
Туры ла биям әй тулады.
Батыш җанкәм аны суй дигәндә
Ике лә кулым әй бармады.

Минем лә кулым әй бармады,
Батыш җанкәм пычак ошлады (ошлау – тоту).
Кешнәп лә торган әй колынны
Бугазыннан суеп әй ташлады.

Шуннан соң Әйтүкә үзенең халыкта иң таралган җыр юлларының берсен җырлый:

Кызылгат дигән әй җиләкнең,
Тышлары ла татлы, эче ташлы.
Минем лә сөйгән әй Батышның
Телләре лә татлы, күңеле каты.

Бу строфа галимнәр тарафыннан кат-кат язып алынган. Риваяте онытыла барып, җырның яңа варианты барлыкка килгән. Кызның кискенлеген, холкын күреп, гаҗәпләнеп җырлаган Әйтүкәнең җыры мактауга, соклануга әйләнә:

*Кызылгат дигән әй җиләкнең,*
*Тышлары ла татлы, эче ташлы.*
*Минем лә сөйгән Фатыйманың*
*Авызы ла татлы, теле баллы.*

Качып киткән яшьләр җыр юлларына Ябышкан дип кергән урманда (икенче вариантта – болында) яши башлыйлар. Бу җирләр аларның туган авылларыннан шактый ерак, кеше аягы басмаган аулак урын була.

Әйтүкәнең качып китеп урнашканнан соңгы җырларында, аның сөйгәне белән кавышудан сөенеп, күпмедер вакыт эйфория халәтендә булуы аңлашыла:

Суда ла йөзгән ак балыкның
Баласын әйтерләр култан диеп.
Акча ла бирми ярлар сөйсәң,
Әйтүкәне әйтерләр солтан диеп.

*Яр буйлары әй, Ябышкан,*
*Ябышканда яткан бармы икән?*
*Яр буенда яткан Әйтүкәне,*
*Әйтерләр аны солтан дип.*

Шул ук вакытта, тынычлык булмау, кире кайту турында уйлау, киләчәкнең билгесезлеге яшьләргә бәхетле булырга да ирек бирми. Алар үзләрен йолаларга каршы килүләре, илдә булмаган гамәл кылулары өчен гаепле тоялар. Алдагы строфаларда бер-берсен гаепләү, чарасызлык чагыла:

*Әйтүкә:*

Ябышканның буе ярлар микән,
Барып кына күргән барлар микән.
Газиз генә башын хурлар кылган
Яр сөйгән матур ярлар микән.

Ябышканның буе ярлар микән,
Барып кына күргән барлар микән.
Сөйгәнен алып мәерләй канган
(мәерләй канган – күңеле рәхәтләнгән)
Бу дөньяда барлар микән.

Ябышканның буе ярлар икән,
Барып та лай күргән барлар микән.
Уйны да йөрдем, буйны да йөрдем
Җан сөйгәннән артык барлар микән.

Кешеләрдән читтә яшәү аларга кыен бирелә. Икесе дә туган иленә кайту турында уйлый башлый.

*Әйтүкә:*

Карагат бәнем икеләй күзем (карагат – карлыган),
Саргайды ла бәнем ике йөзем.
Исән генә булып илгә барсам,
Әйтергәләй күптер бәнем сүзем.

Сикереп лә төштем әй инешкә,
Ат бәйләдем сары камышка.
Үлмәсә дә адәм үлми икән,
Эчекәе тулган сагышка.

Ябышкан буе, әй, ком такыр,
Алтын акчалар булмас бакыр.
Сагындым, җаный, әй, саргайдым,
Кайтмаенча булмас, ахыр.

Әй әдернә лә тартып, уклар аттым (әдернә – җәя),
Кырларда ла йөргән киекләргә.
Газиз генә башым туган икән
Дөньясынамы көекләргә (көек – кайгы, борчу).

Муены ла озын әй пүз торна (пүз – бүз),
Әллә ничә төрләй бузнайдыр (бузнау – көйләү, сайрау) .
Әй, уйны да йөреп, пуйны ла йөреп,
Мөхәндәрдин адәм узмайдыр (мөхәндәр – язмыш).

Күпмедер кагылып-сугылып йөргәннән соң, Әйтүкә белән Батыш туган илләренә кайтырга булалар. Икенче версия буенча, аларны эзләп табып кайтаралар. Авылга кайткач, җырның эчтәлегенә караганда, бөтен авыл халкы җыела.

Хөкем иткәнче, Әйтүкә үзе чыгарган җырларны җырлап күрсәтергә тәкъдим итә. Бу җырларда ул Батышның матурлыгын, аңа булган мәхәббәтен тасвирлый. Картлар, бу җырларны тыңлагач, мондый көчле мәхәббәт өчен җәза бирү гөнаһ булыр дип, хәзрәттән яшьләрне кичерүен үтенәләр. Әйтүкә җырларында мондый юллар бар:

Ул да яхшы, бу да яхшы,
Чәй эчкәндә бал да яхшы,
Баш коткарган тел дә яхшы.

*Ашаган чакта бал да яхшы,*
*Сөешкән чакта яр да яхшы.*
*Газиз генә башка эшләр төшсә*
*Сөйләшкән чакта тел дә яхшы.*

Әйтүкә белән Батыш җырларында үзләренең гаепсез булуларын, бигрәк тә бер-берсенең гаебе юклыгын исбатларга тырышалар, берсе икенчесен коткарып калырга тели.

*Әйтүкә:*

Шаулап ла аккан әй елгада,
Чуртан йөзә суларның үзенә.

Кимсетмәгез безне, әй дусларым,
Кеше кермәс кеше ләй гүренә.

Таң алдыннан яуган әй карларга,
Ак куяннар йөгереп лә юллар салган.
Сөйгәндә дә сөйгән ярын алу
Йосыф белән Зөләйхадан калган.

Суларда ла йөзгән әй балыкның,
Баласына әйтегез култан диеп,
Маллары ла булмас ярлар сөйгән
Әйтүкәне әйтегез солтан диеп.

*Батыш:*

Күлләрдә лә ялгыз аккош,
Баласыннан аерып атмагыз.
Минемдә лә сөйгән Әйтүкәне
Малы юк дип читкә какмагыз.

Әй какмагыз безне, әй какмагыз,
Түкә кәмшек сүзенә бакмагыз.
Гомерлек лә итеп сөйгән ярым,
Аерып ла мине утка ла якмагыз.

Аера алмассыз мине Әйтүкәмнән,
Бугазыма баулар әй салмыйча.
Аера алмассыз мине Әйтүкәмнән,
Газраилләр җаным әй алмыйча.

*Батыш:*

Әй беләгемә кигән куш беләзек,
Ай яктысы төшсә ялтырый.
Минем лә сөйгәнем әй Әйтүкә –
Ир-егетләрнең лә иң батыры.

Үңәр байларының соравы буенча, Әйтүкәне хөкем итү өчен, шәһәрдән кыңгыраулы унсигез пар атта 18 түрә килгән. Алар Әйтүкәне гомерлек каторгага хөкем итәләр. Ахырда баш түрә: «Сезне җырчы диләр, ахыргы минутыгызда бер җырлап күрсәтегез», – ди. Баштагы җырдан түрә, бу безне бик мактады дип аңлый, «бик күп маллар түгәр идем алтын штуф укалы якагызга» дигән юлларны бу безгә ришвәт бирәчәк икән дип аңлап, хөкем җәзасын йөз чыбык суктырырга калдыра.

Әйтүкәнең суд приставы килгәч җырлаган җыры:

Ат бәйләгән кубагызга (куба – күчмә өй,
чыбыктан үрелгән),
Чәң бәйләгән дугагызга (чәң – кыңгырау).
Гакылым бетте, исем китте
Алтын штуф бәйләгән якагызга.

Ат бәйләрмен курагызга,
Чәң бәйләрмен дугагызга,
Бик күп маллар түгәр идем
Алтын штуф укалы якагызга.

Риваятьләрдә Әйтүкәнең төрмәгә утыртылуы, аның төрмәдә җырлаган җырлары да булуы бәян ителә.

Икенче версия буенча, Әйтүкәне утыртмаганнар, ләкин аңа Батыш белән калырга да рөхсәт булмаган. Ул үзенең беренче хатыны, баласы янына кайткан.

Әйтүкә белән Батышның хөкем карарыннан соңгы җырларында мәхәббәткә, гашыйкларның тугрылыгына дан җырлана:

*Әйтүкә:*

Батыш җанкәм суга иңгән,
Көянтәсен талга элгән.
Буе зифа тал чыбыктай
Яр буласын әй кем белгән.

Батыш җанкәм урак ура,
Уң беләген әй талдырып.
Батыш җанкәй мине сөйде
Байлар күңелен әй калдырып.

Батыш җанкәй әй кия лә
Кара сатин көйләген (көйләк – күлмәк).
Батыш җанкәм ташламайды
Маллар өчен әй сөйгәнен.

Ашасаң да шикәр, бән куямын,
Ашаганыңны ла әй күрәем.
Ашаганыңны ла әй бән күрәем,
Сәнеңләй өчен бән үләем.

*Батыш:*

Онытмам ла, җанкәм, онытмам мин,
Синнән лә башканы яр итмәм мин.
Синең лә кайгыңнан, әй солтаным,
Камыштаен саргаеп үләрмен мин.

Өченче риваять Әйтүкәнең хөкем ителүен бәян итә. Әйтүкә өстеннән җәза башкарылган. Баш түрә Әйтүкәдән, яңадан Батышны алмам, дигән сүз ала. Шуннан соң Әйтүкәне атып үтерәләр. Бу вариант җыр юллары белән дә туры килә. Батышның соңгы җырларында хөкем карарының нинди булганы да, палач турында да мәгълүмат саклана:

Сине генә сагынган чакларымда
Астанаңа башымны куярмын мин.
Әй моңланып кошлар сайраганда
Сине генә уйлап җырлармын мин.

Әйтер сүзен әйтә алмый торды,
Эт урядник кылыч әй алганда,
Әйтер сүзен әйтә алмый торды,
Түкә кәмшек мылтык әй атканда.

Әй куе ла кауданлы каен төбе,
Яныкаем, яткан җирең булды.
Кара ла туфрак әй астында
Алмадаен кызыл ла йөзең сулды.

Әйтүкә үлгәннән соң, Батыш яңадан кияүгә чыкмаган. Гомере буе Әйтүкәне эзләп, 60 яшендә Үңәргә кайтып вафат булган.

*Текст Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәгенең фольклор архивында сакланган материаллардан төзелде.*

*Аларны фольклорчы галимнәр Х. Рәхмәтуллин, Х. Ярми, Һ. Мәхмүтов, Ф. Урманчеев, Ф. Әхмәтова, Х. Гатина, В. Хаҗиев Новосибирск өлкәсенең төрле районнарында фольклор экспедицияләре вакытында туплаган. Информантлар исемлеге:*

*Бараба районы Бакчакүл авылы, Аәнбанов Габбас, 1884 елгы; Аҗбаков Мөслим, 1891 елгы.*

*Венгерово районы Арынсас авылы, Вахитов Мәгъруф, 1905 елгы; Венгерово авылы, Назирова Мөршидә, 1910 елгы.*

*Куйбышев районы Шагыр авылы, Рафикова Мөхлисә, 1882 елгы; Баязитова Оркыя, 1897 елгы; Хәйдарова Мәргу, 1898 елгы; Сәлимҗанов Хәмидулла, 1878 елгы.*

*Чан районы Кошкүл авылы, Мөхәммәтшин Аллаяр.*

*Чан районы Тармакүл авылы, Ишмакова Нәкыя, 1923 елгы; Нургалиева Вәйдә; Шәмсетдинов Гази, 1903 елгы; Ташпулатов Кәрим; Юнанов Сәфәргали; Сираҗетдинов Давыт; Хәбибуллина Хәтирә, 1890 елгы; Вәлиуллина Нурҗамал, 1899 елгы.*

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 398.1

*И.К. Фазлетдинов*

# БАШКОРТСТАН ТАТАРЛАРЫНЫҢ КАЧКЫННАР ҺӘМ КАРАКЛАР ТУРЫНДАГЫ РИВАЯТЬЛӘРЕНДӘ ТАРИХ ҺӘМ МИФОЛОГИЯ СИНТЕЗЫ

Статья посвящена исследованию отражения мифологических воззрений в преданиях татар Башкортостана о ворах и разбойниках, их взаимосвязи с историческими фактами. По характеру главного героя автор классифицирует данные произведения на два типа: о «благородных» и о «простых» разбойниках. Проведя тщательный анализ обеих групп, он отмечает то, что в преданиях о «благородных» разбойниках мифологическая составляющая является более выраженной, чем в произведениях второго типа. Отдельно выделяются и анализируются мотивы, связанные с апотропеической, экзапатетической и криптической магией; исследуется отражение антропоморфических и зооморфических воззрений народа в преданиях указанного типа. Проведя межжанровые параллели между преданиями и сказками, автор приходит к выводу о том, что анализируемые произведения являются синтезом тотемистических, анимистических и антропоморфических воззрений наших предков с реальной историей народа.

**Ключевые слова:** предание, легенда, мифология, мотив, трансформация, беглец, разбойник, «благородный», «простой».

The article is devoted to the study of the reflection of mythological views in the legends of the Tatars of Bashkortostan about thieves and robbers, their relationship with historical facts. According to the nature of the protagonist, the author classifies these works into two types: about «noble» and «simple» robbers. After a thorough analysis of both groups, he notes that in the legends about the «noble» robbers, the mythological component is more pronounced than in the works of the second type. The motives associated with apotropaic, exapathetic and cryptic magic are singled out and analyzed separately; the reflection of anthropomorphic and zoomorphic views of the people in the legends of this type is investigated. Having drawn inter-genre parallels between legends and fairy tales, the author comes to the conclusion that the analyzed works are a synthesis of totemic, animistic and anthropomorphic views of our ancestors with the real history of the people.

**Keywords:** legend, mythology, motive, transformation, fugitive, robber, «noble», «common».

Хәзерге Башкортстанга караган җирләрдә борын-борыннан яшәүче татар халкының фольклор репертуарында качкыннар һәм караклар турындагы риваятьләр сан һәм әсәрләрнең идея-эстетик кыйммәте ягыннан әһәмиятле урын алып тора. Бу безгә соңгы елларда чыккан тупланмаларда аларны мөстәкыйль цикл буларак аерымларга мөмкинлек бирде [Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр..., б. 139–144; Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш..., б. 63–64; Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., б. 71–74; Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк..., б. 76–77].

Качкыннар һәм караклар турындагы риваятьләр Башкортстанның татарлар укмашып яшәгән районнарында 1970 еллардан бирле теркәлеп килә. Аларга таянып, Башкорт дәүләт университетының филология факультеты татар-рус бүлеге студентлары, аерым алганда, Д.А. Зиннуров 1975 елда «Нуриман районы легендалары», М.Г. Закиров 1979 елда «Караидел һәм Аскын районы татарларының легендалары» дип аталган диплом эшләрен яклыйлар. Ике хезмәтнең дә фәнни җитәкчесе булып филология фәннәре кандидаты, доцент Р.М. Мөхәммәтҗанов чыгыш ясый. Әлеге эшләрдә чагылыш тапкан һәм качкыннар турында хикәяләгән дүрт риваять – «Баязит урманы», «Хөсәен имәнлеге», «Бәкер тавы» һәм «Миндулла куышы» – соңыннан «Татар халык иҗаты» академик уникетомлыгының 1987 елда нәшер ителгән «Риваятьләр һәм легендалар» китабына урнаштырыла [Татар халык…, б. 92–93].

Р.М. Мөхәммәтҗановның 1996 елда вакытсыз вафатыннан соң, ул башлаган эш безнең тарафтан дәвам иттерелде. 2018 елда нәшер ителгән «Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» китабына без татар фольклор фәнендә беренче тапкыр качкыннар һәм караклар турындагы халык прозасы әсәрләрен тарихи риваятьләр составындагы мөстәкыйль цикл буларак аерып чыгардык, һәм югарыда атап үтелгән дүрт үрнәктән тыш, янә 1996–2010 елларда студентларның фольклор практикасы вакытында язып алынган 13 яңа риваятьне шушы баш астында урнаштырдык [Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр..., б. 139–144]. Алдагы дүрт риваять Башкортстанның Аскын, Караидел, Нуриман кебек төньяк районнарында теркәлгән булса, соңгылары көнбатыш һәм төньяк-көнбатыштагы Туймазы, Кушнаренко, Чакмагыш, Илеш, Балтач һәм Яңавыл районнарында язып алынды.

Соңгы елларда Башкортстанда яшәүче татарларның фольклорын җыю эшенә урындагы энтузиастлар һәм үзешчән тикшеренүчеләр җәлеп ителде. Шундыйларның берсе – Караидел районының Караидел авылында яшәүче язучы һәм журналист Заһит Мурсиев безгә үзе җыйган күпсанлы фольклор үрнәкләрен китерде. Алар арасында төрле характердагы бәетләр дә, риваятьләр дә, сөйләкләр дә, мәзәкләр дә бар. Бу язмалар әлегә кадәр беркайда да басма рәвештә дөнья күрмәгән, алар урындагы халыкның тел үзенчәлекләрен саклап язып алынган, паспортлаштырылган, ягъни җыючы фольклор фәненең барлык таләпләренә дә тугры калып эш иткән. Материаллар арасында Хөснияр качкын турындагы өч риваять тә бар. Аларны Заһит Мурсиев Башкортстанның Аскын районы Әмир авылында туып, хәзер Ханты-Манси автономияле округының Ньяган каласында яшәүче Явидә Мөкъсиновадан (1962 елгы) язып алган. Хөснияр качкын образы Аскын-Караидел якларында шактый киң таралса да, киңкүләм укучыга әлегә кадәр билгеле түгел иде. Димәк, Башкортстанда фольклорчылар өчен һаман да «ак тап» булып калган авыллар да, образлар да шактый булып чыга әле. Шуны истә тотып, Башкортстан

татарлары авызыннан теркәлгән качкыннар һәм караклар турындагы риваятьләрне системалаштырып һәм классификацияләп, язмабызның кушымтасына урнаштыруны максатка ярашлы дип таптык. Текстларның оригиналлары Башкорт дәүләт университеты татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасының фольклор фондында саклана.

Гыйльми тикшерү җәһәтеннән, рус фольклорчысы Н.А. Криничная атап үтелгән цикл риваятьләрен үзәк персонажларының характеры, риваятьченең аларга мөнәсәбәте, мотивлар комбинациясенә карап, ике төркемгә аера. Беренчесенә «изгелекле» караклар турындагы мисаллар караса, икенчесе «гади» караклар хакында сөйләүче үрнәкләрдән тора [Криничная, с. 171]. Әлеге бүленеш Башкортстан татарлары репертуарына карата да үз-үзен аклый.

«Изгелекле» караклар турындагы риваятьләр белән беренче танышудан ук шул күзгә ташлана: барлыкка килү вакыты, геройлары, таралу географиясе, башкаручылары төрле булсалар да, аларга мөһим уртаклык, типологик охшашлыклар хас.

Беренче уртаклык социаль характерлы. «Изгелекле» каракларның берсе дә рәхәт тормыштан байларны талый башламаган, моңа аларны милли-колониаль изү, чиновникларның кансызлыгы, җирле хакимиятнең гади кеше мәнфәгатьләренә битарафлыгы дучар иткән. Мәсәлән, Нуриман районы Кызыл Яр авылында язып алынган «Миндулла куышы» риваятендә бай үз улына «рекрутлык килеп» җиткәч, «чиновникларны сатып ала да, үзенең улы өчен Миндулланы җибәрә... Нык кайгырудан Миндулланың әнисе үлә, ә әтисе чиргә сабыша». Бу хәбәрне ишеткәч, «ничәмә стражникны бәреп ега да егет, сыза урманга». Илеш районы Йонны авылында теркәлгән «Яркәй тавы» исемле үрнәктә үзәк герой патша тарафыннан салынган «авыр салым җыючыларны тукмап», куып җибәрә. Үч алырга дип, кораллы гаскәрләр килгәч, «авылны ташлап, шушы тауга качып китә». Туймазы районы Тукай авылында теркәлгән «Гәрәй сазлыгы» дип аталган әсәрдә кыю егет «байларга көн күрсәтмәгән»лектән, аларның үченнән шушы сазлыкка яшеренеп котылырга мәҗбүр була. Шушы ук районның Карамалы-Гобәй авылында язып алынган «Япарай куышы» исемле риваятьтә Яппар «бик озын» «солдат хезмәтенә барудан» кача. 2021 елда Заһит Мурсиев тарафыннан Аскын районында теркәлгән «Хөснияр качкы» риваятендә исә вакыйгалар Совет чорына күчерелеп, 1941 ел белән нисбәтләнә; үзәк геройның туган җире, яшәү рәвеше дә конкретлаштырыла: «Хөснияр Мөскелде авылыннан булган. Мылтыгы белән ауга йөрергә яраткан. Үзе сал агызуда эшләгән була», – дип әйтелә. Сталин дәверендәге кырыс тәртипләр, каты хөкемгә тарттырылу куркынычы Хөсниярны качкынлык юлына басарга мәҗбүр итә: «Үзе сал агызуда эшләгән була. Шулай 1941 елда, сугыш алдыннан, Уфага сал агызып төшеп баралар. Юлда саллары тарала, ә калганын сатып җибәрәләр. Шуннан соң Хөснияр, хөкем ителүдән куркып, качкылыкка китә». Күренүенчә, әлеге образларда халыкның гадел булмаган җәмгыять тәртипләренә стихиячел протесты чагылыш

таба. Күренекле фольклорчы Фатих Урманче сүзләре белән әйтсәк, «тормыш авырлыгыннан качып, урманда яшәү – азатлык өчен көрәшнең пассив формасы» [Урманче, б. 298]. Шушы юлга басучылар якташларын түрәләр залимлыгыннан яклаучы идеаль геройлар буларак тасвирланып, риваятьченең ачык симпатиясе белән сугарылалар.

Икенчедән, югарыда әйтелгәннәргә бәйле рәвештә, «изгелекле» каракларның зыяны да гади халыкка түгел, ә бары тик эксплуататорларга каршы юнәлтелгәнлеге күзгә ташлана. «Юлда төнен калучыларның мәетләре табыла – байларныкы, патша чиновникларыныкы. Баязит качкын аларның байлыкларын, атларын ярлыларга өләшкән», – дип әйтелә Караидел районы Багазы авылында теркәлгән «Баязит урманы» риваятендә. «Миндулла куышы» исемле үрнәктә дә герой бары тик «байларның юлларын баса, аларның малларын, акчасын ярлыларга өләшә». Аскын районы Аскын авылында язып алынган «Бәкер тавы» риваятендә дә батыр «авыл байларына һич көн күрсәтмәгән». Яңавыл районы Айбүләк авылында теркәлгән «Кокушкин тавы» риваятендә Кокуш исемле атаман «бай кешеләрне талап көн күргән, ә ярлыларга кагылмаган». Совет чорында иҗат ителгән «Хөснияр качкы» риваятенә дә шушы традицион мотив күчерелә: герой «яшеренеп кенә авылына кайтып йөргән була, ләкин ярлы-ябаганың әйберенә тимәгән. Киресенчә, тапкан малын өләшеп бирер булган». Шулай итеп, бу образлар һәммәсе дә аерым бер урынга бәйләнгән һәм локаль характерда булсалар да, аларны бер үк төрле типологик охшашлыклар берләштерә.

Өченчедән, качкыннар нинди генә кыю, көчле рухлы шәхес булмасыннар, аларның язмышы бары тик фаҗига белән генә тәмамлана, бу геройлар я үтерелә, я сөргенгә җибәрелә, я хәбәрсез югала. Мәсәлән, «Бәкер, каты чабып килгән уңайга, аты белән таудан елгага ташланган, ди» («Бәкер тавы»); «Миндулланы сөргенгә җибәрәләр. Бүтән бу якка кайтмый инде ул, һәлак булгандыр» («Миндулла куышы»); «Ләкин патша гаскәрләре барыбер Яркәй качкынны тотып алганнар» («Яркәй тавы»); «Байлар сазлыкны бер ел буена көнетөне саклаганнар, имеш. «Гәрәй дә шунда ачлыктан үлгән икән», – дигән имеш-мимешләр йөри халык телендә» («Гәрәй сазлыгы»). Бу исә җәмгыятьтәге гаделсез тәртипләргә каршы ялгыз стихиячел баш күтәрүләрнең нәтиҗәсезлеген, перспективасыз булуын халыкның төшенүен аңлата. Татарларда юкка гына «Ялгыз сыерчык яз китерми»,– дигән мәкаль йөрми бит. Фатих Урманче билгеләвенчә, «Русия империясендә милли һәм социаль изү шулкадәр көчле була ки, гади халык аннан качкын булып кына котыла алмый, әлбәттә» [Урманче, б. 298]. Бары тик соңрак чорда иҗат ителгән «Хөснияр иректә» риваятендә генә геройның XX гасырның 70 нче елларында милиция майоры кыяфәтендә Свердловск шәһәрендә йөрүе хәбәр ителә. Ләкин ул кулга алынмаса да, барыбер яшеренеп яшәргә мәҗбүр була. Димәк, моны да тулы ирек дип атап булмый. Шулай итеп, фаҗигалылык, драматизм әлеге төр риваятьләр өчен янә бер уртак сыйфат булып тора. Бу исә аларны бәет жанры поэтикасына якынайта.

Н.А. Криничная билгеләвенчә, «изгелекле» карак образларында «рудиментлар формасында булса да, кайбер архаик сыйфат һәм функцияләрнең саклануы күзгә ташлана [Криничная, с. 174]». Бу – татар риваятьләренә дә хас күренеш. Аеруча ул качкыннарның килеш-килбәтен, көчен тасвирлаганда ачык сизелә. Мәсәлән, «Баязит качкын зур, мәһабәт гәүдәле, чем кара озын чәчле булган... Аты исә теләсә нинди сазлыкларны да, елга-күлләрне дә җилдәй үткән» («Баязит урманы»); Миндулла «әле яшүсмер чагында ук өч яшьлек үгезне бер сугуда үтереп салган» («Миндулла куышы»); «Кокушның сызгыруы берничә чакрымга ишетелгән» («Кокушкин тавы»); «Хөснияр югалып калмый, өйнең мөешен күтәреп, баздан чыгып кача», «Качкы ике яклап саклап торган милиционерларның якаларыннан тотып башлары белән чәкәштерә дә, тәрәзәдән чыгып та кача» («Хөсниярнең үткерлеге»). Әлеге тасвирламаларда борынгы зооморфик һәм антропоморфик күзаллауларның, алыпларга бәйле мифологик традицияләрнең, трансформация кичереп, социаль характердагы «изгелекле» караклар турындагы риваятьләр тукымасына килеп керүен сиземләргә була. Фольклор әсәрләре өчен бу – табигый күренеш. Мәсәлән, 1773–1775 еллардагы Крестьян сугышы турындагы тарихи риваятьләр циклында Салават Юлаев һәм Емельян Пугачев образларына легендар алыпларга хас сыйфатлар күчерелүен без Башкортстан татарларыннан язып алынган күпсанлы үрнәкләргә таянып исбатлаган идек инде [Фазлутдинов, с. 308–310]. Шушы ук алым качкыннар һәм караклар турындагы әсәрләрдә дә кабатлана.

«Баязит урманы» риваятендәге качкынның үлемен тасвирлаган эпизодта да мифологик карашларның калдыкларын күрергә мөмкин. Биредә «Бервакыт үзенең сөйгәне Маруся янына килгәндә, сагалап торып, Баязитны тотып алалар. Ычкыныр иде, озын чәченнән эләктергәннәр. Һәлак була Баязит качкын»,– дип хәбәр ителә. Ягъни, качкынның үлеменең сәбәбе аның чәче дошман кулына эләгү белән аңлатыла. Күренекле фольклорчы В.Я. Пропп билгеләвенчә, борынгы җәмгыятьтә «чәч – җан я магик көч урыны. Чәчсез калу – көчне югалту» булып исәпләнгән [Пропп, с. 41]. Әлеге фикер башка галимнәр тарафыннан да куәтләнә [Татар мифлары, б. 274; Минһаҗетдинов, б. 211–212; Турсунов, с. 175]. Мәсәлән, Г.Н. Потанин мәгълүматлары буенча, тува халкының батырлар турындагы әкиятендә Хангавай атлы пәһлеван, үзе җиңгән Ерсары – Мөгенең көчен юкка чыгару өчен толымын кисеп ала [Турсунов, с. 174]. Башкорт фольклорчысы Ә.М. Сөләйманов исә «эпик кобаерларда, батырлар турындагы әкиятләрдә кошка әверелеп очарга сәләтле кызның (яки кыз-батырның) герой толымыннан эләктерүе була – ул шунда ук үзенең җиңелүен таный»,– дип яза һәм бу фикерен «Акбүзат», «Заятүләк белән Сусылу» эпослары һәм «Һанай батыр» әкияте мисалында раслый [Сөләйманов, б. 309]. Шулай итеп, «чәчсез булу – ул изге мифик көчләрнең яклавыннан мәхрүм булу дигән сүз, җаныңны явыз мифик көчләргә бирү дигән сүз» [Минһаҗетдинов, б. 212]. Шулай итеп, төрле халыклар фольклорында чәчкә

тылсымлы сыйфатлар биреп, аны җан һәм көч саклана торган сакраль урын итеп санау типологик уртаклык булып тора.

Димәк, «Баязит урманы» риваятендәге качкынның үлеме дә һич тә очраклы түгел. Ул чәче дошман кулына эләгү аркасында һәлак була. Чәчен югалту белән бергә, ул үзенең көчен дә җуя. Шулай итеп, борынгы мифологик мотив, беренче карашка, тулысынча реаль, социаль эчтәлеккә корылган хикәяткә дә килеп керә. Димәк, качкыннар турындагы риваятьләрнең генетик тамырлары борынгы мифологиягә килеп тоташа дип исәпләргә мөмкин. Риваятьтә моны дәлилләүче тагын бер күрсәткеч бар. Баязит үзе үлсә дә, аның җаны үлми, «шәүләсе, байларга шом салып, озак еллар урманда йөргән, имеш. Урман исеме дә шуннан торып калган». Көчләп үтерелгән кеше каны түгелгән җирдә өрәк күренү – шулай ук борынгы мифологик ышану. Тикшеренүчеләр фикеренчә, ул татарларда ислам кергәнче үк яшәгән [Насыйри, б. 51; Татар мифлары, б. 130–138]. Димәк, әлеге социаль эчтәлекле риваятьтә дә без анда тасвирланган вакыйгалардан күпкә алданрак туган мәҗүси ышануларның традиция буларак дәвам ителүен күрәбез.

Н.А. Криничная билгеләвенчә, «изгелекле» карак образы халыкның тарихи прозасында алдарак формалашкан «гади» карак образын кысрыклап чыгара алмый, чөнки чынбарлыкта да алар янәшә яшәп киләләр [Криничная, с. 172]». Шуңа күрә дә Башкортстан татарларының качкыннар һәм караклар турындагы риваятьләр циклында «гади» караклар турындагы әсәрләр дә шактый. Аларның «изгелекле» карак образларыннан төп аермасы талау, юл басуларның характерына кайтып кала. «Изгелекле» караклар бары тик байларны гына талап, тапкан малларын гади халыкка өләшсәләр, «гади» караклар байларның да, ярлыларның да мөлкәтен тартып алалар, аерма ясамыйлар; урланган байлыкны да фәкать үз мәнфәгатьләрендә генә файдаланалар. Шуңа күрә дә соңгы типтагы риваятьләрдә сөйләүченең бу образга карата симпатиясе сизелми. Шул ук вакытта ачыктан-ачык антипатиясен дә тоемлау авыр. Нигездә, мондый риваятьләр урын атамасын артык эмоциональ-экспрессив төсмерләргә баетылмаган вакыйга белән аңлатудан гыйбарәт.

«Изгелекле» караклар турындагы риваятьләрдә, гадәттә, батыр һәлак булган урын («Баязит урманы», «Бәкер тавы», «Гәрәй сазлыгы»), я булмаса ул патша гаскәрләреннән яшеренеп яткан җир («Япарай куышы», «Миндулла куышы», «Яркәй тавы», «Кокушкин тавы») әлеге качкынның исемен алса, «гади» караклар хакында сөйләүче әсәрләрдә аларның исеме белән халыктан урлап алынган мал-мөлкәт яшереп сакланган чокыр-ерымнар атала. Моңа мисал итеп Туймазы районы Бишенде авылындагы «Әхмәт кулы», Кушнаренко районы Илек авылындагы «Каһәрмән чокыры», Чакмагыш районы Калмашбаш авылындагы «Гайнетдин чокыры» кебек риваятьләрне китерергә мөмкин. Бу урыннарның һәммәсендә дә исемнәре әлеге топонимнарга күчкән каракларның урланган мал-мөлкәте ят күзләрдән яшереп сакланган.

Хәтта урын-җир атамасында «гади» каракның исеме урын алуы аның биредә һәлак булуы белән аңлатылган очракта да, бу үлем һәртөрле героикадан азат. Карак, кагыйдә буларак, я мал бүлешкәндә, я аның байлыгыннан көнләшүчеләр тарафыннан үтерелә. Мәсәлән, «Каһәрмән чокыры» риваятендә әлеге исемне йөрткән ике чокыр барлыгы турында хәбәр ителә. Бер чокырда «Каһәрмән үзенең урлаган, талаган мал-мөлкәтен җыеп» сакласа, икенчесендә «аны икетуганы кыйнап үтергән». Ачыктан-ачык экспрессив буяулар белән тасвирланмаса да, биредә риваятьченең позициясен дә тоярга була, аның «юньле кешене туганы үтерми» дигән караште торганлыгы сизелә. Каракны һәлакәткә бары тик кансызлыгы һәм намуссызлыгы гына китерә. «Гайнетдин чокыры» исемле риваятьтә дә әлеге шәхеснең икейөзлелегенә ишарә бар: «Рапат авылында элек Гайнетдин исемле кеше яшәгән. Бар яктан да аңлы, сәләтле булган ул. Йөзе – матур, сүзе – татлы, кешеләрне бер карауда үзенә тарткан. Аны бар кеше дә яраткан. Беркем дә аның кире якларын күрмәгән. Чынлыкта исә, Гайнетдин җиңел юл белән баюга исәп тоткан...»

«Изгелекле» караклар турындагы риваятьләрдән аермалы буларак, «гади» караклар хакында сөйләүче әсәрләрдә аларның юлбасарлык юлына басуының бер генә сәбәбе дә китерелми, бу хакта, гомумән, телгә алынмый. Димәк, кешенең угрылыкка тотынуына халык хәтеренә сеңеп калырлык бернинди җитди социаль мотивация дә юк булып чыга. Әлеге мотивның «гади» караклар турындагы риваятьләрдә урын алмавы, риваятьчеләрнең аларга кире караште торуларына ишарәли, чөнки «изгелекле» караклар хакындагы әсәрләрнең һәммәсендә дә кешенең угрылык юлына басуы социаль сәбәпләр, җәмгыятьнең гаделсезлеге белән аңлатыла һәм бу образлар ачыктан-ачык сөйләүченең симпатиясе белән сугарыла. Шулай да, «гади» караклар турындагы әсәрләрдә информаторларның аларга симпатиясе яки антипатиясе турыдан-туры хәбәр ителми, моны бары тик ишарә рәвешендә генә тоемларга була.

Аның каравы, Башкортстан татарларының «изгелекле» һәм «гади» караклар циклындагы риваятьләрендә качкыннарга маҗаралы әкият герое сыйфатларын биреп карау да ачык сизелә. Фольклорчы Ф.А. Нәдершина бу күренешнең әлеге типтагы башкорт риваятьләрендә дә зур урын тотуын «Бейеш», «Кызырын таш-Ибли йорты», «Айчуак маҗаралары», «Буранбай» кебек әсәрләр мисалында билгеләп үтә [Нәҙершина, б. 278–280]. Димәк, риваятьләргә әкият традицияләре килеп керә.

Аларның иң зурысы – качкыннарны гаять акыллы, хәйләкәр һәм шуңа күрә тоттырмас зат итеп сурәтләүдән күренә. Мәсәлән, Гайнетдин карак «урлашканда атының дүрт аягына да тискәре итеп чабата кидерә торган булган. Бу ат эзен яшерү өчен эшләнгән» («Гайнетдин чокыры»); «Тотылмас өчен, Хөсәен качкын итеген тискәре кигән. Эзәрлекләүчеләр аны эзләп, капма-каршы якка китә торган булганнар» («Хөсәен имәнлеге»). Дошманнан әлеге ысул белән – аяк киеменең тискәре ягын киеп котылу мотивы югарыда телгә алынган

риваятьләрдә реаль төсмерләр алып, эзәрлекләүчеләрне хата юлдан җибәрү вазифасын үтәсә дә, аның тамырлары тирәнгәрәк, борынгы мифологиягә килеп тоташа. Мәсәлән, М.А. Васильев тарафыннан 1915 елда Стәрлетамак өязе Толбазы авылында язып алынган «Шүрәлене ничек алдарга?» мифологик хикәятендә урманда шүрәле адаштырган кызлар нәкъ шул юл белән, киемнәрен – тискәре ягы белән, ә башмакларын сулын – уң аякка, уңын – сул аякка киеп, әлеге затның тылсымыннан котылалар [Татар халык..., б. 276]. Башкортстан татарларының йола иҗатын тикшерүче Р.М. Мөхәммәтҗанов исә кияүгә чыгасы кызның туй алдындагы кичне мунча кергәч, явыз рухлар зыян салмасын өчен, күлмәген кире ягы белән киюе турында яза [Мөхәммәтҗанов, б. 42]. Бу исә – явыз көчләрне алдауга юнәлтелгән экзапатетик магия күренеше.

Димәк, борынгы халык киемнең тискәре ягын киюгә илаһи мәгънә салган, шул рәвешле явыз рухларны алдап, үзен танытмаска һәм аларның зыяныннан котылырга өмет иткән. Анализланучы риваятьләрдәге дошманны аяк киеменең тискәре ягын киеп юлдан яздыру мотивын да без әлеге борынгы экзапатетик ышануның трансформация кичереп, тылсымын җуеп, реаль тормышка якынлашуының нәтиҗәсе итеп карарга тиешбез. Аерма тик шунда: борынгы ышанудагы явыз рухлар урынын эзәрлекләүчеләр, я булмаса патша солдатлары ала, аяк киеменең тискәре ягын кию магик максатларда түгел, ә практик ихтыяҗдан чыгып, куып килүчеләрне ялгыш юлга җибәрү өчен файдаланыла. Шулай итеп, әлеге мотивның генетик тамырлары борынгы мифологиягә килеп тоташу һич шик тудырмый.

«Хөсәен имәнлеге» риваятендә каракның беркемнән дә тоттырмавын халык, маҗаралы әкиятләр өчен традицион алым кулланып, аның хәйләкәрлеге белән исбатлый. «Шулай бервакыт, Хөсәенне, шарт та шорт мылтык атып, патша солдатлары куалар. Суга бүрәнә төшереп җибәрә дә үзе яр астына поса. Хөсәен качкын дип белеп, бүрәнәгә ата башлыйлар. Бүрәнә арчыган ягы белән өскә әйләнә. «Әләкте, корсагы белән өскә әйләнде»,– дип, патша солдатлары, мылтыкларын иңнәренә салып, килгән юлларыннан китәләр». Шушы ук традицион мотив XX гасырның икенче яртысында иҗат ителгән «Хөсниярнең үткерлеге» риваятендә дә кабатлана: «Хөсниярне тотып район милиция бүлегенә япканнар. Төрмә дигәннәре яр буенда гына, имеш. Качкы төн буена стенаны кырып, кулына ком җыйган. Шуннан, кысталам дип, милиционерны чакырган. Тегесе ишекне ачуга, күзенә ком сибә дә, Хөснияр чыгып йөгерә. Милиционер күзен уып ачканчы, Хөснияр елга буена килеп җитә. Шунда яткан түмәрне алып суга ыргыта һәм шым гына юк була. Шаптырдаган тавышны ишеткән милиционер, тоткын суга сикерде, дип, шул тарафка пуляларын ата башлый. Пулялар бетә, яр буе тынып кала». Әлеге юллар качкыннарның халык аңында хәйләкәрлек, үткерлек символы булып чыгыш ясауларын раслый.

Качкыннар һәм караклар турындагы риваятьләрдә, нигездә, XVIII гасыр башыннан алып XX гасыр урталарында кадәр булган

вакыйгалар, социаль катламнар, җәмгыять тәртипләре чагылыш таба. Димәк, әлеге әсәрләр дә якынча шул чорларда иҗат ителгән булып чыга. Бу инде – борынгы мифологик карашлар җуела төшкән, мәҗүсилек эзләре чагыштырмача аз сакланган дәвер. Шуңа күрә дә риваять тукымасына алар трансформация кичереп, тылсымлылык сыйфатларын бары тик ишарәләр рәвешендә генә саклаган хәлдә килеп керәләр. Тамырлары белән мифологиягә килеп тоташкан мотивлар, сюжет элементлары биредә конкрет тарихи җирлек, тарихи чор, конкрет шәхесләр эшчәнлеге белән тыгыз үрелеп килә. Шулай итеп, тикшерелгән риваятьләр реаль чынбарлык күренешләре белән халкыбызның мифологик карашларын, иҗади фантазиясен бергә берләштереп килә һәм фольклорның башка жанрлары белән тыгыз мөнәсәбәттә торып, кабатланмас синтез тудыра.

**Әдәбият**

Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррире Ә.М. Сөләйманов. Уфа: Китап, 2018. 344 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 312 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 296 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. – 304 б.

*Криничная Н.А.* Русская народная историческая проза: вопросы генезиса и структуры / отв. ред. В.К. Соколова. Л.: Наука, 1987. 232 с.

*Минһажетдинов М.Х.* Ҡәләмендә ҡөҙрәт бар: монография, әҙәби тәнҡит һәм башҡорт фольклористикаһына арналған хеҙмәттәр / төҙөүселәре, баш һүҙ авторҙары Т.А. Килмөхәммәтов һәм Ә.М. Сөләймәнов. Өфө: Китап, 1995. 256 б.

*Мөхәммәтҗанов Р.М.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты / төзүчеләр: И.И. Ямалтдинов, И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 228 б.

*Насыйри Каюм.* Сайланма әсәрләр: ике томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 320 б.

*Нәҙершина Ф.А.* Риүәйәт һәм легендаларҙа халыҡ тарихы. Тулыландырылған баҫма. Өфө: Китап, 2011. 360 б.

*Пропп В.Я.* Исторические корни волшебной сказки / вступ. статья В.И. Ереминой. 2-е изд. Л.: Издательство ЛГУ, 1986. 364 с.

*Сөләймәнов Ә.М.* Әкиәттә хәҡиҡәт: башҡорт көнкүреш әкиәттәренең жанр составы, сюжет төрлөлөгө, тормош ерлеге. Өфө: Китап, 1997. 400 б.

Татар мифлары: иияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Икенче китап / Галимҗан Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 432 б.

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов; фәнни редакторы Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 368 б.

*Турсунов Е.Д.* Генезис казахской бытовой сказки: в аспекте в связи с первобытным фольклором. Алма-Ата: Наука, 1973. 216 с.

*Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты. Казан: Мәгариф, 2005. 383 б.

*Фазлутдинов И.К.* Синтез исторических и мифологических воззрений в преданиях населения северо-западного Башкортостана // Славянские этносы, языки и культуры в современном мире: материалы VII Международной научно-практической конференции, посвященной 95-летию со дня рождения доктора филологических наук профессора Леонида Михайловича Васильева (г. Уфа, 23 сентября 2021 г.) / отв. ред.: В.Л. Ибрагимова, Л.А. Киселева. Уфа: РИЦ БашГУ, 2021. С. 303–311.

*КУШЫМТА*

## I. «Изгелекле» караклар һәм качкыннар турындагы риваятьләр

### *1. Баязит урманы*

Баязит качкын зур, мәһабәт гәүдәле, чем кара озын чәчле булган. Тирә-як байлары, алпавытлар аннан уттан курыккандай куркалар. Юлда төнен калучыларның мәетләре табыла – байларныкы, патша чиновникларыныкы. Баязит качкын аларның байлыкларын, атларын ярлыларга өләшкән. Үзенең аты исә теләсә нинди сазлыкларны да, елга-күлләрне дә җилдәй үткән.

Бервакыт үзенең сөйгәне Маруся янына килгәндә, сагалап торып, Баязитны тотып алалар. Ычкыныр иде, озын чәченнән эләктергәннәр. Һәлак була Баязит качкын. Ә шәүләсе байларга шом салып, озак еллар урманда йөргән, имеш. Урман исеме шуннан торып калган.

*1977 елда Башкортстанның Караидел районы Багазы авылында*
*Туктабикә Гыйниятуллинадан (1918 елгы)*
*Мөхәммәт Закиров язып алган*

### *2. Бәкер тавы*

Аскын районы Күбияз авылы янында Бәкер тавы бар. Җирле халык сөйләвенә караганда, элек Бәкер исемле кыю кеше булган. Авыл байларына һич көн күрсәтмәгән ул. Бервакыт аннан үч алмакчы булганнар. Бәкер текә тау өстендә, котылыр әмәл юк икән. Аста Төй елгасы аккан. Бәкер, каты чабып килгән уңайга, аты белән, таудан елгага ташланган, ди. Аның чын исеме Әбүбәкер булуга карамастан, тауны халык «Бәкер тавы» дип йөртә.

*1977 елда Башкортстанның Аскын районы*
*Аскын авылында Фәйхунә Вәлиевадан (1946 елгы)*
*Мөхәммәт Закиров язып алган*

### *3. Гәрәй сазлыгы*

Элек авылда Гәрәй исемле кеше булган. Ул авыл байларына һич көн күрсәтмәгән, ди. Байлар бервакыт моңардан үч алмакчы булганнар.

Бу турыда ишетеп, Гәрәй авылдан ерак булмаган бер сазлык эченә кереп качкан. Байлар сазлыкны бер ел буена көне-төне саклаганнар,

имеш. «Гәрәй дә шунда ачлыктан үлгән икән»,– дигән имеш-мимешләр йөри халык телендә. Сазлык шуңа – «Гәрәй сазлыгы».

*1996 елда Башкортстанның Туймазы районы Тукай авылында Хәҗәр Шафыйковадан (1929 елгы) Земфира Шакирова язып алган*

### 4. Кукушкин тавы

Безнең авылда җир җиләгеп җыярга «Урыс ягы»на йөриләр. «Урыс ягы» дип урыслар яшәгән Зайцево, Орловка[1] авыллары тирәләрен әйтәләр. Шундагы җиләккә иң бай урыннарның берсе – «Кукушкин тавы».

Элек бу тауда үзенең кешеләре белән Кокуш исемле атаман яшәгән. Тау янында матур күл җәелеп яткан, анда бик күп су кошлары, хәтта аккошлар да йөзеп йөргән. Кокуш үзенең көче һәм батырлыгы белән тирә-якта дан тоткан. Ул якындагы бай кешеләрне талап көн күргән, ә ярлыларга кагылмаган. Кокушның сызгыруы берничә чакрымга яңгыраган. Аны ишетү белән халык Кокушның уңышлы аудан кайтуын, яисә үз кешеләрен җыюын аңлаган.

Кокуш яшәгән тауны халык «Кокуш тавы» дип йөрткән. Соңрак, халык теленә җайлашып, ул «Кукушкин тавы» дип атала башлаган.

*1998 елда Башкортстанның Яңавыл районы музее материалларыннан Гөлчәчәк Әүхәтова күчереп алган*

### 5. Миндулла куышы

Миндуллалар авыл очында торганнар. Йортлары бәләкәй генә, салам түбәле була. Әтисе һәм әнисе байда батраклыкта йөриләр. Ярлыларның да ярлысы була алар. Көне-төне эшләсәләр дә, бернәрсә дә арттыра алмыйлар. Менә Миндуллага да рәхәт көннәр бетә, аны да көтү көтәргә куялар. Иртән тору, мал куу һәм төрле эшләрне эшләү аның көчен арттырган. Киң күкрәкле, көчле егет булып үсеп җиткән. Сокланмаган кеше булмый аңа. Әле яшүсмер чагында ук өч яшьлек үгезне бер сугуда үтереп салган, дип сөйлиләр аның турында.

Бервакыт бай улына рекрутлык килеп җитә. Бай чиновникларны сатып ала да үзенең улы өчен Миндулланы җибәрә.

Миндулланың әтисе, байга барып, дөреслекне табарга тырышкан, ләкин аны хатыны белән урамга чыгарып бызактырганнар[2]. Нык кайгырудан Миндулланың әнисе үлә, ә әтисе чиргә сабыша. Бу хәбәр ничектер приемда утырган Миндуллага килеп җитә. Приемдагы ничәмә стражникны бәреп ега да егет, сыза урманга.

Бу якларда, Караидел[3] буенда тау куышы бар. Әле дә «Миндулла куышы» дип йөртәләр. Шунда үз ише ярлы егетләрне җыя һәм байлардан үчен ала башлый Миндулла. Аның исемен ишетүгә, байлар дер калтырый башлыйлар. Миндулла байларның юлларын баса,

[1] *Зайцево, Орловка* – Башкортстанның Яңавыл районындагы авыллар/

[2] *Бызактыру* (диал.) – ыргыту, ату.

[3] *Караидел* – Чиләбе, Свердловск өлкәләре һәм Башкортстан аша агып, Агыйделгә коючы елга.

аларның малларын, акчасын ярлыларга өләшә. Ләкин сатлыкҗаннар аны патша жандармнарына тотарга ярдәм итәләр. Миндулланы сөргенгә җибәрәләр. Бүтән бу якка кайтмый инде ул, һәлак булгандыр. Тик менә, батырлыгы хакында һәйкәл булып, тау куышы тора.

*1971 елда Башкортстанның Нуриман районы*
*Кызыл Яр авылында Вәсбиямал Хәйбрахмановадан (1899 елгы)*
*Д. Зиннуров язып алган*

### 6. Хөсәен имәнлеге

Хөсәен качкынның төтене землянкасыннан өч чакрым читтә чыккан. Җирне казып, ул шулай төтен юлы ясаган, имеш.

Тотылмас өчен, Хөсәен качкын итеген тискәре кигән. Эзәрлекләүчеләр, аны эзләп, капма-каршы якка китә булганнар.

Шулай бервакыт Хөсәенне, шарт та шорт мылтык атып, патша солдатлары куалар. Суга бүрәнә тәгәрәтеп төшереп җибәрә дә, үзе яр астына поса. Хөсәен качкын дип белеп, бүрәнәгә ата башлыйлар. Бүрәнә арчыган ягы белән өскә әйләнә.

«Әләкте, корсагы белән өскә әйләнде», – дип, патша солдатлары, мылтыкларын иңнәренә салып, килгән юлларыннан китәләр.

Авыл янындагы имәнлекне «Хөсәен имәнлеге» дип йөртәләр.

*1977 елда Башкортстанның Караидел районы*
*Багазы авылында Әхмәт Салиховтан (1915 елгы)*
*Мөхәммәт Закиров язып алган*

### 7. Хөснияр качкы[1]

Хөснияр Мөскелде авылыннан булган. Мылтыгы белән ауга йөрергә яраткан. Үзе сал агызуда эшләгән була. Шулай 1941 елда, сугыш алдыннан, Уфага сал агызып төшеп баралар. Юлда саллары тарала, ә калганын сатып җибәрәләр. Шуннан соң Хөснияр, хөкем ителүдән куркып, качкылыкка китә. Яшеренеп кенә авылына кайтып йөргән була, ләкин ярлы-ябаганың әйберенә тимәгән. Киресенчә, тапкан малын өләшеп бирер булган.

Хөснияр качкының төтене землянкасыннан өч чакрым читтә чыккан, имеш. Тотылмас өчен ул итеген башы белән артка каратып кия торган булган, аны эзәрлекләүчеләр, итек эзенә алданып, кире якка китә торган икән. Шулай бервакыт Хөсниярне, шарт та шорт мылтык атып, солдатлар куалар, ди. Ул суга бүрәнә тәгәрәтеп төшереп җибәрә дә, үзе яр астына поса. Солдатлар караңгыда бүрәнәне Хөснияр дип шәйли һәм ата башлыйлар. Шулчак бүрәнә каерысы каезланган ягы белән өскә әйләнә. Әләкте моңа, корсагы белән өскә калкып чыкты, дип, солдатлар, мылтыкларын иңнәренә салып, килгән юлларына китәләр. Авыл янындагы имәнлек шуннан соң «Хөснияр имәнлеге» дип атала башлый.

*2019 елда Башкортстанның Аскын районы Әмир авылында туып,*
*хәзер Ханты-Манси автономияле округының*
*Ньяган каласында яшәүче Явидә Мөкъсиновадан (1962 елгы)*
*Заһит Мурсиев язып алган*

[1] *Качкы* (диал.) – качкын.

### *8. Хөсниярнең үткерлеге*

Бервакыт Хөснияр халык җыенына килә. Аның монда икәнен белгән милиционерлар, кешеләрне ерып, тотарга дип киләләр. Хөснияр качып өлгерә һәм бер авылдашы аны базына яшерә. Милиционерлар килеп базга төшә башлыйлар. Ләкин Хөснияр югалып калмый, өйнең мөешен[1] күтәреп, баздан чыгып кача.

Икенче тапкырында Хөсниярне барыбер тотканнар. Суд бара, моңардан хөкемдар сорый икән:

– Төрмәдән ничек качтыгыз?

– Менә болай, – дип, качкы ике яклап саклап торган милиционерларның якаларыннан тотып башлары белән чәкәштерә дә, тәрәзәдән чыгып та кача.

Хөсниярне, тотып, район милиция бүлегенә япканнар. Төрмә дигәннәре яр буенда гына, имеш. Качкы төн буена стенаны кырып, кулына ком җыйган. Шуннан, кысталам дип, милиционерны чакырган. Тегесе ишекне ачуга, күзенә ком сибә дә, Хөснияр чыгып йөгерә. Милиционер күзен уып ачканчы, Хөснияр елга буена килеп җитә. Шунда яткан түмәрне алып суга ыргыта һәм шым гына юк була. Шаптырдаган тавышны ишеткән милиционер, тоткын суга сикерде, дип, шул тарафка пуляларын ата башлый. Пулялар бетә, яр буе тынып кала.

Шулчак еректан Хөсниярнең тавышы ишетелгән, ди:

– Нәрсә, мент, шул нәрсәмне тоттыңмы?

*2019 елда Башкортстанның Аскын районы Әмир авылында туып,*
*хәзер Ханты-Манси автономияле округының*
*Ньяган каласында яшәүче Явидә Мөкъсиновадан (1962 елгы)*
*Заһит Мурсиев язып алган*

### *9. Хөснияр иректә*

Биявәшкә[2] эре бәрде – хариус тула торган иде, аны тотар өчен буа эшләп, талчыбыктан үреп, мурда салына иде. Бер тапкыр балык юк, кемдер караңгыда килеп, карап алып китә. Нишләргә? Әни белән әти киңәшләштеләр дә, мылтык көпшәсенә тоз тутырып, мурдадагы балыкны сакларга Бәхет күле тирәсендә чыгып яттылар.

– Менә килде, ди теге кеше, суга ерып кереп, буага басып, мурданы күтәрәм дип, иелүе булды, күтенә тоз белән атуым булды, – ди әтием. – Бу каракның ничек йөгереп качканын күрсәгез! – дияр иде... Кем булды икән, ничек этләнде икән… әлегәчә бу хәл сер булып калды, әтием дә кем икәнен белмәде, ләкин бик тә Хөсниярга охшаган иде, ди...

Җитмешенче елларда безнең авылдан бер кеше Свердлау каласына барган. Урамда милиция майорын танып калган, ди:

– Хөснияр, син монда нишләп йөрисең? – дип сораган.

---

[1] *Мөеш* (диал.) – почмак.

[2] *Биявәш* – Пермь өлкәсеннән чыгып, Башкортстанның Аскын районы буенча агучы елга.

– Бирермен мин сиңа Хөсниярне. Унике сәгать эчендә бу шәһәрдән юк бул! – дигән тегесе.

*2019 елда Башкортстанның Аскын районы Әмир авылында туып, хәзер Ханты-Манси автономияле округының Ньяган каласында яшәүче Явидә Мөкъсиновадан (1962 елгы) Заһит Мурсиев язып алган*

### *10. Яркәй тавы*

Хәзерге Яркәй[1] авылы янындарак «Яркәй тавы» дигән урын бар. Аның тарихы мондый.

Элек патша хөкүмәте халыкка бик авыр салым салган. Яркәй исемле кеше җитәкчелегендәге авыл халкы салым җыючыларны тукмап, куып җибәргән. Озак та үтми, хөкүмәтнең коралды гаскәрләре килгәч, Яркәй авылны ташлап, шушы тауга качып киткән. Ул шушында тау куышында качып яткан. Ләкин патша гаскәрләре Яркәй качкынны барыбер тотып алганнар. Шуннан бирле бу тауны «Яркәй тавы» дип йөртәләр.

*1998 елда Илеш районы Иштирәк авылында Кашбелгаян Ногмановтан Таңсылу Ногманова язып алган*

### *11. Япарай куышы*

Элекке заманда патша армиясендә хезмәт вакыты бик озын була. Яппар исемле егет, солдат хезмәтенә барудан качып, тау буендагы җирне чокый һәм урман эчендә куыш кора. Хезмәт срогы тулганчы, ул шунда яши.

Бу урынны кеше үтеп керә алмаслык кара урман каплап торган була. Шуңа да егетне беркем дә таба алмый. Шуннан бирле бу урынны халык «Япарай куышы» дип атый.

*1999 елда Туймазы районы Карамалы-Гобәй авылында Фазлый Камалиев (1908 елгы) истәлекләреннән Фәнилә Бәйрәмова күчереп алган*

## II. «Гади» караклар турындагы риваятьләр

### *12. Әхмәт кулы*

Бу чокырда элек, Әхмәт исеме ат карагы иптәшләре белән качып яткан булган. Яшерен сукмаклардан төрле якларга кәсепкә йөреп, атларын да шушында тоткан. Бу атама шулай барлыкка килгән.

*1998 елда Башкортстанның Туймазы районы Тукай авылында Айгөл Хаҗиева язып алган. Информаторы күрсәтелмәгән*

### *13. Әпес тавы*

Исәнбай* авылында элек Әпес исемле кеше яшәгән була. Бервакыт ул Игъмәт* авылына юлга чыга. Ләкин, юлда ниндидер хәл

[1] *Яркәй* – Югары Яркәй, Башкортстанның Илеш районындагы авыл.

булып, ул шушы таудагы урманга качып китә. Авыл халкы аны бары-бер тотып ала.

Бу урман инде күптән киселеп, урыны сөрелеп беткән, ләкин ха-лык кайчандыр ул урнашкан тауны һаман да «Әпес тавы» дип атый.

*1998 елда Башкортстанның Илеш районы*
*Рсай авылында Мәгъсүм Кашаповтан (1927 елгы)*
*Айгөл Сәетова язып алган.*

### *14. Гайнетдин чокыры*

Рапат авылында элек Гайнетдин исемле кеше яшәгән. Бар яктан да аңлы, сәләтле булган ул. Йөзе матур, сүзе татлы икән, кешеләрне бер карауда үзенә тарткан. Аны барысы да яраткан. Беркем дә аның кире якларын күрмәгән.

Чынлыкта исә, Гайнетдин җиңел юл белән баюга исәп тоткан. Аның бик яхшы, өйрәтелгән эт шикелле аты булган. Шул аты белән Гайнетдин еракларда сарык, кәҗә һәм башка төрле терлекләрне бик оста итеп урлаган.

Авыл читендә тирән чокыр булган. Кешеләр аны читләтеп үтә торган булганнар, нәрсәдәндер шикләнгәннәр. Гайнетдин шушы чокырда урланган малларны чалган. Урлашканда атының дүрт аягы-на да чабата кидерә торган булган. Бу ат эзен яшерү өчен эшләнгән. Хәзер Гайнетдин юк, ә чокыр әле дә бар, аны һаман да «Гайнетдин чокыры» дип йөртәләр.

*1999 елда Башкортстанның Чакмагыш районы*
*Рапат авылында Зөләйха Хәбировадан*
*Ирина Насыйрова язып алган*

### *15. Кара сыер чишмәсе*

«Кара сыер чишмәсе» Байгуҗа авылында, Бәрсүән елгасы башында урнашкан. Борынгы заманда, безнең авыл шаулап торган ка-рурман эчендә утырган вакытта, шушы чишмә урынында бер бик юан йөзьяшәр чыршы үскән булган. Көннәрнең берсендә давыл чыгып, аны төбе-тамыры белән аударып ташлаган. Һәм, ни гаҗәп, чыршы төбендәге чокырдан кара сыер тиресе килеп чыккан! Караклар сыер урлап суйганнар да тиресен шушы чыршы төбенә күмеп куйганнар, имеш.

Шуннан кешеләр, тагын берәр әйбер күммәделәр микән дип, чыршы төбен казый башлаганнар икән, ургылып су чыккан, ди. Менә шуннан соң бу чишмәгә «Кара сыер чишмәсе» дигән исем ябышып калган, имеш.

*1998 елда Башкортстанның Яңавыл районы Байгуҗа авылы музеенда*
*Талиб Килмәтовның 1987 елда язып калдырылган истәлекләреннән*
*Гөлчәчәк Әүхәтова күчереп алга.*

### *16. Каһәрмән чокыры*

Элек безнең тирәләрдә Каһәрмән исемле кеше яшәгән, диләр. Ул атаклы ат карагы булган. «Каһәрмән чокыры» дип ике чокырны атый-

лар. Беренчесендә аны икетуганы кыйнап үтергән. Икенче чокыр – урманда. Монда Каһәрмән үзенең урлаган, талаган мал-мөлкәтен җыеп саклаган, диләр.

*1997 елда Башкортстанның Кушнаренко районы*
*Илек авылында Фәнил Гәрәевтән (1928 елгы)*
*Илдар Хәйруллин язып алган*

### *17. Кизгән сазы*

Бу зур булмаган сазлык үз исемен 1928 елда алган, дип сөйли картлар. Егерменче елларда Югары Карышта Казыйхановлар бандасының «даны» чыккан була. Алар безнең авыл халкына гына түгел, тирә-як авылларга да зур зыян салганнар. Хакый Атзитаров дигән юлбасарның бигрәк тә куркыныч, канэчкеч кеше булуы турында сөйлиләр иде.

1928 елда шушы банда Борай районы Кизгән авылыннан Яңа Урыс авылы ярминкәсенә баручы бер сәүдәгәрне сагалап торып, аны үтерә һәм гәүдәсен шушы сазга ташлап китә. Шуннан бирле бу сазлык «Кизгән» исеме белән аталып йөри.

1930 елларда банда тармар ителә.

*1998 елда Башкортстанның Балтач районы*
*Югары Карыш авылында Асия Хариповадан (1945 елгы)*
*Фәнүзә Садыйкова язып алган*

### *18. Өйкискән тугае*

Байрак-Түбә һәм Кәкребаш[1] авыллары арасында элек куе урман үскән. Шушы урман эчендә бер карак яшеренеп яткан. Ул урманда агач кисеп, йорт салган. Халык шул хәлдән соң бу җирләрне һәм күлне «Өйкискән» дип атаган.

*1998 елда Башкортстанның Туймазы районы*
*Кәкребаш авылында Кашап Шакировтан*
*Гөлчәчәк Әхмәдиева язып алган*

***Фазлетдинов Илдус Камил улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы доценты (Уфа);*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре (Казан)*

[1] *Байрак-Түбә һәм Кәкребаш* – Башкортстанның Туймазы районындагы авыллар.

УДК 398.9

***Г.Ф. Каюмова***

# ҮСЕМЛЕК ОБРАЗЛАРЫ КУЛЛАНЫЛГАН ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК МӘКАЛЬЛӘРЕНДӘ КЫЙММӘТЛӘР ЧАГЫЛЫШЫ

Исследование пословичного фонда разных народов способствует осмыслению их отношений к ценностям. Витальные, нравственные, материальные и социальные ценности являются сущностно значимыми для современного общества, а пословичный фонд помогает определить стереотипы, шаблоны, определяющие роль данных ценностей в картине мира народов. В статье на основе описательного, сравнительного методов, а также метода контекстуального анализа показано, что образы растений в татарских и турецких пословицах олицетворяют такие качества как трудолюбие и лень, социальные отношения, стремление к развитию, красоту и уродство, устойчивость определенных качеств.

**Ключевые слова:** пословицы, тюркские народы, фитонимы, витальные ценности, нравственные ценности, социальные ценности, материальные ценности.

The study of the proverbial fund of different peoples contributes to the understanding of their attitudes towards values. Vital, moral, material and social values are essential for modern society and the proverbial fund helps to define stereotypes, patterns that determine the role of these values in the picture of the world of peoples. Based on descriptive, comparative methods, as well as the method of contextual analysis the article shows that the images of plants in Tatar and Turkish proverbs personify such qualities as diligence and laziness, social relations, the desire for development, beauty and ugliness, the stability of certain qualities.

**Keywords:** proverbs, Turkic peoples, phytonyms, vital values, moral values, social values, material values.

Мәкаль – «хикмәтле сүзгә, йомгакланган тирән фикергә корылган тотрыклы образлы гыйбарә, вакыйга яки ситуацияләргә охшашлык һәм тәңгәллек нигезендә бәя бирүгә хезмәт итә торган фәлсәфи-дидактик хөкем ул. Урынлы кулланылганда, бу хөкем кире кагылгысыз хакыйкать һәм бәхәскә урын калдырмый торган өлге-норма буларак кабул ителә. Чөнки мәкальләр – халыкның күп буыннар тарафыннан сыналган акыл һәм тәҗрибә җимешләре»,– дип яза М. Бакиров [Бакиров, б. 90] Әнә шундый үзенчәлекләргә ия булуы аларның иң еш һәм тәфсилле, төрле яклап фәнни өйрәнелә торган фольклор әсәрләре булуына китерә. Мәкальләрне өйрәнүдә фәндә төрле юнәлешләр актив үстерелә һәм дәвам иттерелә. Халык авыз иҗатының әлеге бай катламын Н. Исәнбәт, Х. Мәхмүтов, М. Бакиров һ.б. галимнәр өйрәнәләр. Нәтиҗәдә аларның жанр хасиятләре, тематик төркемнәре, лингвомәдәни кыйммәтләре һ.б. аспектлар җентекләп өйрәнелә. Соңгы елларда тугандаш һәм тугандаш булмаган халыкларның мәкальләрен чагыштырып өйрәнүдә дә кызыклы фәнни хезмәтләр язылып тора,

шул исәптән татар мәкальләре дә башка халыкларның шул афористик жанрга караган үрнәкләре белән янәшә куеп тикшерелә. Мәсәлән, Г.Р. Мөгътәсимова мәкаләләрендә татар һәм уйгур мәкальләрендәге үсемлек атамаларына күзәтү ясала [Мугтасимова, Туэрсюньтаи, 2016]; А.Р. Әхмәтшина диссертациясендә татар, рус һәм француз мәкальләренә семантик характеристика бирелеп, охшаш һәм аермалы яклар билгеләнә [Ахметшина, 2000]; З.А. Биктаһирова, Г.С. Хаҗиева-Демирбаш татар һәм төрек мәкальләрендә шәхси исемнәрнең вазифаларын ачыклыйлар [Биктагирова, Хазиева-Демирбаш, 2012]. Шулай да татар һәм төрек мәкальләрен чагыштырып өйрәнүдә ачыкланмаган, тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән аспектлар да шактый. Шуларның берсе – мәкальләрдә кыйммәтләр чагылышын тикшерү. Бу – шактый киң, төрле ноктадан өйрәнүне таләп итә торган тема, фактик материалның муллыгы да җитди эзләнүләр сорый. Шуны истә тотып, без теманы бераз таррак – үсемлек атамалары, фитонимнар кергән мәкальләр кысаларында өйрәнүне максат итеп куйдык. Нәкъ шушы үрнәкләргә тукталу очраклы түгел, чөнки паремияләрдә үсемлекләр дөньясы кешелек дөньясы белән тыгыз бәйләнгән, Г.Р. Мөгътәсимова язганча, «үсемлекләрне атау юлы белән, кеше үз дөнья картинасын тудыра» [Мугтасимова, Туэрсюньтаи, 2016]. Бу фикер белән тулысынча килешкән хәлдә, үсемлек дөньясы белән бәйле лексиканың кыйммәтләрне ачыклауда да зур роль уйнавын ассызыклап китү сорала. Без моны татар һәм төрек мәкальләре мисалында күзәтәбез. Чыганак буларак Н. Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» томлыклары [Исәнбәт, 1959; 1963; 1967], «Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре» хезмәте (төзүчеләре Л. Мөхәммәтҗанова, И. Ямалтдинов) [Татар халык мәкальләре..., 2020] һәм Й. Чотуксекен [Çotuksöken, 2004], М. Сарачбашы [Saraçbaşı, Minnetoğlu, 1978], Х. Эрол Йолдыз [Atasozleri ve deyimler…, 2019] хезмәтләрендә тупланган төрек мәкальләре файдаланылды. Фитонимнар, гомумән, үсемлекләр дөньясына караган образлар мәкальләрдә түбәндәге кыйммәтләрне чагылдыруда актив катнаша.

1. Виталь кыйммәтләр. Виталь, ягъни яшәеш, куркынычсызлык, сәламәтлек, иминлек белән бәйле кыйммәтләр яшәешнең нигезен тәшкил итә, дибез. Галимнәр ассызыклавынча, традицион фольклор үсешенең иң борынгы этапларында виталь кыйммәтләр аеруча игътибар үзәгенә алынган [Каминская, б. 53]. Без дә мәкаләдә бу аспектны читләтеп үтмәдек. Татар һәм төрек мәкальләрендә бу яктан охшашлыклар шактый күп. Күп кенә мәкальләрдә хәрәкәтнең тормыш һәм сәламәтлек нигезе булуы аңлашыла. Мәсәлән, *Хәрәкәттә – бәрәкәт* дигән татар мәкаленең төрек телендә дә эквиваленты бар. Төрек мәкальләрендә хәрәкәт, үсешне тормыш-яшәешнең нигезе дип атаганда, су һәм суүсем образлары да ярдәмгә килә. Мәсәлән: *Akan su yosun tutmaz.*

Бу очракта даими агып торган су хәрәкәт, үсеш символы булып тора, мондый суда зарарлы матдәләр, пычрак, суүсемнәр тупланырга өлгерми, дигән фикер белдерелә, ягъни суүсем образы биредә тискәре мәгънәдә килә.

Ризыкны кешенең нигез ихтыяҗы буларак таныйлар, ул – куәт-энергия, яшәү чыганагы да ул. Күп кенә үсемлекләр, аларның тамырлары, җимешләре, бөртекле культуралар да мәкальләрдә виталь кыйммәтләрне чыгылдыруда катнаша. Шунысы кызыклы: алар арасында образлар ягыннан охшаш паремияләр дә очрый. Мәсәлән, татар халкының *Тавык төшенә тары керә* мәкале төрек халкында түбәндәге вариантта чагылыш таба: *Aç tavuk kendini buğday ambarında sanır.* Шулай да кыйммәтләр чагылышы ягыннан бу ике мәкаль аерыла: төрек мәкалендә нәкъ менә бодай образы виталь мәгънәгә ия булып, ач тавыкның яшәү шарты буларак аңлашыла. Татар мәкалендә бу очракта витальлек чагылыш тапмый диярлек, бөртекле культура – тары – хыял, омтылыш, хәтта фетиш мәгънәсенә якын тора. Шул ук вакытта татар мәкальләрендә дә үсемлек атамалары виталь ресурс буларак еш кулланылалар, һәм алар тарихи фактлар – 1921 елгы ачлык, Бөек Ватан сугышы елларындагы кытлык һ.б. белән аңлатыла. Татар халкының бу өлкәдәге фаҗигалы тәҗрибәсе шактый зур булу аның мәкальләрдә дә чагылыш табуына алшарт булып тора. Мисал рәвешендә түбәндәге мәкальләрне атый алабыз: *Ак алабута – ачлык елның бодае; Әтнек барда ач үлмиләр; Ачлык елны – алабута, туклык елны йолкып ута.*

Сирәгрәк булса да, виталь кыйммәтләрне чагылдырган мәкальләрдә артык күп, комсызланып ашауның зыяны хакында да искәртелә. Түбәндәге мәкальгә игътибар итик: *Saman elinse samanlık senin.* Биредә сәламәтлекне саклау печән эскертен саклау метафорасы аша бирелә. Мәкальләрдә еш кына ашау гамәле артында күпкә тирән мәгънә ята. Әйтик, түбәндәге төрек мәкале беренче карашка гына груша, алмаларны ашау серләренә төшендерә, грушаны кабыгыннан чистартып, ә алманы санап кына ашарга кирәклеген искәртә: *Armudu soy ye, elmayı say ye.* Асылда исә биредә һәр эшне уйлап башкару турындагы фикер үткәрелә.

2. Матди кыйммәтләр. Тикшерелгән мәкальләр арасында бу яктан җиләк-җимеш һәм яшелчә атамаларының кулланылышы кызыклы. Татар мәкальләрендә алар еш кына антиномик мөнәсәбәтләрдә кулланылалар, мондый очракларда үзебезнең туфракта үскән җимеш – очсызлык, затсызлык, ә җылы якларда үстерелә торган җимешләр затлылык, дәрәҗә, бай тормыш атрибуты буларак кулланыла. Мәсәлән: *Бераүгә торма кирәк, бераүгә хөрмә кирәк; Җимеш юк җирдә чөгендерне дә әфлисун диләр.* Төркиядә авыл хуҗалыгы алга киткән, һәм биредәге климат төрле-төрле җимешләр үстерергә мөмкинлек бирә, шуңа күрә үсемлекләр бу яктан антиномия хасил итә алмыйлар. Аның каравы җимеш, яшелчәләрнең матди байлык чыганагы буларак кулланылышында күләмне, микъдарны белдерүче сүз төркемнәре, бигрәк тә саннар еш кулланыла. Мондый мәкальләр гадәттә бүләкне зурлыгына карап кабул итүне гаеплиләр, бүләк-күчтәнәчнең кечкенәсенә дә шатлануны хуплыйлар. Мәсәлән: *Yarım elma, gönül alma; Hatır alma bir elma.*

Тормышта матди кыйммәтләр бүленешендә була торган гаделсезлек түбәндәге төрек мәкалендә дә чагылыш таба: *Armudun iyisini*

*ayılar yer,* ягъни турыдан-туры тәрҗемә иткәндә, иң яхшы грушаларны аюлар ашар. Әлеге мәкаль тормышта төрле сәбәпләр аркасында иң яхшы бүләкләрнең, матди кыйммәтләрнең аларга лаек түгел кешеләр кулына керүе хакында сөйли. Әлбәттә, кешелек, җәмгыять моңа каршы торырга тиеш, әмма, борынгылар кисәтүенчә, бу күренешнең тамырын корытып булмый.

Матди кыйммәтләрне символлаштырып килүче образ буларак икмәк, бодай икмәге төрки мәдәниятләрдә еш кулланыла. Түбәндәге төрек мәкалендә исә ул образ-символ булып кына килми, матди һәм күңел, рух байлыкларының каршылыкта торырга тиеш түгеллеген дә ассызыклый: *Buğday ekmeğin yoksa buğday dilin de mi yok?* Биредә кунакчыллык идеясе дә алга чыга: аерым очракларда бодай теленең (татлы, әдәпле, матур тел буларак аңлашыла) бодай икмәген алыштыра алуы ассызыклана.

3. Социаль кыйммәтләр. Мондый мәкальләрдә укытучы һәм укучы, гаилә әгъзалары, гаилә һәм дуслар арасындагы мөнәсәбәтләр, затлы һәм бай гаиләдән чыккан кеше тасвиры, коллективизм идеясе алга чыга. Арада татар һәм төрек мәкальләре арасындагы охшаш вариантлар (образлар охшашлыгы урын алган һәм бары тик төп идея, мәгънә уртаклыгы сакланган очраклар да) шактый булуы ачыкланда. Түбәндәге мәкальгә игътибар итик: *Ağaç ne kadar yüksek olsa da yaprakları yere düşe; Агач нинди генә биек булса да, тамыры җирдә булыр.* Аңлашылганча, ике мәкальдә дә агачның биеклеге социаль баскычның югары катына карата метафорик яңгыраш ала, ә җир метафорасы биеклекнең иллюзия, вакытлыча күренеш булуын ассызыклый, төрек мәкалендә вакытлылык яфраклар коелу метафорик образы аша ассызыклана, ә татар мәкалендә бары биеклеккә, ягъни затлы чыгыш, ата акчасы һәм дәрәҗәсенә ышануның һәлакәт белән янавы да беркадәр чагылыш таба, чөнки бу дәрәҗә, бөеклек җир тормышы, нәсел-нәсәп, ата-бабалар хезмәте белән алшартланган, боларны оныту һәлакәткә илтә.

Социаль кыйммәтләр арасында остаз һәм укучы, өйрәнчек мөнәсәбәтләренә кагылышлы мәкальләр дә очрый. Бу яктан *Hocanın vurduğu yerde gül biter* мәкале кызыклы. Аңлашылганча, бу мәкаль элекке реалияләрне чагылдыра. Татар телендә мондый социаль мөнәсәбәтләр, мәдрәсәгә баласын китергәндә, ата-ананың остазга атап әйтелгән канатлы сүзләрендә күренә: *Ите сезгә, сөягә безгә*. Күренгәнчә, фитоним буларак, роза гөле образы төрек мәкалендә генә урын ала, остаз сугудан кызарган урын гөл сурәте белән чагыштырыла. Мөгаен, мондый образ Төркиядәге һава шартларында роза гөленең иркен үсүе һәм еш очравы белән дә аңлатыла торгандыр. Хәзерге вакытта һәр ике халыкта да балага карата гуманлы мөнәсәбәтләр өстенлек итә.

Социаль мөнәсәбәтләрдә тигезлек мөмкин түгеллеге татар мәкальләрендә дә, төрек мәкальләрендә дә ассызыклана. Бу яктан мәкальләрне берничә төргә аерып карарга мөмкин:

1. Туганлык, гаилә, дуслык һәм башка төрле якын мөнәсәбәтләрнең үзара көйләнешен чагылдырган үрнәкләр. Халык, үз тәҗрибәсенә

таянып, шуңа игътибар итә: кеше иң элек якыннарын кайгырта, башкаларның мәнфәгате, алар белән мөнәсәбәтләрне көйләү икенчел әһәмияткә ия. Бу яктан төрек мәкалендә иң элек ботакның төбенә төшкән груша образы үзенчәлекле: *Armut dalının dibine düşür*. Төрле тип мөнәсәбәтләрнең тотрыклылыгын кешеләрнең холык, максатлары буенча яки башка яктан охшашлык, уртаклыклар булу тәшкил итә. Төрек мәкалендә бу яктан юкә образы кулланылган мәкаль кызыклы: *Ihlamurdan odun olmaz, beslemeden kadın olmaz.* Охшаш мәгънәгә ия татар мәкалендә тирәк образы кулланыла: *Ир белән хатын – куш тирәк: төбе бер дә тамыры бер.* Төрек халкында гаилә кануннары, гаилә әгъзаларының бердәм булу хасиятенә аеруча зур игътибар бирелә. Түбәндәге мәкальдә кеше үзе – агач, ә туганнары, дуслары яфраклар буларак гәүдәләнә: *Ağaç yaprağıla gürler.* Татарларда да охшаш мәкаль бар: *Агач яфрагы, кеше – гаиләсе белән матур.* Шунысы кызык: татар мәкалендә агачның яфраклар белән, ә кешенең кылган эшләре белән бизәлүе дә ассызыклана (*Агачны яфрак, кешене хезмәт бизи*).

2. Социаль иерархиягә нигезләнгән мөнәсәбәтләрне чагылдырган мәкальләр. Төрки халыкларда буйсынып эшләү һәм яшәүгә караганда, җаваплы, дәрәҗәле булу – «баш булу» идеясе алга чыга. Мәсәлән: *Baş ol da, istersen soğan başı ol*.

3. Коллективизм кыйммәтләрен чагылдырган мәкальләр. Кеше өчен тирәлекнең әһәмияте гаять зур, шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре – халык авыз иҗатында да, әдәбиятта да иң киң яктыртылган темаларның берсе. Түбәндәге мәкальгә игътибар итик: *Uzüm üzüme baka baka kararır.* Аңлашылганча, бирелә билгеле бер социаль төркемгә караган кешеләр йөзем тәлгәше белән чагыштырыла. Тәлгәштәге йөземнәрнең бер-бер артлы карала, пешә баруы – коллективта да кешеләрнең бер-берсенә йогынты ясавына ишарә. Татар халык иҗатының афористик жанрларында да охшаш мәгънәгә ия булган үрнәкләр очрый. Мәсәлән: *Иш ишен табар, имән кушын табар.* Бу мәкальләр якыннан аралашу даирәсен тәфсилләп сайлауга этәрә, җаваплы, тырыш кешеләр арасына тартылган очракта, үзең дә шундый булырга омтыласың; җаваплылыкны үз өстенә алырга курыкканнар башкаларны да баткаклыкка этәрә. Шул ук вакытта җавапсыз (ялкау, куркак, тырыш, гадел һ.б.) булган очракта аңлы һәм аңсыз рәвештә кешенең нәкъ шундый тирәлеккә тартылу куркынычы кисәтелә. Коллективизм кыйммәтләре борынгыдан килә, хәзерге вакытта ул Шәрык мәдәниятендә дә өстенлек итә, Көнбатыш мәдәнияте исә индивидуальлекне әһәмиятле кыйммәт буларак таный. Татар мәдәниятендә коллектив, бердәмлек ярдәмендә ирешелгән уңышлар югары бәяләнә, тарихи реалияләр дә (ачлык еллары, сугыш еллары) аларның мөһимлеген, шушы сыйфат, хасиятләр ярдәмендә ил, халыкның исән калуын ачык күрсәтә. Болар, мәсәлән, түбәндәне мәкальдә чагылыш таба: *Калын-юан булса да, ялгыз агач өй булмас; күпме изге булса да, ялгыз егет би булмас*. Ялгыз кешенең мөмкинлекләре чикле булу төрек телендә чәчәк образы аша ассызыклана: *Bir çiçekle*

*yaz olmaz*. Эквивалент татар мәкален дә очратабыз: *Бер карлыгач яз китерми.*

Әхлак – шактый киң, заман үзгәрү белән, үзгәрешләргә дучар була ала торган, шул ук вакытта мәңгелек хасиятләргә дә ия булган үзенчәлекле күренеш. Әхлакый кыйммәтләрнең мәкальләрдә чагылышын тикшергәндә, без әлеге терминны фәлсәфи категория буларак аңлыйбыз һәм аның «иҗтимагый аң формасы, шәхеснең үзкыйммәтен, бәхетле һәм лаеклы тормышка омтылуда һәркемнең тигезлеген раслауга юнәлдерелгән, кешелеклелек идеалларын, тарихның гуманлылык перспективасын чагылдырган иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең бер төре» [Гусейнов, б. 342] булуын күздә тотабыз. Төрки халыкларның мәкальләрендә үсемлекләр дөньясы белән бәйле образлар төрле әхлакый сыйфатлар хакында метафора ярдәмендә сөйләшергә мөмкинлек бирә. Бөртекле культуралар белән бәйле образлар еш кына тырышлык һәм ялкаулыкны, хезмәт сөючәнлекне, үзара ярдәмләшеп яшәүне хуплаган мәкальләрдә очрый. Боларда тырышлык – ялкаулык, яхшылык – начарлык каршылыгы бөртекле культуралар – чүп үләне, очсыз культура – кыйбат культура антиномиясе ярдәмендә күрсәтелә. Бу үзенчәлек һәм татар, һәм төрек мәкальләре мисалында раслана. Мәсәлән: *Ялкауның җиренә бодай чәчсәң, билчән үсә; Arpa eken buğday bıçmez* h.б. Уңганлык сыйфатлары егетләргә дә, кызларга да хас булырга тиеш, дигән фикерне җиткерәләр мәкальләр. Уңган, кул эшенә һәвәс кызлар егет халкында да ихтирам, мәхәббәт яулый, дигәннәр татарлар. Әлеге фикер түбәндәге мәкальдә ассызыклана: *Кызлар туккан киндерә яшь йөрәкне көйдерә*. Гомумән, «татар халкында хезмәт тәрбиясе бирү бик әһәмиятле бурыч дип карала. Бездә *Эш бүре түгел, урманга качмас; Эш җүләрләрне ярата* кебек мәкальләр дә, җылы өйдәге мичкә утырып, урманнан утын китерүне мактый торган экиятләр дә юк. Кечкенәдән үк баланы эшкә өйрәтү милли тәрбиянең үзәген тәшкил итә», – дип яза галим М. Әхмәтҗанов [Әхмәтҗанов, б. 88]. Төрек мәкальләрендә дә шуңа охшаш күренешне күзәтәбез.

Бөртекле культураларның үзара антиномиясе гаделлек, намус турындагы мәкальләрдә дә урын ала. Мәсәлән: *Бодай күрсәтеп, арпа сатма*. Бөртекле культура белән чүп үләне каршылыгы яхшы, намуслы кеше белән явыз, намуссыз кеше арасындагы каршылык буларак аңлашыла. Төрекләрдә киң таралган мондый мәкальне мисал рәвешендә теркәп китик: *Buğdayın yanında acı ot da sulanır*. Җәмгыять инсафлы кешеләр белән бергә намуссыз кешеләргә дә үсү мөмкинлеге бирә, мәкаль шундыйлардан сак булырга чакыра.

Әхлакый кыйммәтләргә кагылышлы мәкальләрдә агач, бигрәк тә җимеш бирә торган агач образы еш урын ала. Ике халык мәкальләрендә дә агачның (гомумән, үсемлекнең) җимеш бирүе – зур кыйммәт, җимешнең башкалар өчен әһәмияте, аның сыйфаты агачның да кыйммәтен билгеләүче күрсәткеч буларак бәяләнә. Җимеш бирмәү – агач, үсемлекнең файдасыз, кирәксезлеген ассызыклаучы сыйфат буларак ачыклана, җимешсез агач һәм файдасыз, кирәксез, ялкау,

һөнәрсез, гомумән, «начар» кеше арасында параллельләр үткәрелә. Мисалларга тукталыйк: *Kavakta nar olmaz, kötülerde ar olmaz; Her ağacın meyvası olmaz; Kavak ağacı gibi ne yemişi var ne gölgesi; Агач җимеше белән, кеше эше белән матур; Яхшы агач яхшы җимеш бирә* һ.б. Охшаш кыйммәтләрне пропагандалауда үлән һәм иген образлары кергән мәкальләр дә катнаша. Мәсәлән: *Кычыткан орлыгы булганчы, бодай орлыгы бул*. Әмма алгарышка ирешү өчен тырышлык кую сорала. Түбәндәге мәкальдә әлеге идея йөзем агачы артыннан багу, аны үстерү күренешен метафорик куллану аша җиткерелә: *Bağa bak üzüm olsun, yemeye yüzün olsun.*

Ике халыкта да роза гөле, чәчәк образы максатка ирешүдә авырлыклардан курыкмаска кирәклеген ассызыкларга ярдәм итүче атрибут буларак кулланыла. Максат сыйфатында матур, әмма холкы «чәнечкеле» кыз белән парлашу; хыялны тормышка ашыру өчен күп вакыт сарыф итү һ.б. күзаллана ала. Мәкальләрне теркәп китик: *Gülü seven, dikenine katlanır; Чәчәк җыйган кеше чәнечкедән курыкмый.* Роза гөле белән бәйле алдагы мәкальдә төрки халыкларда кунакчыллык сыйфатына әһәмият бирү чагылыш таба: *Кунак – хуҗаның гөлчәчәге*. Биредә, беренчедән, хуҗа кешегә куела торган таләпләрне күрергә була: роза гөле яхшы тәрбия, ярату таләп иткән кебек, кунак кешегә дә шундый мөнәсәбәт күрсәтелергә тиеш; икенчедән, кунак кешене гөлчәчәк белән чагыштыру аңа карата куелган таләпләрне дә яңгыратырга ярдәм итә: хуҗа өендә гөлчәчәктәй матур, сокландыргыч, ягъни әдәпле, итагатьле булу сорала.

Шәрык әдәбиятында борынгыдан камил шәхес идеясе алга сөрелә, әмма халык мәкальләрендә идеализм иллюзиясенә бирелүнең куркыныч булуы ассызыклана, чынбарлыкта камил кешеләр, камил хәятләр була алмый. *Арпаның саламы, күмернең төтене була,* дип кисәтә төрек мәкале *(Arpa samanıyla kömür dumanıyla*). Монда ислам дине алга сөргән «шөкер итеп яшәү» идеясе дә чагылыш таба. «Кимчелеге булмаган һичбер әйбер дә юк. Кулланыла торган әйберләрне кимчелекләре белән кабул итәргә кирәк», – дигән аңлатма бирелә сүзлектә [Atasozleri ve deyimler…, б. 216].

Үсемлек образлары кергән мәкальләр мисалында галимнәрнең «табигать белән өзелмәс бәйләнеш, тәрбияви характер, башка халыкларның мәдәниятләре белән элемтәдә тору чагылышы хас» булуын төрки мәдәниятка хас үзенчәлек буларак билгеләүләренең тагын бер кат раслануын да искәртеп китү артык булмас [Такаракова, б. 150].

Йомгак ясап, шуны ассызыклап китү урынлы булыр: татар һәм төрек мәкальләрендә үсемлек образлары (бигрәк тә агач, чәчәк, агачның билгеле бер төре (усак, юкә), җиләк-җимеш (алма, йөзем, груша), бөртекле культуралар (арпа, бодай), яшелчә образлары (суган, шалкан, баклажан)) еш очрый. Әлеге образлар кеше яшәешенә, үзара мөнәсәбәтләргә метафора буларак кулланыла ала (мәсәлән, кеше һәм аның гаиләсе агач һәм аның яфраклары белән тиңләштерелә); кешеләр арасындагы аермалар үсемлекләр арасындагы капма-каршы үзен-

чәлекләр белән тиңләштерелә (җимешле агач – җимешсез агач); омонимия, сүз уйнату максаты белән кулланыла (суган башы – җәмгыятьтә баш булуга омтылу) һ.б. Мондый мәкальләрдә күбрәк коллективизм идеяләре, гаилә һәм туганнар арасындагы бердәмлек социаль кыйммәтләр буларак алга сөрелә; кунакчыллык, хезмәткә мәхәббәт, тырышлык, җәмгыять өчен файдалы кеше булып җитешү идеяләре әхлакый кыйммәтләр чагылышы буларак яңгырый; виталь кыйммәтләрдән хәрәкәт, үсеш идеясе яшәеш шарты буларак чагылыш таба.

**Әдәбият**

*Ахметшина А.Р.* Семантика татарских пословиц: в сравнении с русскими и татарскими пословицами: дис. … канд. филол. наук. Казань, 2000. 151 с.

*Әхмәтҗанов М.Р.* Яманны юлдаш итмә: мәкаләләр, очерклар, эсселар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 223 б.

*Бакиров М. Х.* Мәкальләр һәм әйтемнәр // Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен д-лек. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 89–100.

*Гусейнов А.А.* Мораль // Философский словарь. М.: Республика, 2001. С. 342–343.

*Биктагирова З.А., Хазиева-Демирбаш Г.С.* Личные имена в татарских и турецких пословицах и поговорках // Вопросы современной науки и практики. 2012. № 2 (40). С. 271–274.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: өч томда. 1 т.. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 913 б.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: өч томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 959 б.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: өч томда. 3 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. 1013 б.

*Каминская Е.А.* Культурные смыслы мифов и их отражение в традиционном фольклоре // Вестник Челябинской академии культуры и искусств. 2015. №5 (44). С. 49–55.

*Мугтасимова Г.Р., Туэрсюньтаи А.* Растительный мир в татарских и уйгурских пословицах // Теоретическое и методическое обеспечение современного филологического образования: Материалы Международной заочной научно-практической конференции, посвященной 25-летию кафедры иностранных языков / Отв. ред. Шакирова Р.Д. Набережные Челны: НГПУ, 2016. С. 151–155.

*Такаракова Е.* Тюркская этика: традиция и современность // Этнодиалоги. 2021. № 1. С. 145–150.

Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре / төз.: Л. Мөхәммәтҗанова, И. Ямалтдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. 271 б.

Atasözleri ve deyimler sözlüğü / yayına hazırlayan H. Erol Yıldız. – Konya: Karatay yayınları. 2019. 320 s.

*Çotuksöken Y.* Türkçe Atasözleri ve Deyimler Sözlüğü. İstanbul: Toroslu Kitaplığı, 2004. 376 s.

*Saraçbaşı M.E., Minnetoğlu İ.* Türk Atasözleri Sözlüğü. İstanbul, Yaylacık m., 1978. 305 s.

***Каюмова Гөлүсә Фәрит кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар әдәбияты кафедрасы доценты*

УДК 94(470.41)

*А.М. Гайнетдинов*

# КАЗАН ГУБЕРНАСЫ МАМАДЫШ ӨЯЗЕ ШЕПШЕҢӘР АВЫЛЫ ТАРИХЫННАН (XVII гасырның икенче яртысы – XVIII гасыр)

Статья посвящена истории деревни Шепшенар Кукморского района Республики Татарстан. В ней приводятся история ее возникновения, существующие версии происхождения названия населенного пункта, ее планировка, некоторые статистические данные по численности населения, результаты генетического исследования жителей.

**Ключевые слова:** Шепшенар, Кукморский район, название, население, численность, планировка, гаплогруппы.

The article is devoted to the history of the village of Shepshenar in the Kukmor district of the Republic of Tatarstan. It contains the history of its origin, the existing versions of the origin of the name of the settlement, its layout, some statistical data on the population, the results of a genetic study of the inhabitants.

**Keywords:** Shepshenar, Kukmor district, name, population, number, layout, haplogroups.

Шепшеңәр – Татарстан Республикасы Кукмара районы составындагы сала. Ул Кукмара шәһәреннән 27 километр көньяктарак, Мишә елгасының югары агымы буенда урнашкан. Авыл 1920 елга кадәр Казан губернасы Мамадыш өязе Петропавел волостена кергән. Аннан соң – ТАССРның Мамадыш кантонына, 1930 елдан – Тәкәнеш, 1932 елдан – Кукмара, 1935 елдан – тагын Тәкәнеш, 1963 елдан – Саба, 1965 елдан кабат Кукмара районнары составында торган. Шундый төрле бүленешләр шуның белән аңлатыла ки, Шепшеңәр саласы Кукмара, Саба, Тәкәнеш кебек район үзәкләренә чагыштырмача бер тирә якынлыкта торган, шуңа күрә җитәкче-түрәләр аны төрле елларда төрле районнар составына кертергә мәҗбүр булганнар.

Шепшеңәр атамасының килеп чыгышы хакында ике төрле фараз бар. Беренчесе, иң популяры – әлеге атама русча «щепки» дигән сүздән алынган, имеш. Каяндыр билгесез кешеләр килеп, бу тирәдә өйләр салырга тотынганнар икән. Бурадан йортлар салганда, аның йомычкалары Мишә елгасына төшеп агып киткән. Завод-Нырты авылы урыслары елга буйлап аккан йомычкаларны күреп: «Щепки, щепки», – дигәннәр, янәсе. Шуннан соң саланы «щепки» сүзенә охшатып, Шепшеңәр дип йөртә башлаганнар, ди.

Авылда сакланган риваятьләргә күрә, элек бу тирәләрдә карурман булган. Рус булмаган халыкларны чукындыру сәясәте вакытында берничә татар нәселе вәкилләре шушы урманга качкан.

Кыскача авыл тарихын язып калдырган Һәдия апа Дәүләтшина үзенең дәфтәрендә бу хәлләрне болай тасвирлаган: «Иң беренче итеп Шепшеңәр сүзе каян чыкканын языйм әле. Элек, бик күп еллар элек була инде бу, кара урман була бу урында. Татарларны чукындыру заманасында шушы урман эченә өч нәсел кешеләре яшеренгән була, болар: Бакый, Гобәй, һәм бер чирмеш (бу мөселман динендәге кеше була). Болар өй салганда, йомычкалары Завод-Нырты саласына агып төшә һәм, монда кешеләр булырга тиеш, дип, эзлиләр һәм табалар боларны. Шипке дип сөйли урыслар, менә шуннан татарчалатып Шепшеңәр була. Кеше сөйләве буенча болар».

Икенче фаразга ышанганда, «Шепшеңәр» атамасы «шөпшә» сүзеннән чыккан. Имеш, элек авылда бик күп шөпшәләр булган, ди. Шуңа күрә аны шулай атаганнар, янәсе.

Бу фикерләр бүгенге көндә фәкать фараз булып кала. «Щепки», «шөпшә» сүзләренең лексик яктан зур үзгәреш кичергән булуы шул хакта сөйли. Гадәттә, элгәрләребез авылларга мәгънәле исемнәр куша торган булган.

Безнең фикеребезчә, сала атамасы мари телендәге өч сүздән барлыкка килгән. «Шып» – «тыныч», «ший» – «көмеш», «эңер» – «елга», ягъни мари телендә «Шепшеңәр» атамасы «тыныч, көмеш елга» дигәнне аңлата. Әгәр Татарстандагы башка татар авылларының исемнәрен карасак, аларның күбесенең этимологиясен мари, удмурт яки чуваш телләре белән җиңел бәйләп була. Кукмара районындагы күп кенә елгаларның атамаларын исә нәкъ менә марилар кушкан. Шунысын да әйтергә кирәк: ниндидер конкрет торак пунктка атаманы үз халкы түгел, ә күрше авылларда яшәүчеләр биргән. Чөнки теге яки бу саланы күрсәтергә кирәк булганда, күрше авыл халкы шул торак пунктка үзләре уйлап чыгарып исем биргәннәр. Мәсәлән, салада берәр билгеле кеше яшәсә, аны шул кеше авылы дип йөртә башлаганнар. Мәсәлән, салада Дусай (Дусмөхәммәд) исемле берәр абруйлы кеше яшәгән икән, ул Дусай авылы дип йөртелә башлаган. Уразай (Уразмөхәммәд) исемле кеше яшәсә, Уразай авылы дип кушылган, әгәр дә, мәсәлән, Җанбулат яшәсә – Янбулат пустошь булган. Торак пункт исемнәре шулай ук табигать белән бәйле ниндидер билгеләр буенча да ясалган. Мәсәлән, авыл тирәсендә камыш бик күп үссә, авыл Камышлы булып киткән. Елга исеменнән алынган сала атамалары да байтак. Мәсәлән, Нормабаш – Норма елгасы башы, Сәрдекбаш – Сәрдек елгасы башы һ.б.

Шуңа күрә Шепшеңәр атамасының елга исеменнән (марилар кушкан исем булса да) килеп чыгуы бер дә гаҗәп түгел. Борынгы карталарны карасак, сала яныннан ике елга аккан. Беренчесе, көнчыгыш (Ятмас-Дусай авылы) ягындагысы – Зур Шепшеңәр елгасы, көнбатыш ягындагысы Кече Шепшеңәр елгасы дип аталган. Зур Шепшеңәр елгасы урманнан чыгып, хәзерге Карда бөясенә агып, аннары авыл кырые буйлап, Күкчә саласына таба юл тоткан. Кече Шепшеңәр елгасы (хәзерге Мишә елгасы башы) шулай ук урманнан чыгып, авыл

зиратына таба агып, Зур Шепшеңәр елгасы белән тоташкан. Бу елгалар элек бик тирән булган, хәзер генә алар кечкенә инешләргә әйләнгәннәр. Елгаларның атамаларын элек бу җирләрдә яшәгән чирмешләр (марилар) кушкан. Шепшеңәр саласы барлыкка килгәнче үк инде елгаларның атамалары булган. Авылга бу ике елга арасында нигез салынгач, әлбәттә, тирә-юньдә яшәүче күрше салалар халкы аны елга исеме белән атый башлаган, ягъни «Шепшеңәр елгасы буенда урнашкан авыл» дип, озын итеп түгел, кыскача «Шепшеңәр» дип кенә йөрткән. Шуңа күрә элекке галимнәр үзләренең хезмәтләрендә авылны «при речке Шепшенарка» («Шепшеңәр елгасы буенда») яки «при ключе Шепшенарка» («Шепшеңәр чишмәсе буенда») дип күрсәткәннәр.

Шулай итеп, сала марилар кушкан елга атамасын үзенә алырга мәҗбүр булган, чөнки Шепшеңәр елгасы буенда барлыкка килгән. Тик авылда бер мари да яшәмәгән, барысы да татарлар булган. Бу – борынгы документлар белән расланган факт. Бәлки, кайчандыр бу тирәләрдә марилар яшәгәннәрдер, әмма тора-бара алар бераз төньякка таба – Синәр (Синерь) елгасы буена китеп урнашканнар.

Шепшеңәр тарихын бабабыз Каим Газизов түбәндәгечә сөйли иде: «Авыл тарихларын сөйли торганнар иде. Безнең бабайлар сөйләвенчә, шушы тирәләргә Казан ягыннан килгәннәр дип тә әйтәләр. Агачларны кискәннәр, чәчәргә җир кирәк бит. Элек юан-юан чыршылар үскән монда, аларны кискәннәр. Монысы Чыршы юлы, әнә шуннан калган, хәзер басу инде. Олы юл басуы дибез, анысы Дусай авылына бара торган юл... Насыйр бабай чишмәсе булган. Башта өч кеше генә килеп урнашканнар, гел урман булган. Башта шушы тирәдәге авылларга барганнардыр инде. Арыш, арпа, солы чәчкәннәр күбрәк, бәрәңге утыртканнар, ясмыклар, борчаклар чәчкәннәр. Агач сука белән сукалаганнар, тырма ясаганнар, тырмалаганнар. Агач табаклар бар иде әүвәле» [Рамазанова, б. 108].

«Татар энциклопедиясе»ндә Шепшеңәр саласына XVIII гасыр башында нигез салынган, дип язылган [Татарская энциклопедия, с. 405]. Чынлыкта, авыл инде аңарчы ук нигезләнгән. Шепшеңәргә кагылышлы иң борынгы архив документы 1678 елга карый. Әлеге халык санын алу кенәгәсендә түбәндәге сүзләр язылган: «Деревня по ключу Шапшинар. Двор Ишмаметка Байкеева, у него дети Ищтеречко шти лет, Бегейко трех лет, платит полясака, денег девять алтын, четыре деньги, хлеба осмина ржи, овса тож, четверик ячмени» («Шепшеңәр чишмәсе янындагы авыл. Ишмәмәт Бәйкиев хуҗалыгы, аның уллары Иштирәк – алты яшендә, Бигәй – өч яшендә. Ярты ясак, 9 алтын акча, 4 акча, чирек арыш икмәге, шулай ук солы, чирек арпа түли») [РДБАА. 1209 ф., 1 тасв., 6453 эш., 2 бүлек, 932 кгз]. Димәк, шул елда салада бары тик бер генә хуҗалык булган һәм биредә Ишмәмәт (тулы исеме Ишмөхәммәд) Бәйки улы, аның хатыны (исеме язылмаган), уллары Иштирәк һәм Бигәй яшәгәннәр. Үзләре генә булганга күрә, аларның әле күптән түгел генә килгәннәре аңлашыла.



1678 елгы халык санын алу документы фрагменты (Шепшеңәрдә яшәүче халык турында язылган). *РДБАА. 1209 ф., 1 тасв., 6453 эш., 2 бүлек, 932 кгз.*

Шулай итеп, әлеге документка таянып әйткәндә, Ишмәмәт Бәйки улы – Шепшеңәргә нигез салучы кеше (кызганычка каршы, аның нәсел дәвамчылары калмаган) һәм авыл 1678 елга кадәр барлыкка килгән булып чыга.

Кызганычка каршы, Шепшеңәргә кагылышлы 1710–1711 елгы Ландрат кенәгәсе сакланмаган. 1716 елгы ревизия документында әлеге кенәгәдә булган күпмедер мәгълүмат китерелгән: «Деревни Шапшинар, в ней татара, по переписи 1710 и 1711 годов написано семнатцеть дворов» («Шепшеңәр авылы, анда татарлар, 1710 һәм 1711 елгы халыкның санын исәпкә алу вакытында 17 хуҗалык дип язылган») [РДБАА. 350 ф., 2 тасв., 153 эш., 164б кгз.]. Биредә инде 17 гаилә яшәгән.

Кайбер әби-бабайлар, салага XVI гасырның икенче яртысында, ягъни төбәктә чукындыру сәясәте башлангач, кешеләр, Казан якларыннан качып, бирегә килеп утырган, дип сөйлиләр. Бу фаразны кискен инкяр итеп булмаса да, алай дияргә безнең кулда дәлилләр һәм фактлар җитми.

1716 елгы документка күз салсак, Шепшеңәрдә 8 хуҗалык булып, барлыгы 26 кеше яшәгән. Ир-атлар – 14, хатын-кызлар – 12 кеше. Барысы да татарлар [РДБАА. 350 ф., 2 тасв., 153 эш., 165б кгз.]. 1710–1711 елгы халык санын алудан соң, 7 кеше (5 ир-ат һәм 2 хатын-кыз) вафат булган, бер ир-ат качкан, бер хатын-кыз, кияүгә чыгып, авылдан киткән [РДБАА. 350 ф., 2 тасв., 153 эш., 166б–167 кгз.]. 1712 елда, ясак түли алмау сәбәпле, 9 хуҗалыктан 33 кеше (22 ир-ат һәм 11 хатын-кыз) качып китәргә мәҗбүр булган [РДБАА. 350 ф., 2 тасв., 153 эш., 165б кгз.]. Шул рәвешле, 1716 елда 9 йорт бушап калган. Ул заманнарда ясак күләме зур, чәчүлек җирләре аз булган, чөнки тирә-якта урман үскән, ә агачларны төпләп чәчүлекләр ясау тыелган. Качып китүчеләрнең күбесе ачлыктан үлгән.

1716 елда Шепшеңәрнең старостасы Уразмәт (Уразмөхәммәт) Теләүле улы, сотнигы Бикмәт (Бикмөхәммәд) Килмәк (Килмөхәммәд) улы булган [РДБАА. 350 ф., 2 тасв., 153 эш., 167 кгз.].

XVIII гасыр башында Шепшеңәрдә яшәгән кайбер кешеләрнең исемнәре сәеррәк яңгырый, әлбәттә, әмма аларны документка урыс кешеләре ничек ишеткән – шулай теркәгән. Урыс түрәләре авыл халкыннан «Исемең ничек?» дип сораган вакытта, кайчак кешеләр үзләренең тулы исемнәрен түгел, ә кыскартылган исемнәрен, хәтта кушаматларын атаганнар. Шуңа күрә борынгы архив чыганакларында әллә нинди исемнәрне очратырга мөмкин. Тик шунысы хак: Шепшеңәрдә электән үк татарлар яшәгән, башка милләт кешеләре (мәсәлән, марилар) хакында бернинди мәгълүмат юк.

Шепшеңәр авылына нигез салынганнан соң, халык тыныч-имин яшәргә өметләнсә дә, киресенчә булган. Рус дәүләте мондагы һәр кешене ясаклы крестьяннар рәтенә кертеп, зур ясаклар түләтергә тотынган. Аның күләме гаиләнең зурлыгына, күпме җиргә ия булуына караган, гаиләләр ишле, җирләре күбрәк булган саен, күбрәк түләргә мәҗбүр ителгәннәр. Ясакны акчалата, ашлык белән түләгәннәр. Игенчелек белән шөгыльләнүчеләрнең, җир начар, ташлы булганга, хәлләре мактанырлык булмаган. Ясакны түли алмаучылар, әлбәттә, каты җәзага тартылган. 1712 елда, аны түләргә хәлләре булмаганга, 9 хуҗалыктан 33 кеше (22 ир-ат һәм 11 хатын-кыз) Шепшеңәрдән качып китәргә мәҗбүр булган [РДБАА. 350 ф., 2 тасв., 153 эш., 166–167 кгз.]. Бу – бик зур сан, ярты авыл дигән сүз. Аларның язмышлары мәгълүм түгел, башка ерактагы торак пунктларга килеп кушылганнармы, яңа берәр салага нигез салганнармы, ачлыктан үлеп беткәннәрме – бер Аллаһ кына белә. 1719 елда фәкать ир-атларның санын гына исәпкә алганнар. Ул вакытта хуҗалыкларның саны 11 гә җиткән, аларда барлыгы 20 ир-ат яшәгән. Шепшеңәр халкы артканнан-арта барган һәм 1746 елда анда барлыгы 61 (документта, ни өчендер ике үлгән кешене дә кушып санаганга, 63 дип язылган) ир-ат яшәгән [РДБАА. 350 ф., 2 тасв., 1143 эш., 272б кгз.]. Ләкин 1764 елда аларның саны 39 га калган. Моның сәбәпләре төрле булган. Берничә гаилә 1749 елда хәзерге Оренбург өлкәсенә кергән Каргалы бистәсенә бәхет эзләп күченгән. Мәсәлән, Бимәкәй Ношаев үзенең балалары Хәлил, Амән, Заһир һәм оныклары белән шунда күченеп киткән [РДБАА. 350 ф., 2 тасв., 1205 эш., 19–19б кгз.]. Шулай ук Биктимер Игъмәмәт улы да шунда күченгән [РДБАА. 350 ф., 2 тасв., 1205 эш., 24 кгз.]. Аблай Тәткә улы гаиләсе хәзерге Башкортстан Республикасы Кызыл Кама районы Биктимер авылына күчеп киткән [РДБАА. 350 ф., 2 тасв., 1205 эш., 21б кгз.]. Шепшеңәрдә, нигездә, игенчелек белән шөгыльләнеп көн күргәннәр. Мәгълүм булганча, Казан арты төбәгендә җир аз һәм бик уңдырышсыз булган, ә менә Уфа һәм Оренбург якларында башка җирләрдән күченеп килгән кешеләргә җир биргәннәр, шуңа күрә байтак кеше шунда юл тоткан.

Шулай ук яшь егетләрне һәрдаим рекрутлыкка, ягъни хәрби хезмәткә алганнар, шул сәбәпле дә халык саны кимегән. 1705 елда Россиядә регуляр патша армиясе оешкач, татарларны да хәрби хезмәткә алу гамәлгә кергән. Солдатлар өйләренә олыгайгач кына әйләнеп кайта алганнар, кайберәүләр сугышларда да ятып калган. Әлбәттә, солдат яраланса яки авырса, иртәрәк тә кайта алган. Кануннар нигезендә авыл халкы солдатка китүче егеткә тиешле күләмдә кием, азык-төлек һәм акча җыеп бирергә тиеш булган. Хәзерге көндә дә салада бу традиция сакланып калган: хәрби хезмәткә алынучы егетләр авыл яшьләре белән гармун уйнап, җырлар җырлап, урам әйләнәләр һәм шул вакытта кем күпме булдыра ала – шуның кадәр аларга акча яки башка кирәк-яраклар бирә.

Ревизия кенәгәләрендә түбәндәге санда хуҗалыклар һәм авылда яшәүчеләр теркәлгән:

1710–1711 елларда – 17 хуҗалык.

1716 елда – 26 кеше: 14 ир-ат, 12 хатын-кыз.

1719 елда – 20 ир-ат, хатын-кызларның саны билгесез.

1746 елда – 61 ир-ат, хатын-кызларның саны билгесез.

1764 елда – 78 кеше: 39 ир-ат, 39 хатын-кыз.

Диалектолог Нәҗия Борһанова мәгълүматлары күрсәткәнчә, элекке заманнарда Шепшеңәр халкы Төркәш, Югары Арбаш, Түбән Арбаш, Хәсән, Ямбулат авыллары халкы белән июнь ахырында Арбаш җыенын бәйрәм иткән. Белгәнебезчә, җыеннар Идел буе Болгар дәүләте чорында ук формалашкан һәм төрки халыкларның, аерым төркемнәренең нәсел бәйләнешләрен чагылдырган [Бурганова, с. 21].

Элек авыл хәзерге шикелле зур булмаган. Борынгы карталардан күренгәнчә, XX гасыр башына кадәр Шепшеңәрдә бары тик бер генә урам булган. Аны халык телендә Түбән урам, рәсми рәвештә Мәктәп (Школьная) урамы дип йөртәләр. Башта ул урам хәзерге кибеткә кадәр генә барган. Тора-бара, йортлар салган саен, көньякка таба үсеп, хәзерге Бакыйлар нәселе зиратына кадәр җиткән. Шуңа күрә торак пункт тәмамланган урынга шул яңа зиратны ачканнар. Анда ниндидер Бакый нәселенә караган кешеләрне генә җирләгәннәр. Яңа зират шул нәсел кешеләренең җирләрендә урнашкан булгандыр, мөгаен. Шунысы кызык, авылда беркайчан да Бакый исемле кеше яшәмәгән. Аның кем булуы, кайчан яшәгәнлеге бөтенләй аңлашылмый. Әгәр дә андый кеше биредә яшәсә, ул һичшиксез архив документларында күренер иде. Бәлки, ул кешенең ике исеме булгандыр. Әмма шунысы төгәл: әлеге кеше Үтән нәселенә караган, чөнки нәкъ менә шул нәсел кешеләре анда җирләнгән һәм җирләнә. Бакый нәселе дәвамчылары үзләренең бабаларының Тау ягыннан килгәнлеген сөйлиләр. Тау ягы дип Идел елгасының уңъяк яр буен атыйлар, аңа хәзерге Апас, Кама Тамагы, Кайбыч, Тәтеш районнары, өлешчә Буа һәм Яшел Үзән районнары керә. Ләкин Үтән нәселе соңыннан килгән нәсел түгел, ул башка нәселләр белән бер үк вакытта Шепшеңәрдә төпләнгән, ягъни XVIII гасыр башыннан ук билгеле.

Зират кына авылның зураюын тоткарлап кала алмаган, кешеләр зиратның икенче ягына да йортлар сала башлаганнар һәм шул рәвешле бу урам бик озынайган һәм хәзерге вакыттагы озынлыкка җиткән. Соңыннан урамның һаман озынаюын хуп күрмичә, шул урамга параллель рәвештә тагын бер урам барлыкка килгән. Анысы – халык телендә Югары урам, рәсми исеме – Урман (Лесная) урамы. Тик бу урам тегесе кебек артык үсә алмаган, чөнки Бөек Ватан сугышыннан соң халыкның саны кискен кими башлаган.

ДНК анализы (Y-хромосомалар) мәгълүматлары төрле авыл халкы арасында тыгыз нәсел бәйләнешләре булуын раслый. 2018 елда үткәрелгән ДНК-тикшеренүләр берникадәр нәтиҗә бирде.

Шепшеңәр авылында өч кешедән ДНК-тест алынды. Бу кешеләрнең фамилияләрен атамаска булдык. Гәрчә, төрле нәселләрдән булсалар да, ике кешенең (Битем һәм Дусай нәселләре вәкилләре) ДНКлары тулысынча бер-берсенеке белән туры килде. Димәк, якынча 400 ел элек Битем һәм Дусайның бабалары бер булган. Аларның анализларында 37 маркердан 36 сы туры килде. Аларның гаплогруппасы – G2a (M201). Бу гаплогруппаны «сванокарачаевская» дип йөртәләр, чөнки ул Карачай-Черкас Республикасы территориясеннән чыккан, ягъни Кавказ халыклары өчен хас. Бу гаплогруппа Идел буена 1300–1700 ел элек үтеп кергән һәм ул татарларда да күп очрый, аеруча Казан артында. Мәсәлән, бу гаплогруппа Теләче районының Олы Кибәхуҗа һәм Кече Кибәхуҗа авылларында, Лаеш районы Татар Сараланы саласында яшәүчеләрдә табылды. Алар якынча 800–1000 ел элек бер бабадан туганнар. Бу салаларга инде Казан ханлыгы чорында ук нигез салынган булганга, Шепшеңәр авылына шул яклардан килгән кешеләр төпләнгәннәр, дип фаразлый алабыз.

Шепшеңәрдә алынган өченче кешенең (Үтән нәселе вәкиленеке) гаплогруппасы – I1 (M-253). Бу гаплогруппа, нигездә, Скандинавия өчен хас. Татарлар арасында да ул сирәк очрамый. Бу гаплогруппа кешеләре Идел буенда инде Болгар чорында ук килеп урнашканнар. Нәкъ шундый ук гаплогруппа тагын ике кешедә табылды. Шуларның берсе – Югары Чура авылыннан Никитин фамилияле керәшен татары. 37 маркерның 35 туры килде, димәк, якынча 300–400 ел элек аларның бабалары бер булган. Моны болай аңлатырга мөмкин. Шепшеңәрдә XIX гасыр урталарында ике кеше чукынган. Аларның берсе Оренбург губернасына күчерелгән, ә икенчесе хакында архив материаллары арасында мәгълүмат юк. Димәк, анысы Югары Чура авылына күченгән булып чыга. Гадәттә, чукынган кешеләрне мөселманнар белән яшәтмәгәннәр, чөнки алар кире үз диннәренә кайтырга мөмкин булган, шуңа күрә аларны керәшеннәр яки урыслар яши торган торак пунктларга күчереп утырткannар. Шунысы бар, Үтән нәселе вәкилләре дә, Югары Чурада яшәүче Никитин да үзләренең бабаларының Тау ягыннан килүләре хакында сөйлиләр. Чыгышлары Тау ягыннан булган тагын ике кешедә шул ук нәтиҗәләр чыкты. Димәк, Шепшеңәрдәге бер нәсел шул тирәдән күченеп килгән. Хәзер-

ге Татарстанның Чүпрәле районы Иске Шәйморза авылында яшәүче бер кешедә дә I1 (M-253) гапплогруппасы табылды. 37 маркерның 34 туры килде, димәк, якынча 400–600 ел элек аларның бабалары бер булган. Кыскасы, бу гаплогруппа Скандинавиядән Кырымга, аннан Идел буе болгарларына килгән булып чыга.

Кукмара районы Шепшеңәр саласына XVIII гасырның беренче яртысында гына нигез салынган, дигән караш яшәп килсә дә, архив чыганаклары нигезендә аның инде 1678 елда ук булуы исбатланды. Авылга Ишмәмәт Бәйки улы нигез салган, дип әйтә алабыз, чөнки биредә шул вакытта аның гаиләсе генә яшәгән. Авыл атамасының килеп чыгышы хакында төрле риваятьләр һәм фаразлар бар, тик алар, безнеңчә, дөреслеккә туры килми. Тел ягыннан тикшерсәк, аның марилар кушкан елга атамасыннан алынганлыгы күренә. Бу тирәләрдә элек мари кабиләләре яшәгән, тик бирегә татарлар килеп утыра башлагач, алар төньякка таба – Синәр (Синерь) елгасы буена күченеп киткән. ДНК-тестлар нәтиҗәләренә таянып, биредә яшәүчеләрнең иң ерак бабалары Кавказ һәм Скандинавия якларыннан Болгар җирләренә, ә аннан Казан артына килеп, Шепшеңәр авылына нигез салганнар, дип фаразларга мөмкин. XVIII гасырда Шепшеңәр халкының саны стабиль рәвештә үскән диярлек, тик яшьләрне хәрби хезмәткә алу һәм миграция аркасында бу процесслар бераз тоткарлык белән барган. 1678 елда бер генә хуҗалыктан торган торак пункт үскәннән-үсә барып, хәзерге көндә 100 йортлы матур авылга әверелгән.

**Әдәбият**

*Бурганова Н.Б.* О системе народного праздника джиен у казанских татар // Исследования по исторической диалектологии татарского языка (материалы исследования). Казань, 1982. 154 с.

*Рамазанова Д.* Тарихыбыз телгә килсә // Д. Рамазанова, М. Булатова // Милли-мәдәни мирасыбыз: Кукмара. Казан, 2016. Б. 97–146.

РДБАА. 350 ф., 2 тасв., 153 эш.

РДБАА. 350 ф., 2 тасв., 1143 эш.

РДБАА. 350 ф., 2 тасв., 1205 эш.

РДБАА. 1209 ф., 1 тасв., 6453 эш.

Татарская энциклопедия: в 6 т. / гл. ред. А.М. Мазгаров, отв. ред. Г.С. Сабирзянов. Казань: Институт татарской энциклопедии АН РТ, 2014. Т. 6: У–Я. 720 с., ил., карты.

***Гайнетдинов Айдар Марсил улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 745

***Р.Р. Мусина***

# САКЛАУ ЗОНАСЫ БУЛАРАК РУХИ ТРАДИЦИЯЛӘР (халык сәнгать промыселлары турындагы закон буенча фикер алышуга)

Статья вызвана размышлениями, связанными с «внесением изменений» в закон «О народных художественных промыслах» 1999 года, а по сути, коренным образом изменившими базовые принципы сохранения и развития духовных традиций народов нашей страны. Традиционное искусство, народные художественные промыслы в их специфической форме являются для современного общества заповедной зоной сохранения своей самоидентичности, уникальной областью творчества, не подлежащей тенденциозным реформам.

**Ключевые слова:** традиционное искусство, самоидентичность, народные художественные промыслы, законопроект, дискуссия, термины.

The article is caused by reflections related to the «amendments» to the law «On Folk Artistic Crafts» of 1999 and in fact, radically changed the basic principles for the preservation and development of the spiritual traditions of the peoples of our country. Traditional art, folk crafts in their specific form are for modern society a reserved area for preserving their self-identity, a unique area of creativity that is not subject to tendentious reforms.

**Keywords:** traditional art, self-identity, folk crafts, bill, discussion, terms.

Традицион сәнгать – безнең тормышыбызда уникаль күренеш кенә түгел, ә күптөрле сәнгать системасының үзенчәлекле өлеше дә булып тора. Табигатьнең күмәклеге һәм үсешендәге кучүчәнлек аны үзе янәшәсендәге сәнгать сәнәгатеннән, «фәнни» авторлык сәнгатеннән һәм үзешчән иҗаттан аерып тора. Аңа халыкның менталитетын билгеләүче тарихи тамырлар белән безне бәйләп торган югары рухилык хас. Моңа XX гасыр башында ук төшенеп, дәүләт һәм фән аның үзенчәлеген һәм рухи кыйммәтен саклап калу өчен күп көч куйганнар. Бу – дөнья тәҗрибәсендә халыкны шөгыльләр белән генә тәэмин итү түгел, ә халыкның рухи мәдәнияте ияләре буларак халык сәнгать промыселларына гуманитар әһәмият бирү буенча дәүләт сәясәтенең уникаль үрнәге дә. Халык сәнгать промыселлары (ХСП) – бу безнең тәҗрибә һәм илебез аны уңышлы тәкъдим итте. Кыска гына вакыт эчендә рухи-матди эшчәнлекнең уникаль өлкәсен булдыра алдык, анда матди һәм матди булмаган өлешләр тарихи тамырлар белән үзара тыгыз бәйләнгән, димәк, алар вакыт белән чикләнмәгән. Традицион сәнгатьнең яшәеш һәм үсеш механизмы халыкның ментальлегенә, аның тормыш укладындагы традицион кыйммәтләргә тугрылыгына, җәмгыять үсешенең кучүчәнлегенә хас өстенлекләргә җавап бирә. Һәм бу генетик код кебек эшли, ватандашларыбызны традицион сәнгатькә җәлеп итә, без күргәзмәләрдә һәм эре массакүләм акцияләрдә моңа һәрдаим инанабыз.

Болар барысы да база принциплары рәвешендә 1999 елгы ХСП турындагы Законга салынган иде. Ул совет чорының ахырында фән һәм агымдагы практика өчен күп эшләгән, традицион мәдәниятнең алыштыргысыз рухи һәм сәнгати кыйммәтен тирән аңлаган белгечләр тарафыннан әзерләнде. Законда эшләнгәннәр теркәлгән, аның үзенчәлеге кысаларында тармакның алга таба хәрәкәт итү механизмнары уйлап табылган. Болар барысы да мирасның зур әһәмиятен югалтмаска өндәү буларак кабул ителә.

Килешәбез: вакытлар үзгәрә, яңа шартлар туа. Традицион сәнгать агымдагы процесслар белән бергә эволюция кичерә, яңаны үзләштерә һәм үз системасына кертә. Бу яңарту аның үсеш принципларына салынган. Әмма традицион сәнгатьнең чынбарлыкны кабул итү үзенчәлекләре, үз үсеш ритмы бар, һәм аларны ашыктырырга, бигрәк тә сәнгати процесс барышын үзгәртергә ярамый.

Тәкъдим ителгән яңа проектта традицион сәнгатьнең рухи кыйммәтенә басым ясалмый, ул эшчәнлекнең коммерцияле нәтиҗәсенә күчә. Ә бу исә ХСПның урнашкан яшәү тәртибен боза, аны алга таба җимерүгә юл ача. 1970–1980 елларда илебезгә шактый күләмдә валюта керемнәре китергән, үз эшләнмәләрендә халыкның рухи көчен һәм матурлыгын күрсәткән тармак коммерция аша түгел, ә сәнгать законнары кысаларында үскән. Бу өлкәдә керемнәр икенчел, алар эшләнмәләрнең сәнгати һәм идея кыйммәтләренә бәйле.

Безгә тәкъдим ителгән проект тармакны коммерцияләштерү юлында ХСПның үсеш моделен тәкъдим итә. Шартларны вакыт үзе билгели. Тәкъдим ителгән структураның катлаулылыгы, «халык сәнгать промыселларының үз-үзен җайга салучы оешмалары»ның фактта арадашчы ролендә булуы да үзен акламый. Халык сәнгать промыселларын һәм һөнәрләрен федераль яклау, саклау һәм үстерү фонды (аның 3 органнан торган өскормасы белән), ХСПның иҗади остаханәләре, фәнни-иҗат лабораторияләре рәвешендә кертү промыселлар өчен бөтенләй ят. Алар промыселларның яшәү урынына бәйләнгән һәм локаль сәнгать традицияләре белән характерланган үтә нык үзенчәлекле эшчәнлеген җимерә. Проектның «халык сәнгать промыселлары эшләнмәләренең типовой үрнәкләрен булдыру» белән шөгыльләнергә тиешле лаборатория эшчәнлеге турындагы параграфы бу хакыйкать белән «дус түгел». Промыселлар системасында типовой үрнәкләр юк, һәр производствода үз эшләнмәләре. Шулай ук бу структураларның ни өчен предприятиеләрдән алынуы да аңлашылмый. Һәм хәтта «иҗади остаханә җитештерү процессының яисә халык сәнгать промыселлары оешмалары эшчәнлегенә идарә итү процессының бер өлеше була алмый», дип гадәттән тыш каты әйтелгән. Сүз уңаеннан, лаборатория алайса нигә кирәк? 1980 елларда ХСП предприятиеләренең иҗат структурасы җентекләп эшләнде һәм рекомендация рәвешендә, предприятиенең үсеш дәрәҗәсенә карап, иҗади эшне оештыруның төрле формаларын сайларга мөмкин иде. Кемдер бөтен участоклар белән берьюлы эшләде. Анда иҗат участогы да, иҗат төркеме дә, эксперименталь-иҗади лаборатория дә бар иде. Әмма алар

башкалардан аерым түгел, ә җитештерү эчендә «үз тегермәннәренә» эшләделәр, автоном рәвештә типовой үрнәкләр тудырмыйлар иде. Бу модель күбрәк стандартлаштырылган җитештерүләргә, мәсәлән, сәнгать сәнәгатенә туры килә. Бәлки, бу очракта сүз җитештерүне оештыруның төрле типлары турында барадыр, әмма аларны карап тикшерергә, бигрәк тә ХСП турындагы законга кертергә кирәк түгел, бу – әлеге закон сакларга тиешле күренешнең уникальлеген юкка чыгарачак. Һәм алар да үз эшләре белән шөгыльләнәләр, тик ул вакытта аларның кем өчен булуы билгесез. Локаль принцип буенча үсә торган традицион сәнгатьтә адрессыз типовой үрнәкләр була алмый.

Документта кайбер урыннар (бәлки тулаем тармак төзелеше турында күзаллауның эшләнеп бетмәве аркасында) аңлашылып бетми. Тагын шунысы да аңлаешсыз: ни өчен промысел предприятиесе эшчесе буларак юристны телгә алырга, ул вакытта фабрикага хезмәт күрсәтүчеләрнең барысын да (урам себерүчегә кадәр) санап чыгарга кирәк. Мөгаен махсус документта махсуслаштырылган кадрларны гына күрсәтү сораладыр. Шулай ук осталарның «китапханә фондларыннан түләүсез файдалану» мөмкинлекләре турындагы фраза да сәер яңгырый. Алардан бит бөтен кеше файдалана ала? Ни өчен иҗат остаханәсе Законда «махсус җиһазландырылган бина» буларак карала? Ул болай да шундый булырга тиеш. Ә аның эшчәнлегенең асылы нәрсәдә?

ХСПда иҗади эшчәнлек белән профессионал да, һәвәскәр дә шөгыльләнә ала, дигән фикер төгәл түгел. Һәвәскәр – үзешчән оста һәм ул иҗатның башка өлкәсеннән. «Оста» сүзен куллануда да төгәлсезлекләр бар. ХСП өчен – ул хөрмәтле һөнәрче-профессионал һәм иҗади шәхес. Ни өчен «Халык сәнгать промыселлары остасы статусы вәкаләтле орган билгеләгән тәртиптә бирелә»? Бу дәрәҗәме? Документтан аңлашылмый. Проектта тикшерү предметы белән бик үк ярашмый торган терминнар һәм төгәл булмаган формулировкалар күп. Әйтик, «продукция» сүзен очратабыз. Аны ХСПга карата кулланырга ярамый. Бу – сәнгать сәнәгате өлкәсеннән, биредә «эшләнмәләр» дию дөресрәк була. Тәкъдим ителә торган закон проекты мондый яңа аңлатмалар белән гамәлдәге законга өстәмә түгел, ә яңа документ булып тора.

Чыннан да промыселлар өчен авыр заман килде. Аларга коммерцияле вазгыятькә керергә булышырга кирәк. (Әмма аларның рухи һәм иҗади үзенчәлекләренең специфик сыйфатлары белән билгеләнгән, арадашчы структуралар белән катлауландырылмаган кагыйдәләр буенча гына.) Әлегә кадәр эшләделәр бит, һәм директорлар да кемгә нинди сорау белән мөрәҗәгать итәргә кирәклеген беләләр. Яңа тормышка күчкәндә иҗат эшенә өстенлек бирелергә тиеш, ә бу мәсьәләләр документта эшләнмәгән диярлек. Хәзерге заманда халык сәнгать промыселлары территориясе җитештерүнең һәм иҗатның үзгәреп торучан рәтләре эченә кертелмәсен, ә тыелган зона буларак каралсын иде.

***Мусина Ралия Рифгат кызы,***
*сәнгать фәннәре докторы, профессор,*
*С.Г. Строганов исемендәге Мәскәү дәүләт сәнгать-сәнәгать академиясе*

УДК 792

***А.А. Шәмсутова***

# ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ТАРИХИ-МӘДӘНИ КҮРЕНЕШ БУЛАРАК «ТЕАТРАЛЬ ПРОСТРАНСТВО» КАТЕГОРИЯСЕ

В статье раскрывается понятие «театральное пространство» в татарской драматургии, отраженное в пьесах в XX веке. Автор опирается на новую концепцию в контексте анализа этих пьес. Исходя из этого «театральное пространство» рассматривается как социально-историческое пространство, где реализовываются определенные события истории и жизни человека. Выделено несколько подходов в изучении театрального пространства от начала XX века до современности в татарском театре. Выявлено, что татарские драматурги обращают особое внимание на место театрального пространства в структуре театра и драматического произведения; стремятся показать соотношение театрального и художественного пространств в рамках бытия и истории. Обращение к феномену «театральное пространство» с позиции социалистического реализма и постмодернизма необходимо для того, чтобы понять как татарская драма XX века фокусируется на реальных аспектах истории, жизни, как идет трансформация понятия «театр», «театральное представление» в различные культурно-исторические отрезки времени.

**Ключевые слова**: «театральное пространство», постмодернизм, татарская драматургия, национальная самоидентификация.

This article focuses on the concept of «theatrical space» in Tatar dramaturgy and the category of space, which were reflected in plays in the 20th century. The author relies on a new concept in the context of the analysis of these plays. Proceeding from this, the «theatrical space» was considered as a socio-historical space where certain events in the history and life of a person are realized. Several approaches were also identified in the study of theatrical space from the beginning of the twentieth century till present days in the Tatar theater. We have found that Tatar playwrights pay special attention to the place of theatrical space in the structure of the theater and dramatic work; strive to show the relationship between theatrical and artistic spaces within the framework of existence and history. Appeal to the phenomenon of «theatrical space» from the standpoint of socialist realism and postmodernism is necessary in order to understand how the Tatar drama of the twentieth century focuses on the real aspects of history, life, how the concept of «theater», «theatrical performance» is being transformed into various cultural and historical periods of time.

**Keywords:** «theatrical space», postmodernism, Tatar dramaturgy, national self-identification.

Соңгы егерме елда Россия җирлегендә фәлсәфә өлкәсендә һәм мәдәнияттә «мәдәни пространство» дигән категория үтә актив тикшерелә һәм үстерелә. Моның сәбәбе мәдәниятнең төрле өлкәләренә кызыксыну арту белән бәйле. Тикшеренүчеләр мәдәни пространствоның структур төзелешенә еш мөрәҗәгать итүгә карамастан,

татар театры эчендәге урын категориясе мәдәни феномен буларак фундаменталь тикшеренү объекты булудан читтә кала кебек.

Мәдәниятнең традицион төре буларак, театр мәдәни пространствоның асылын тануның һәм төзүнең төп принципларыннан берсе булган уен категориясенә нигезләнә. Без бүген постмодернистик чорның ахырында яшибез. Постмодернизм фәлсәфәсе исә кеше яшәешенең асылында уен ята, дип билгели [Хейзинги, 1997]. Мәдәниятнең генә түгел, тарихның да уен башлангычына корылуын аңлау бүгенге җәмгыятьтә яшәүчеләргә тормышны танып-белергә ныграк ярдәм итәргә тиеш. Шушы җәһәттән театр, «уеннарның уены» буларак чынбарлыкны тану өчен бер чарага әверелә. Фәлсәфи эзләнүләр яктылыгында тормышның мәгънәви яклары, мәдәни кысаларга утыртылып, билгеле бер мәдәни сценарийлар рәвешен ала. Һәм бу тормыш, ахыр чиктә, шул ук «театраль кануннар нигезендә» алга бара.

Бүген күп кенә галимнәр, яшәеш кануннарын аңлату өчен, театр законнарына таяналар. Монда «театрлаштыру», «театр» бара торган пространствоның үзенчәлекләре, бу театрның тормышка тәэсире – болар барысы да чынбарлыкны тагын да катлауландыра торган билгеле бер өлешләр. Аеруча «уен алымнары», «тамашалар», «рольләрне башкару»га игътибар итү сорала. Бүгенге җәмгыять шул рәвешле шартлылык алымнарына бәйләнгән, тормышны һәм театрны тигезли торган театрга һәм «театраль пространствога» әверелә. Мондый заманда спектакль кебек сәхнә уены образлар аша күрсәтелә торган кешеләр арасындагы иҗтимагый мөнәсәбәтләр рәвешен ала. Постмодернизм кысаларында хәтта фәлсәфә һәм мәдәният үзләре дә «акылның драматик уены» итеп карала башлый, чөнки монда һәрбер фәлсәфи концепция сәхнә уены булган пьеса шәкелендә төзелә. Постмодернистик фәлсәфәдә аның төп ике «уенчысы» булган материя һәм аң драматик каршылыкка керә. Димәк, әле XX гасыр урталарында танылган фикер иясе Х.Ортега-и-Гассет билгеләгәнчә, көнебезнең тормыш җирлеге билгеле бер «архетип», «клише», «штамплар» белән тулы, адәм баласы исә мәдәният һәм җәмгыять тарафыннан оештырылган билгеле рольне генә башкара [Ортега-и-Гассет,1991].

«Яшәеш театры»н аңлату һәм аңлау өчен «театраль пространство»ның теоретик асылын ачыклау сорала. Димәк, без «уен» категориясенә мөнәсәбәттә «театраль пространство» һәм «театр җирлеге» дигән ике урын категориясе белән эш итәргә тиеш булабыз. Бу ике төшенчәне ачыклау җәһәтеннән Г. Гадаммерның «Игра в искусство» хезмәтендәге концепцияләргә таянып фикер йөрттек [Гадаммер, 2006, с. 164–168]. Һәм бу яшәп килгән теоретик карашларны берләштерүне һәм театральләштерү феноменын тамашачыга юнәлтелгән һәм билгеле бер фикерләү калыпларына таянган иҗтимагый-мәдәни мөнәсәбәтләр өлкәсенә кертүне дә сорый.

Әлеге тикшерүнең асылын постмодернизм һәм деконструктивизм кысаларында формалаштырылган «пространство-җирлек парадигмасы» тәшкил итә. Шул сәбәпле, мәкаләнең методологик нигезен пост-

модернистик фәлсәфәне яктырткан һәм әдәби текстны символлар, тамгалар системасы буларак өйрәнә торган структур анализга корылган заманча мәдәни-фәлсәфи концепцияләр тәшкил итә. Алар XX гасыр урталарында Р. Барт [Барт, 1994], Ж. Бодрийяр [2006], Ж-Ф. Лиотар [1998], Х. Оргета-и-Гассет [1991], М. Фуко [2004], М. Хайдерггер [1993], Й. Хейзинга [1997] кебек чит ил галимнәренең хезмәтләрендә яктыртылган иде.

Кеше эшчәнлегенең чикләрен билгеләү өчен «мәдәни пространство» дигән төшенчә кулланыла. «Мәдәни пространство» үз эченә география, геополитика, этнография, социология, филология һәм тарих кебек белемнәрне туплый. Монда без ике төп күренешкә тукталырга тиешбез.

1. Геомәдәни күренеш – мәдәниятнең бер дәүләт чикләрендә таралуы.

2. Онтологик күренеш – мәдәниятнең кешеләр һәм җәмгыятьнең аңын формалаштыручы, милли мәдәниятнең асылын билгеләүче булуын аңлау. Бу карашларны без Ю. Лотман [Лотман, 2002], В .Тюпа [Тюпа, 2001; 2002], В. Топоров [Топоров, 1995] кебек галимнәрнең хезмәтләрендә күрәбез. «Театраль пространство» төшенчәсен мәдәният җирлегендә теоретик өйрәнү «уен концепциясе»н формалаштырган И. Хейзинга [1997], Х.Ортега-и-Гассет [1991] хезмәтләрендә тирән аңлатыла.

Куелган максатка ирешү өчен, киңкырлы мәдәни яссылыкта эш иттек. Әдәбият белеме өчен традицион саналган анализ төрләренә – әдәби-теоретик, мәдәни-тарихи, герменевтик, интертекстуаль, структур-семантик рецептив, чагыштырма-компоративистик методларга, шулай ук яңа нарратив анализ, дискурс-анализга да мөрәҗәгать ителде.

«Тормыш — ул театр», бер әсәр җирлегендә төрле фәлсәфи фикерләрнең кисешүе (интертекстуальлек), Җир тормышын һәм адәм баласының үзен төрле катламнарга аерып карау кебек концепцияләр, уен, коллаж, реминисценция, аллюзия кебек алымнар XX гасыр урталарында Европада постмодернизм теоретиклары тарафыннан фәнни җирлектә өйрәнелә башласа да, Көнчыгыш, шул исәптән татар һәм төрек әдәбиятларында, алар борынгы чорлардан ук сурәт тудыруның үзәк катламнарын тәшкил иткәннәр. Чөнки сәнгать әсәрләрендә үзенчәлекле гәүдәләнеш тапкан Шәрык менталитетының нигезендә яталар. Мәкаләдә исемнәре атап үтелгән язучылар исә бу концепцияләрне, алымнарны бүгенге татар театры һәм драматургиясе җирлегендә яңача үстерәләр, кулланалар. Шул рәвешле, сүз сәнгате кысаларында Шәрык һәм Гареб синтезын формалаштыралар, яңача дәвам итәләр [Шәмсутова, 2002, б. 45–49].

Күргәнебезчә, яшәешнең уен кебек бер күренешенә нигезләнеп, театр билгеле бер пространство кысаларында гамәл кыла [Возгравцева, 2005, с. 59]. Моның дәлилләрен без XX гасыр башында татар мохитендә театр һәм беренче спектакльләр барлыкка килгән чордан күзәтә алабыз.

Платон һәм Аристотель кебек фикер ияләре безнең эрага кадәр үк театрны үзенчәлекле эшчәнлек төре буларак таныйлар [Ахундов, 1982, с. 3, 45]. Театр эшчәнлеген төрле яклап өйрәнү театраль коммуникациянең чикләрен билгеләргә ярдәм итә. Әйтик, Г. Колахмәтов, Г. Камал, Г. Исхакый театрны тамашачыга (халыкка) иҗтимагый йогынты ясаучы бер чара һәм «мәйдан» (пространство) буларак кабул итәләр. Бу фикер дә Россиядә беренче тапкыр театр дигән күренеш барлыкка килү белән бәйле. Моны XVIII гасырда Пётр I алга сөрә [Шамсутова, 2020, с. 280–283]. Соңыннан В. Белинский, А. Луначарский, Д. Лихачев хезмәтләрендә тамашачыга тәрбияви йогынты хакында нигезле фикерләр әйтелә [Волькенштейн, 1929, с. 229–232].

XX гасыр башында К. Станиславский, Н. Немирович-Данченко кебек танылган, көчле режиссерлар театраль пространство төшенчәсен бары тик театр эчендә генә карап була, дигән фикерне яклап чыгалар. Әлеге режиссерлар карашы буенча, «театраль пространство» – ул «сәхнә пространствосы» [Станиславский, 1999, с. 25]. В. Мейерхольд, Н. Евреинов, Е. Вахтангов «уен» һәм «чынбарлык» арасында чикләрне билгеләделәр, театрны «иллюзор вакыйгалар дөньясы» дип кабул итеп, аны реаль яшәеш һәм чынбарлыктан аерып куйдылар [Мейерхольд, 2001, с. 17]. Мәсәлән, К. Станиславский карашынча, «театраль пространство» – ул актёрлар белән тамашачылар бәйләнешеннән гыйбарәт булган, бары тик режиссер эшчәнлеге нәтиҗәсендә генә туа торган пространство» [Станиславский, 1999, с. 25]. Бүгенге татар театрларында театраль пространствоны сәхнә һәм тамашачының көчле багланышы чарасы итеп караган мондый концепция танылган режиссер Марсель Сәлимҗановтан башлана һәм хәзер дә дәвам итә.

Ә менә К. Станиславский идеяләре белән рухланып формалашкан Европа театрлары режиссерлары Б. Брехт, А. Арто [Artound, 2009, s. 12–18], Ги Дебора театрны реаль чынбарлыкның иллюзор чагылышы буларак үстерәләр [Keskin, 2008, s. 32–33]. Тора-бара бу караш театрны өйрәнүдә Ф. де Соссюр, К. Леви-Строс, Ч. Моррис теорияләре тарафыннан семиотик башлангычлар белән тирәнәйтелә [Ахундов, 1982, с. 43–44] һәм Р. Барт, В. Топоров, Ю. Лотман һ.б. хезмәтләрендә театр тамгалар, тарихи-мәдәни кодлар ярдәмендә тамашачыга тәэсир итәргә тиеш, дигән фикерләр җиткерелә. Монда инде «театр мәйданы» (театраль пространство) театрның бер берәмлеге, бер категориясе буларак кабул ителә башлый [Цимбал, 1977, с. 94–95].

Күргәнебезчә, театр, онтологик бер күренеш буларак, сәнгать кысаларында гына кала алмый, аннан читкә чыга. Чөнки театр бер үк вакытта ике – физик һәм виртуаль (сәнгати) яссылыкларда карала. Сәнгать әсәрләрендә тудырылган һәм урын алган «пространство» (урын) реаль чынбарлыкка тәңгәл түгел, бу чынбарлыкның аерым элементлары-өлешләре булган сәнгать әсәрләренә дә хас түгел. Ул бу сәнгать әсәрләре эчендә тудырыла торган образлы модельләр өчен характерлы. Театраль пространствоның образлылыгы – аның таралуының төп сәбәпләреннән берсе. Театрда сәнгать дөньясы реаль вакыт

кысаларында һәм реаль кешеләр ярдәмендә тудырыла. Бу кешеләр (актёрлар) үзләре тудырган персонаж-геройларның иллюзор образлар булуын белеп уйныйлар. Театраль пространствода үзләре театр сәнгате максатына хезмәт итә торып та, аның образлар дөньясында күренми торган структуралар бар. Болар – архитектура өлеше, музыка яссылыгы, рәсемнәр, сәнгать яссылыгы, әдәби яссылык, эстетик катлам, дини-идеологик катлам, тормыш катламы, иҗтимагый яссылык, шәһәр пространствосы. Алар – театрның аерылгысыз өлешләре, чөнки нәкъ менә шулар театраль пространствоны мәдәният яшәеше мәйданында тотып торалар. Шулар ярдәмендә театраль пространство мәдәни дөньяның мөстәкыйль бер төре буларак чыгыш ясый [Keskin, 2008, s. 45–48].

Театраль пространство –дөньяны драматик вакыйгалар ярдәмендә сәнгати танып белү ул. Аның төп сыйфатлары итеп без семиотик пландагы тулылыкны, кешелек кыйммәтләренең үзенчәлекле булуын, шәхеснең формалашуын күрсәтүне, виртуальлелеген, диалогларга корылган булуын атый алабыз. Театраль уен һәрвакытта да драматик яссылыктан, сәхнә мәйданыннан, сценографиядән, уен яссылыгыннан, текст өлешеннән һәм эчке пространстводан формалаша.

Һәр театрны театраль пространство яшәтә, ягъни театраль пространство көчле булмаса, тамашачыга тәэсир итү көче дә түбән була. Димәк, театраль пространствоның үз функцияләре бар. Беренчесе, – эчке диалог-мөнәсәбәтләр, алар театр мәйданында бара, театрның үзенчәлеген билгели. Икенчесе – тышкы як, иҗтимагый тормышта театраль пространствоның урынына, театрның яшәү рәвешенә бәйле. Бу ике функциянең эшчәнлеге театраль вакыйгаларны мәдәният һәм җәмгыять-тарих сәхнәсенә алып чыга. Театр, уен, театраль вакыйгаларның яшәү шәкеле менә шуннан гыйбарәт.

Театраль пространствога татар театр сәнгатендә чагылыш тапкан төрле карашлар мисалында тулырак тукталасы килә. XX гасыр башында татар драматурглары һәм режиссерлары театраль пространствоны иҗтимагый аңны үзгәртүнең бер чарасы-алымы итеп кабул иткәннәр. Моның матур мисалын без драматург Гафур Колахмәтов иҗатында күрәбез. «Театраль пространство» тудыру җәһәтеннән аның «Ике фикер» пьесасы игътибарга лаек. Нәкъ менә әлеге әсәрдә автор тарихи вакыйгалар тезмәсенең билгеле бер сценарий рәвешендә килүен, адәм баласының да бу «тарихи уенда» «актёр» гына булуын ассызыклый. Бу фикерләр драматург тарафыннан риторик эндәш һәм әдәби алымнар ярдәмендә башкарыла. Г. Колахмәтов та драматургия һәм театрны, Ф. Шиллер концепциясендәге кебек, «кешелек дөньясының остазы» дип карарга чакыра: «*Адәм нихәтле нык табигатьле булса да, нихәтле аның гыйлеме зур, фикере киң булса да, тарихны тудыра алмый, бәлки адәмнең үзен тарих тудыра. Нәрсә ул – тарих? Тарих – гәвамның ничә мең еллар эчендә кылә торган сыйныфлар көрәшенең тезмәсе; тарих – сыйныфлар көрәшенең көзгесе*» [Колахмәтов, с. 44]. Димәк, тарих – билгеле бер чор вакыйгалары чагылыш тапкан «театраль пространство», көзге. Драматург бу төшенчәне җитди ка-

бул итәргә чакыра, чөнки моны аңлау – адәм баласының тормыштагы урынын, тормышның мәгънәсен дөрес аңларга ярдәм итәчәк.

«Ике фикер» – «реаль чынбарлык» һәм «иллюзор дөнья» турындагы карашлар дискуссиясен яктырткан драма-дискуссия [Шарипова, Шамсутова, 2021, с. 91–95]. Тарихны билгеле бер сценарий буенча бара торган вакыйгалар агышыннан гыйбарәт «театраль пространство» дип тәкъдим иткән драматург бу әсәрдә «җиңү» һәм «җиңелү» кебек драматик антиномияне бәрелештерә. Нәтиҗәдә, ХХ гасыр башында барган вакыйгалар тарих битләрендә уйналынган билгеле «уен пространствосы» икәнен күрәбез. Бу әсәрдә дә драматург «сугыш» һәм «тормыш» символикасына корылган Кызыл фикер һәм Кара фикер образларының диалогында «театраль пространство» асылын яктырта торган Хакыйкать семантикасын ача, аны укучы-тамашачыга сәхнә кануннары нигезендә җиткерә.

Тормышның «театраль пространство»дан гыйбарәт булуын Гаяз Исхакыйның «Зөләйха», Фәтхи Бурнашның «Таһир – Зөһрә» трагедияләрендә тагын да ачыграк күрәбез. Бу әсәрләрдә чынбарлык чагылдырыла, шул рәвешле тамашачының тормышка карашын, яшәү позициясен формалаштыру көтелә.

Совет чорында язылган татар драма әсәрләре, нигездә, сәхнәдә күрсәтелгән «үрнәк» «театраль пространство»ны тормышта да чагылдыру максатын куялар. Мәсәлән, Галимҗан Ибраһимовның «Яңа кешеләр» (1920) пьесасында кызыл командир Батырхан белән бай кызы Зәйния арасындагы ялкынлы сөю революция һәм шәхси тормыш дигән яссылыкларны антиномия рәвешендә бәрелештерә. Әмма соңында, Г.Ибраһимов, талантлы язучы буларак, бу ике яссылыкның бер-берсенә каршы торырга тиеш түгеллеген күрсәтә [Ибраһимов, 1975, б. 445]. Бу мисалда без сәхнә ярдәмендә иҗтимагый аң формалаштырылуын билгели алабыз.

Тормышның «театраль пространство» икәнен без танылган татар драматургы, режиссеры Кәрим Тинчурин иҗатында ачык күрәбез. Драматурның «Сакла, шартламасын!» (1918), «Американ» (1923) комедияләрендә тормышта барган реаль вакыйгалар, театр әсәре төзелешенә кертелеп, әсәрләрне реалистик эчтәлек белән тулыландыралар. Нәтиҗәдә, алар 1917 елгы Октябрь вакыйгаларыннан соң илдә формалашып килә торган «яңа чынбарлык»ның сыйфатларын, хасиятләрен тамашачы аңында беркетергә һәм шул ук вакытта «яңа чынбарлык»ны төзергә дә ярдәм итәләр.

Театраль простанствоның семиотик мәгънәдә яктыртылышы һәм тарихның шәхес фаҗигасына сәбәп булуы белән без драматург Ризван Хәмиднең «Ак тамырлар иле» һәм «Олы юлның тузаны» әсәрләрендә танышабыз. Гомумән, Р. Хәмид –«театраль пространство», жанр, конфликт киселеше җәһәтеннән татар драматургиясенең иң көчле авторларыннан берсе. Аның санап үтелгән әсәрләрендә иҗтимагый яссылык белән шәхес иреге кебек төшенчәләр тарих театры мәйданында ачыла. Тышкы вакыйгаларны драматург хәрәкәтчән

итеп, динамик рәвештә тасвирлый. Боларның исә ни рәвешле шәхес фаҗигасы формалашуга, үстерелүгә китерүе күрсәтелә. Монда инде «театраль яссылык» сәясәтне, идеологияне, иҗтимагый, мифологик, шәхес азатлыгы, милләт яссылыкларын, тормыш, табигатьне, шәһәр пространствосын берләштерә.

Р. Хәмид геройларының үзбилгеләнеше кризисның яшерен структураларын ачыклый. Иң мөһиме – яшәешнең мәгънәсен югалту. Шуңа күрә геройлар үз көнкүрешләрен аңлап бетермиләр. Аңлау исә – Р. Хәмид өчен үз халкы, аның мәдәнияте, тарихы өчен җаваплылыкны белдерә [Шарипова, Шамсутова, 2021, б. 202–205]. Моны без әсәрдәге Гарри мисалында ачык күрәбез. Талау, алкоголь һәм көчләү аша тормышка мөнәсәбәтен белдерүче Гарри яңа туган баласын да дуңгыз астына имәргә сала. Бу – яшәеш фаҗигасының кульминациясе. «Театраль пространстово» монда социалистик төзелештән капиталистик формациягә күчү нәтиҗәсендә, балаларга тиешле тәрбия бирү мөмкинлеге булмауны һәм «Гарри»ларның елдан-ел артуын чагылдыра, аның фаҗигасын ача. Театраль җәмгыятькә мөнәсәбәтен белдереп, Р. Хәмид мондый фикер җиткерә: «*Т ә ң р е. Ә бит кешене юлга чыгарып җибәргәндә юнәлешне күрсәтәләр»* [Хәмид, 2000: 150].

«Каен җиле»ндә татар җәмгыяте «планлы уен»га корылган театр буларак тасвирлана («Уен» категориясе И. Ильин, И. Скоропанова, хезмәтләрендә тирән аңлатыла) [Ильин, 1998; Скоропанова, 2001]. Постмодернистик парадигмага эләккән шәхестән берни дә калмый: ул үз йөзен генә түгел, хәтта үзен дә югалтуга дучар ителә: бәндәләр өчен Яшәү һәм Үлем арасында аерма калмый; үлем дә яшәү өчен бара торган уен-көрәшнең бер формасы буларак кына кабул ителә.

1980 еллардан соң язылган драма әсәрләрендә тарих һәм тормыш вакыйгалары «нарратив»ка (эпизодик текстка) гына әйләнеп кала. Мондый төр әсәрләрдә «тарих» дигән күренештән акыл белән уйлау-нәтиҗә ясау катламы махсус рәвештә алып ташлана, аның урынына инстинктлар өстенлеге, либидо, коллектив аңсызлык катламы килеп керү актыртыла.

Бу җәһәттән, Зөлфәт Хәким пьесалары игътибарга лаек. Драматург бөтен кешене бер системага кертергә теләү җәмгыятьтә канәгатьсезлек, каршылыклар, хаос тудыра дип ассызыклый. Шул сәбәпле, ул үз әсәрләрендә аңлы рәвештә тормышны хаос итеп чагылдыра, үз укучысын «вакыйгалар каршылыгында» сакланып калырга һәм яшәргә өйрәтә. Әмма бу аның геройларының берьяклы гына яшәвенә, аңсызлык өлкәсенә нигезләнгән инстинктларга гына таянуына китерә.

З. Хәким бүгенге чор татар драматургиясендә әле 1990 елларда ук постмодернистик стилистиканы яратып кулланган авторларның берсе булды. Ул күбрәк ирония, пародия алымнары белән эш итәргә ярата. Пародияне тудыруда авторга «уен» категориясе ярдәмгә килә. Шуның нәтиҗәсендә, З. Хәкимнең «Су төбендә сөйгәнем», «Кишер басуы» әсәрләрендә тормыш, дөнья, кешеләрнең үзара мөнәсәбәте «театр» итеп сурәтләнә [Шәмсутова, 2002, б. 45–49].

Әлеге ике әсәр дә – Совет чорына, җәмгыятенә, аның кешеләренә пародия. Әсәрләрдәге пародияне берничә төргә аерып карарга була. Беренчедән, совет җәмгыятендәге хокук саклау органнарына пародия. Моны без милиционер Миңлебаев образында күрәбез. Гәрчә, ул, ягъни милиционер, авыл кешесенең мәнфәгатьләрен, хокукларын якларга тиеш булса да, чынында, киресенчә, халыкны куркытып торучы, төрмә белән янаучы затка әверелә. Икенчедән, әсәрдәге Халисә мисалында язучы эмансипацияләнгән татар хатынына пародия тудыра. Совет власте, хатын-кызны азат иттек дип, аның хокукларын ир-атныкы белән тигезләдек дип, гүзәл затларга резин итек, фуфайка кидереп, аларны дуңгыз, сыер фермаларына «урнаштырды». Авылда Мәрданша, Гаделшалар каршында хәзер әнә шул иске фуфайкалы һәм резин итекле хатыннар тора. Бу – гади көлү генә түгел, ә яшь аралаш көлү тудыра. Өченчесе – ир-атның хатын-кыз турындагы идеалына пародия. Монысы алдагысы белән бәйләнгән һәм без аны Мәрданша образында яхшы күрәбез.

Тормышта һәркем ниндидер роль уйный; алай гына да түгел, без төрле ситуациядә үзебезне төрлечә тотабыз, төрле рольләргә кереп бетәбез. «Уен» алымын куллану ягыннан бу әсәрдә Миңлебаев образы отышлы. Автор аның белән рәхәтләнеп «уйный». «Уен» алымын куллану ул әле геройларның башкарган рольләрен сурәтләү генә түгел. Монда төп «идарәче» – драматург, автор. Геройларны теге яки бу көлкеле, фаҗигалы ситуацияләргә куеп, ул, беренче чиратта, үзе «уйный». З. Хәким очрагында бу – драматургның, үз-үзенә юнәлтелгән, ягъни үзе тудырган дөньяны, процессны күзәтүдән туган канәгатьләнү рәвешендәге уен [Шамсутова, 2003, с. 17–21] .

«Су анасы» татар укучысы өчен гади образ яки гади сүзтезмә генә түгел: безнең хәтердә Г. Тукай, аның шул исемдәге әкият-поэмасы яңара. З. Хәким исә әсәр тукымасына мифик образ кертеп кенә калмаган, ә Г. Тукай әсәреннән бер сюжет сызыгын да тартып китергән. Мәрданша, «Су анасы»н үзенә карату өчен, Тукай әкиятендәгечә эшләргә тели: имеш, ул алтын таракны урлый, төнлә Су анасы аның артыннан авылга килә; аның килүен этләрнең өрүе хәбәр итә; Су анасы тәрәзәгә чиртә. Бу момент классик әсәрдән алынган «цитата» буларак кабул ителә.

Беренче карашка, реаль чынбарлыкны сурәтләүгә нигезләнгән әсәргә «Су анасы» образы килеп керү үзе үк әсәрнең уенга корылуын күрсәтә. Язучы бу очракта янә бер алым – коллажны куллана. Коллаж фотографиядә, кинофилмьнарда еш очрый. Ул бер әйбернең өстенә икенчесен ябыштыруны аңлата. Әлеге алым әсәрдә пародияне, уен атмосферасын көчәйтүгә хезмәт итә. Димәк, кеше аңына тәэсир итү юлларын эзләү барышында язучы З. Хәким, укучыны үзе сурәтләгән вакыйгалар агышына тарту өчен, әсәр тукымасына уен алымын кертүне отышлы дип саный. Әдәбиятта исә уен категогиясе пародия тудыруга гына хезмәт итми. З. Хәкимнең пародия алымын куллануының максаты да – совет чынбарлыгында тәрбияләнгән татар кешесе тормышының абсурдлыгын, алар башкарган гамәлләрнең мәгънәсез,

буш, көлке булуын күрсәтү. Бу яктан аның әсәрләре рус, Көнбатыш әдәбиятларындагы «абсурдлык театры» концепциясенә корылган әсәрләргә якын тора. Әсәр текстына абсурд элементның кертелүе бүгенге чынбарлыкның тотрыклы булмавын күрсәтү бурычына хезмәт итә. Милли тарихның, милли тормышның сәнгати эчтәлеген шул рәвешле аңлау язучыга аларга каһкаһәләп көлеп якын килүгә этәрә [Шамсутова, Программа, 2003, с. 24–25]. Татарның дөньяны кабул итүе социалистик дискурс кысаларында формалашуын З. Хәким «гиперперсонаж маскасы» аша ачарга омтылыш ясый. Моның аша автор каһарманнарны һәм укучыны да Хакыйкатьнең күптөрле булуы идеясенә инандырырга тели. Язучы фикеренчә, бары тик шуны таныган кешеләр генә исән кала ала. Шуңа да ул төрекләрнең котылу идеясе бер линиягә нигезләнгән «логос»та (сүздә) түгел, ә хаоста икәненә басым ясый. Җәмгыятенең асылында ята торган хаос – адәм баласын коткара ала. Кешеләр шушы хаоска күнегергә, анда яшәргә өйрәнергә, хәтта «хаосны тудыручының уены»на катылып-кушылып, үзләре дә шунда төп роль уйнарга өйрәнергә тиеш. Бары шул вакытта гына күпкырлы Хакыйкатьне танырга була, дигән фикерне ассызыклый З. Хәким. Шул рәвешле, язучы төрекләрнең менталитетын, асылын, аларның «күп катламлы» булуын ача, бу кешеләрнең акылында, фикерендә нәрсә булуын беркайчан да белеп бетереп булмаячагын билгели. Мондый төр кешеләр белән яшәү өчен, аларның үзләре кебек үк «актёр», «уенчы» булырга өнди, хәтта шушы уен-театрның тудыручысы булырга кирәк, дигән фикерне җиткерә.

Р. Хәмид, З. Хәким әсәрләрен укыганда укучы геройның, үзенең дә вакыйгалар, дөресрәге, хәят, яшәеш капканы эчендә калуын сизә. Әмма драматурглар чыгу юлын да күрсәтәләр: ул, без реализм кануннарында өйрәнгәнчә эзлекле түгел, ә көтелмәгәнчә, очраклы пәйда булырга мөмкин; ул хәтта параллель чынбарлыкларга «сикерү» аша була ала.

«Тормыш – ул театр» концепциясенә нигезләнгән «театраль пространство» хакындагы фикерләребезне йомгаклап, түбәндәге нәтиҗәләрне җиткерәсе килә.

«Театраль пространство» татар драматургиясендә төрле чорларда эчтәлек дәрәҗәсендә, хикәяләү рәвешендә чагыла, соңрак постмодернизм өчен хас булган күптөрле алымнар һәм мотивлар ярдәмендә ачыла. Милли архетипларның төрлелеге, драматургларның дөньяга, яшәешкә карашларның үзгәлеге әсәрләрдә кулланыла торган театральләштерү алымнарының да төрлелегенә китерә.

Төрле чор драма әсәрләрендә драматурглар сюжет сайлауда, тарихи, мәдәни вакыйгаларны торгызуда милли мәдәни-тарихи дискурслар кысаларыннан читкә чыкмыйлар. Шуңа да һәр чор сәхнә әсәрләрендә «театраль пространство»ның аерым, көчле, матур үз йөзе, үз милли варианты формалаша. Мәкаләдә без карап үткән драматурглар иҗаты һәм аларның әсәрләре төрле мәдәни парадигма кысаларына сыя торган үзенчәлекле өйрәнү алымнарын куллануны таләп итә. Хезмәттә кулланылган яңа фәлсәфи терминнар үзләренең отышлы булуын дәлилләде.

Татар драматургларының тарихи чор кысаларында «театраль пространство» тудыруга мөрәҗәгать итүләре, ягъни әсәрләрендә реаль-ирреаль дөнья моделен торгызулары берничә яклы, берничә планда бара. Әсәрләрнең барысында да интригалы сюжет кору, иллюзор образлар тудыру, мифологик образларны «терелтү», кертеп җибәрү, архаик универсалияләр төп көч булып тора.

Г. Колахмәтов, Г. Исхакый, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, Р. Хәмид, З. Хәким кебек татар драматургларының әсәрләре, нигездә, илебез тарихында «вакланган», «кечкенә» кешенең яшәешен тасвирлау һәм татар милләтенең үзбилгеләнешен югалту проблемасы белән бәйле. Тарихка пародия, ирония күзлегеннән якын килеп, алар инсан яшәешенең яңа кыйммәтләрен барлыйлар, читлек, хаос рәвешендә оешкан җәмгыятьтә адәм баласының исән калу юлларын эзлиләр.

Әлеге хезмәт татар драматургиясендә чагылыш тапкан «театраль пространство» концепциясенә күзәтү формасында башкарылды. Төрле чор драматургиясендә бик күп үзенчәлекле әсәрләр, авторлар әле өйрәнелмәде. Шул сәбәпле башка татар драматургларының иҗатлары һәм без карап үткән әдипләрнең әсәрләре дә тагын да тулырак, тирәнрәк анализлауны таләп итә. Мәкаләдә бирелгән нәтиҗәләр татар драматургиясендә бу концепцияне аңлауда ярдәмче була алалар.

**Әдәбият**

*Ахундов М.Д.* Концепции пространства и времени: истоки, эволюция, перспективы. М.: Наука,1982. 224 с.

*Барт Р.* Три внешних пространства. Раскол. Выход из тупика. Избранные работы: Семиотика. Поэтика: Пер. с фр. / Сост., общ. ред. и вступ. ст. Г.К. Косикова. М.: Издательская группа «Прогресс», «Универс», 1994. 616 с.

*Возгривцева К.И.* Театральное пространство: культурологический аспект.// Известия Уральского государственного» университета. 2005. № 35. С. 57–63.

*Волькенштейн В.* Драматургия. Метод исследования драматического призведения. М.: «Федерация», 1929.272 с.

*Гадамер Г.-Г.* Игра искусства // Вопросы философии. 2006. № 5. С. 164–168.

*Ибраһимов Г.* Сайланма әсәрләр. 8 томда. Т. 3. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975.

*Ильин И.* Театр как критика. Маска автора. Общество спектакля // Ильин И. Постмодернизм от истоков до наших дней. М.: Интрада, 1998. 255 с.

*Кулахметов Г.* Яшь гомер. Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 286 б.

*Лиотар Ж.-Ф.* Состояние постмодерна / Пер. с фр. М.: Институт экспериментальной социологии; СПб.: Алетейя, 1998. 160 с.

*Лотман Ю.* Заметки о структуре текста. Культура и текст как генераторы смысла // Лотман Ю. История и типрлогия русской культуры. СПб., 2002. 768 с.

*Маньковская Н.Б.* Эстетика постмодернизма. СПб.: Алетейя, 2000. 347 с.

*Мейерхольд В.* Лекции: 1918–1919. М., 2001. 280 с.

*Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань, 2002.

*Ортега-и-Гассет Х.* Дегуманизация искусства // Ортега-и-Гассет Х. Эстетика. Философия культур. М., 1991. 588 с.

*Скоропанова И.С.* Русская постмодернистская литература: новая философия, новый язык. СПб.: Невский Простор, 2001. 416 с.

*Станиславский К.С.* Собр. соч.: в 9 т. М.: Искусство: Московский Художественный театр, 1999.

*Топоров В.* Миф. Ритуал. Символ. Образ. Исследованияв области мифопоэтического. Избранное. М.: Издательская группа «Прогресс» – «Культура», 1995. 624 с.

*Тюпа В.И.* Художественный дискурс: введение в теорию литературы. Тверь: Твер. гос. ун-т, 2002. 80с.

*Хайдерггер М.* Время картины мира // Хайдерггер М. Время и бытие. М.: Республика, 1993. 447 с.

*Хализев В.* Драма как явление искусства. М.: Искусство, 1978. 240 с.

*Хейзинга Й.* Игра и культура // Хейзинга Й. Homo Ludens. Статьи по истории культуры. М., 1997. 416 с.

*Хәким З.* Мин төш күрдем... Пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 307–346.

*Хәмид Р.* Ак тамырлар иле // Казан утлары. 1991. № 10. Б. 128–151.

*Хәмид Р.* Каен җиле. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 159 б.

*Хәмид Р.* Олы юлның тузаны: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 190 б.

*Цимбал С.* Театр, театральность, время. Л: 1977. 263 с.

*Шамсутова А.* Татар әдәбитында постмодернистик карашлар // Гыйльми язмалар, ТГГИ. Гуманитария. 2002. Октябрь. Б. 45–49.

*Шамсутова А.* Татар әдәбиятында постмодернистик концепцияләрнең чагылышы.Махсус курс өчен кулланма. Казан: Казан дәүләт гуманитар институты, 2003. 36 б.

*Шамсутова А.* Хәзерге татар әдәбиятында постмодернистик карашлар һәм Зөлфәт Хәким иҗаты // Гыйльми язмалар. ТГГИ, 2003. № 11. Б. 17–21.

*Шамсутова А.* Отражение просветительских концепций в татарской драматургии XIX – нач. XX в. // Просветительское движение у тюркских народов и творчество Абпя. Сборник материалов Международной научно-практической конференции, посвященной 175-летию со дня рождения казахского поэта, просветителя, общественного деятеля Абая Кунанбаева. Казань, 14 декабря 2020 г. Кзань, 2020.С. 280–283.

*Шарипова А.С., Шамсутова А.А.* Концепции «разрушения» и «созидания» в пьесах Гафура Кулахметова // Вестник Чувашского государственного педагогического университета им. И.Я. Яковлева. 2021. № 4. С. 91–98.

*Шарипова А.С., Шамсутова А.А.* Кризис национальной идентичности героев в творчестве Ризвана Хамида // Russian linguistic bulletin, 2021, № 4. С. 202–205.

*Artroud Antonin.* Tiyatro ve Ikizi. Ceviren: Bahadir Gulmez. Istanbul, Yapi Kredi Yayinlari, 2009. 144 s. (на русском языке: *Арто А.* Театр и его двойник. М.: Мартис,1993. 191 с.)

*Keskin, Yildirim.* Tiyatronun Ilkeleri. Istanbul. Doruk Yayimcilik. 2008. 164 s.

***Шәмсутова Алсу Атлас кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, «Татар мәдәнияте һәм сәнгате» оешмасы җитәкчесе*

УДК 784.4

## СОЛТАН ГАБӘШИ
## ТАТАР МУЗЫКАСЫ ТУРЫНДА

*(дәвамы)*

*Башы журналның 2022 елның 1, 2 нче саннарында*

### МУЗЫКА ТУРЫНДА БЕЗНЕҢ СОРАУЛАР[1]

*«ЯҢАЛИФ» АНКЕТАСЫ*

**Татар музыкасы турында**

*11. Киләчәктә пролетариат музыкасы үстерү өчен нинди чаралар күрергә, нинди юллар белән барырга кирәк дип уйлыйсыз? Опера төзү өчен көчәнү файдалымы, әллә аерым шигырьләр, аерым моментка эшләү юлы белән генә дәвам итәргә кирәкме?*

*12. Бездә пролетариат музыкасы үстерү өчен кадрлардан ничек файдаланырга кирәк? Әлегә хәтле туган халык көйләрен җыйнау, эшләү, яңаларны тудыру һәм аларга тулаем бер караш салу, тикшерү өлкәсендә нишләргә кирәк. Моны тикшерерлек бездә көч бармы, бу безнең хәлебездән киләме һәм бу эштә чит милләт белгечләреннән ничек файдаланырга?*

***Композитор Солтан Габәши***

***11 нче сорауга:*** Бу сорауга җавапта, гомумән алганда, әнә шул югарыда күрсәтелгән комачаулыкларны бетерә-югалта торган чараларны күрергә кирәк дип уйлыйм.

Конкрет рәвештә алганда, Гыйльми институтның музыка кабинеты тарафыннан күрсәтелгән тәкъдимнәрне нигез итеп алып, түбәндәге чараларны күрсәтәм:

1. Эшчеләр массасына музыкаль тәрбия көчәйтү өчен, опера һәм симфония репертуарларын күбәйтергә, булган кадәрлесен киң пролетариат массасы эченә чыгарып күрсәтергә кирәк.

Моның өчен шушы эшләр эшләнергә тиеш:

а) Булган ике опера белән (башлангыч һәм күчү баскычы сыйфатында) киң эшчеләр массасын таныштыра барырга;

ә) Яңа пролетариат опералары җитештерү юлында чаралар күрергә. Бу эш бердән рус сәхнәсендә булган революцион операларны тәрҗемә итү юлы белән, 2 нчедән яңа оригиналь әсәрләр язуга заказлар бирү юлы белән эшләнергә мөмкин.

[1] Музыка турында безнең сораулар // Яңалиф. 1931. № 3. Б. 59–60, 62–71; № 4. Б. 55–60; № 5–6. Б. 86–91. Әлеге текст кириллицага нигезләнгән татар алфавитында беренче тапкыр дөнья күрә. *(А. Софийская иск.)*

2. Симфония репертуарыннан беркадәрлесен киң пролетариат массасына файдаланырга тапшыру белән бергә, яңа заманга яраклы эчтәлекле симфония әсәрләре тудырырга кирәк. Бу эш шушы юллар белән үтәлә ала:

а) Сирәгрәк булса да, системный рәвештә зур симфония концертлары оештыру;

ә) Яңа әсәрләр язарга заказлар бирү;

б) Казан татар дәүләт академия театры каршында бер тулы симфония оркестрына җитәрлек оркесторант музыкантлар кадры асрау.

3. Кадрлар җитештерү мәсьәләсенә әһәмият биреп, аларны күбәйтү чараларын күрергә кирәк.

Моның өчен түбәндәге эшләр эшләнергә тиеш:

а) Сәнгать техникумының хәзерге алган инструктор-педагоглар җитештерү нигезе белән янәшә аерым үтәүче-исполнительләр классы ачып, профессиональ җырчы һәм музыкантлар, бигрәк тә оркесторантлар җитештерүне алга алырга;

ә) Булган кадәрле көчләрнең квалификацияләрен үстерергә;

б) Татар театры каршындагы опера бүлеген студия хәленә куеп, артистларга кирәкле кадәр белемнәр бирү юлларын карарга;

в) Шул ук студиягә, сәхнәнең массовкасы өчен һәм зур концертларда күмәк җырлар өчен, эшче крестьян массасы эченнән аерым яшь көчләр алып, бер состав асрарга һәм аларны эш белән бергә укытырга да. Моның өчен, әлбәттә, аларны җитәрлек жалунья яки стипендия, торак һәм укытучылар составы белән тәэмин итәргә.

г) Чит шәһәрләрдә оркестрлар составында йөргән белемле татар музыканларырын Казанга чакырып алдырырга һәм үзәктә консерваторияләрдә укып ятучы татар укучыларына контрактация ясарга, җитмәгән кадәрлесен башка милләттән булган музыкантлар белән тутырырга.

4. Музыканы массага җитештерү өчен, сәхнәдән үтәп күрсәтү белән бергә аны турыдан-туры массаның үз кулына тапшырырга.

Моның өчен түбәндәге чараларны күрергә мөмкин:

а) Булган кадәрле музыкаль материалларны бастырып, мөмкин кадәрле күбрәк масса эченә тарату чараларын күрергә «Татиздат»ка тапшырырга. Шуның белән бергә бастырыла торган әйберләрнең ялгыз җыр (соло) өчен булганнарына гына туктамый, рояль, скрипка, гармун, мандолина һәм башка халык уен кораллары өчен, шулай ук кечерәк оркестрлар, ансамбльләр өчен язылган әйберләргә, хор өчен мәҗмугалар төзүгә нык әһәмият бирергә.

Киләчәктә бу эшне җиңел башкарып булсын өчен, матбагаларның берсендә яки каршында ноталар басмасы (нотопечатня[1]) булдыру һәм аны кирәк кадәр белгеч эшчеләр белән тәэмин итү эшенә керешелгәндә дә зарар итмәс иде.

---

[1] Бу сүз кириллицада бирелгән.

ә) Ноталар төсле кулланмаларны тарату белән бергә, киң масса эчендә музыка белемен үстерү эшенә дә бик нык әһәмият биреп, музыка фәннәреннән махсус музыкантлар йә шул эш белән шөгыльләнергә туры килә торган укытучылар, режиссерлар вә башкалар өчен тулы зур кулланмалар һәм мәктәп укытучылары, музыка һәвәскәрләре вә гомуми масса өчен җиңел формада кыскартылган популяр теория китаплары бастыру эшенә керешергә кирәк. Бу юлда иң элек башланма музыка теориясе дәресләре (элементарная теория[1]) өлешенә әһәмият биреп, музыка тарихы, акустика, музыка эстетикасы һәм фәлсәфәсе шикелле нәрсәләргә дә игътибар итәргә кирәк.

б) Югарыда күрсәтелгән материал һәм белемнәр белән реаль файдалана белү эшен куәтләр өчен, төрле уен коралларында уйнарга үзеннән-үзе өйрәткечләр (самоучитель[2]) бастыру эшенә дә керешүне ашыктырырга.

в) Клубларда, авылларда, колхозлар һәм совхозларда татар-җыр музыка түгәрәкләрен күбәйтергә һәм булган кадәрлеләрен көчәйтергә кирәк. Бу эш үзеннән-үзе стихия рәвешендә барудан чыгарга тиеш. Шуңар күрә бу эшне алга сөрү өчен, булган клублар, колхоз-совхозларны районлаштырып, район саен җитешкән кадәрле көчләрдән махсус инструктор организаторлар кую юлын тотканда зур уңышлар бирә алыр идек дип уйлыйм.

г) Шул инструкторлар көченнән һәм башка көчләрдән файдаланып, клублар һәм колхозларда лекция-концертлар ясап, шунда массаны музыканың торышы (сущность[3]) белән һәм аның социализм төзелеше чорында тоткан урыны белән таныштыра барырга.

д) Бу лекция-концертларда татар көйләре белән бергә Европа композиторларының әсәрләрен дә куеп, композиторларның иҗатларына һәм әсәрләренә характеристикалар бирә бару белән, татар массасын культур музыка белән таныштыра барырга, аларның музыкаль ишетү куәләрен тәрбияләргә һәм ул әйберләргә сыйнфый ноктадан карашларны аңлата барырга.

Бу эшләрне башкару өчен Татпроф советның культсекциясенә, Наркомпросның масса секторына тиешле күрсәтмәләр бирергә.

е) КҮЕ кооперативының музыка кораллары магазины ачуына әһәмият биреп, массаны кирәкле булган запас кисәкләр, материаллар (мәсәлән, кыллар) белән тәэмин итеп торуны йөкләтергә.

Шулай ук үзәкнең күрсәтүе буенча язылган граммафон тәрилкәләрен алдырып, тарату эшенә дә зур әһәмият бирү турында да күрсәтү язарга.

5. Чын мәгънәсе белән бүгенге хезмәт итә торган концерт һәм эстрада өчен яңа әсәрләр җитештерүгә бик ныклап керешеп. Шул эшләрне эшләргә:

---

[1] Бу сүзтезмә кириллицада бирелгән.
[2] Бу сүз кириллицада бирелгән.
[3] Бу сүз кириллицада бирелгән.

а) Язучыларыбызга, бигрәк тә ТАППка төрле бәйрәмнәр, еллык (годовщина[1])лар шикелле планлы компанияләргә карата, музыкага салыр өчен уңайлы рәвештә махсус язылган яңа әсәрләр иҗат итү турысында уйлануны тапшырырга.

ә) Язучылар белән композиторлар арасында якынрак элемтә тоту юлларын табып, аны гамәлгә ашыру эшен, композиторларның оешмалары һәм оешма төзерлек саннары булмаганлыктан – ТАППның үз өстенә алырга кирәк икәнлеген ТАППка әйтергә.

б) Шагыйрьләргә һәм композиторларга югарыда әйткән юлда яңа әсәрләр язарга заказлар биреп, ул яңа иҗатларында күмәкләшеп үтәлә торган (дуэт, трио, квартет, хор һәм зур булмаган оркестрлар өчен билгеләнгән) әсәрләр иҗат итүгә әһәмият бирә төшүне киңәш итәргә.

в) Язучы һәм композиторларга, ара-тирә булса да, пролетариат массасының эчендә булып, аның тормышы, эше, үсеш һәм иҗатлары белән якыннан танышу өчен, елына берәр мәртәбә генә булса да, озаграк срок белән, промышленность районнарына, колхозларга командировкаларга йөртергә.

г) Шул чаралар нәтиҗәсендә язылган заманга яраклы яңа әсәрләрне шул ук моментта масса эченә тарату өчен, ноталары белән бастырып тарата тору эшен Татиздатка йөкләргә.

д) Моңарчы булган иске һәм яңа революцион шигырьләрне җыйнатып, бер мәҗмуга хәлендә һич кичектерми бастырып чыгарырга Татиздатка задание итеп тапшырырга һәм аңар аерым шагыйрьләрнең әсәрләрен берәр мәҗмуга йә мәҗмугаи әсар сыйфатында бастыра торуга зуррак әһәмият бирү кирәклеген әйтергә.

6. Музыкаль әйберләргә тәнкыйть ясау эшләрен хәзерге хосусый тәәссерләр, хосусый фикерләр һәм бертөрле нигезсез буш сүзләр язу юлыннан чыгарып, бер яктан киң масса фикеренә нигезләнгән җәмәгатьчелек нигезенә куярга кирәк.

Моның өчен:

а) Концерт, кичәләрдә үтәлгән әйберләр хакында рецензияләр язу өчен хосусый бер генә кешегә тапшырмый, репортер сыйфатындарак, берничә кешегә тапшырып, тыңлаучы масса эченнән интервью ясау шикеллерәк фикер җыеп, шул җыелган фикерләрнең җыентыгын, төрле фикерләр булганда, күпчелекнең фикерен, тәәссерләрен язу рәвешенә кертергә.

ә) Яраксыз әйберләр чүп-чар белән тутырмау яки ялгыш юлга кертеп җибәреп адаштырмау өчен, Сәнгать техникумы каршындамы, Гыйльми үзәк йә Гыйльми институт яисә Главлит каршындагы (вакыт-вакыт җыйнала торган) даими бер белгечләр комиссиясе төзеп, һәрбер дөньяга чыга торган әсәрне шуның карамагына һәм рөхсәтенә тапшырырга.

Бу комисссия эчендә бер яктан музыка белгечләре булып, алар әсәрнең музыкаль төзелеш ягын, музыкаль эчтәлек форма һәм худо-

[1] Бу сүз кириллицада бирелгән.

жество ягын карасалар, икенче яктан сәяси ягын караучылар, әсәрнең идеология ягын һәм бу көн өчен ярап-ярамау ягыннан тикшерергә тиешләр.

Бу белгечләр арасында татарлар белән бергә чит милләт кешеләре дә булырга тиеш. Ләкин алар гали укымышлы, зур стажлы музыкант булу белән бергә, сәяси дә яхшы булырга.

б) Шул ук яңа әйберләрне кечерәк клубларда, завод-фабрикаларда турыдан-туры (непосредственно[1]) пролетариат массасы алдына үтәп күрсәтеп, соңыннан фикер алышу-дискуссия ясау шикелле чаралар белән, алар хакында пролетар фикерен һәм хөкемен белергә һәм шуңа карап эш йөртергә.

Бу юлда тыңлаучыларның фикерен алу, бик кыска гына һәм бик кысып язылган анкета өләшеп, шуларга җавап җыю формасында эшләгәндә тагына да яхшырак булып, ул эшне башкару да әллә ни авыр эш булмас иде дип уйлыйм. Чөнки башка театрларда бу методның кулланылуы һәм яхшы нәтиҗәләр бирүе күрелә һәм ишетелә килә.

«Опера төзү өчен көчәнү файдалымы?» дигән сорауга җавап югарыда язылганнардан беркадәр аңлашылса да, бу турыда шуны әйтергә кирәк:

Бу сорау рус музыка галәмендә дә озак яшәп, бер тараф – «кирәкми», икенче як – «кирәк» дип, күп бәхәсләр узганнан соң инде бу мәсьәлә соңгы җавап, ягьни «кирәк» дигән карашның урнаштырылуы белән хәл ителде дияргә мөмкин.

Һәм, минемчә, шулай булмый хәле дә юк иде. Чөнки сәнгатьләрнең бик күбесен эченә алган синтетик бер әсәр булып, культураның зур җиңеше саналган һәм тыңлаучыларга бирә торган тәэсире ягыннан бөтен театр формаларыннан өстен, югары тора торган операны «пролетариат өчен кирәк түгел» дип, бүгенге көндә гигант адымнар белән социализм төзеп яткан һәм шундый ук адымнар белән культурага аяк баскан пролетариатны культура һәм сәнгатьнең иң югары уңышыннан мәхрүм итү яисә «пролетариат аңар хаклы түгел» дигән төсле мәгънәсез бер сүз сөйләнгән булыр иде.

Хәлбуки, пролетариат үзенең характеры белән моның бөтенләй киресен күрсәтеп тора. Пролетариатның музыкаль әсәрләргә булган мөнәсәбәтен, сәнгать белгечләреннән һәм марксизм галимнәреннән булган Луначарский бу сүзләр белән күрсәтә:

«Бәлки опера белән балет бөтенләй искергәннәрдер һәм шуңар күрә без монда һичбер төрле яңалык эшли алмадык һәм эшли алмабыз дадыр?

Әгәр алар искергән булсалар, зур театр буп-буш булыр иде. Ә без аның гел тулы булуын һәм пролетар тамашачының бик зур теләү белән бу опера һәм балет спектакльләренә билет алганын беләбез. Ә бит иске яхшы опера һәм балет спектакльләре безне канәгатьлән-

[1] Бу сүз кириллицада бирелгән.

дерәләр, яңалары исә безне канәгатьләндерми. Әгәр алар шулай да безнең массовый тамашачы дикъкатен тарталар икән, бу теория кирәк түгел дип әйтүче һәрбер кешенең тормышка каршы булуын, бөтенләй марксистларча сөйләмәвен күрсәтә. Юк, мондый, хәтта хәзер булган төсле опера театры да безгә кирәк. Әгәр без аны чыннан да безнең чорыбыз кирәкләренә яраклы итә алсак, ул ошашсыз тагы да артыграк кирәгерәк булыр».

Икенче урында ул болай ди:

«Пролетариатка опера театрына керү юлын ачкан революция сәнгатьнең бу формасына аның омтылышын күрергә мөмкинлек бирде.

Нигә музыкантлар туннан утырып, суыктан дерелдәп, паузаларда бармакларына өргән Зур яки Мариинский театрлар, якында туплар гөрселдәсә дә, үзгәрешсез һәр кичне үзләренең пәрдәләрен күтәрәләр һәм үзгәрешсез күпсанлы публиканы, яртысыннан күбрәге пролетариат булган публиканы җыялар иде? Чөнки театрның бу формасы күтәренке, гадәттән тыш якты матурлыклы, бәйрәмнәрдәгечә тәэсиратлы тормышны чагылдыру тонышыннан зур шатлык бирә иде. Моңар гомумосталык – җырлау, музыка, бию осталыгы, ягъни эшчеләрнең гаять сөйгән үтәү тулылыгы өстәлә иде. Алар чын оста сизелгәнне, яхшы, таза эшләнгәнлекне яраталар. Ахырында монда драмада булмаган сәнгать синтезы бар иде».

Шуңа күрә хәзер рус галәме әлеге сөаль белән баш ватмый, бик чыннан булган опера театрларын саклау гына түгел, хәтта әүвәлдә булып та хәзер сүнгән театрларын да тергезергә карар биреп[1], бик ныклап аларның репертуарларын советлаштырырга тотынды.

Бу юлда алар «Юктан бер нәрсә дә булмый» яки «Һичбер нәрсә күктән төшми» дигән фикерне нигез итеп, иң әүвәл иске байлык, иске операларны пролетариат идеологиясе һәм марксизм карашы ноктасыннан тикшереп чыгып, хәзерге көн өчен зарарсыз булганнарын үрнәк рәвешендә сакларга һәм яңа совет опералары җитештерү эшенә керештеләр. Бу хакта (репертуар сайлау эшендә) нинди юл тотылганын күрсәтү өчен, СССР күләмендәге Музыка конференциясенең музыкаль театр хакындагы карарларыннан репертуар турындагы 3 нче маддәсенең бер кисәген күчерәм:

– «...Искедән калган музыкаль мирасны сайлау мәгънәсендә, безгә идеясе ягыннан якын булган яхшы классик үрнәкләргә ориентация тотарга кирәк. Бу иң башта тематикага кагыла, ул социаль реализм планында формалашырга тиеш: а) көчәйгән сыйнфый көрәш эпохасын тасвирлауны киң социаль алышлы музыкаль драма; ә) чикле чын бытовой дөрес эчтәлекле опера; б) халык эпосының иң таза үрнәкләрендә төзелгән әсәрләр; в) идеология ягыннан ерак торсалар да, музыкаль драматик иҗатның биеклеген күрсәтүче әсәрләр. Үзләренең иҗатларында хәзерге буржуазиянең тенденцияләрен чагылдыручы Европа һәм рус композиторлары әсәрләре, шулай ук күбрәк дини

[1] Шушы уңай белән ясалган докладларда бу билгеләү (определение)ләргә конкрет мисаллар да күп кенә күрсәтелгән. *(С. Габәши иск.)*

мистик характер эчтәлекле әсәрләр репертуарга кертелергә тиеш түгелләр».

Баш-аягы белән ике-өч музыкаль драмабыз булып, ул әсәрләрнең һәр елны унар-унбишәр куелыш күтәрүләре һәм аларны унар меңләп оешкан профсоюз массасы каравын күз алдына китерсәк, югарыдагы Луначарский сүзләре безнең хакта да бик дөрес туры киләләр. Шуңар күрә мин куелган сорауга: «Опералар төзү өчен көчәнү файдалы һәм шуның белән бергә аерым моментларга карата, аерым шигырьләргә эшләүне көчәйтергә кирәк», – дип җавап бирәм.

Шуның өстенә бер опера һәйәтенең яшәве, бигрәк тә югарыда күрсәтелгән теләкләр дә үтәлә калса, татар пролетариат музыкасының үсеше һәм яшь көчләр (һәм үтәүче һәм иҗатчы)нең үсүе өчен иң төпле һәм иң ныклы база булачагын да онытырга ярамый.

Узган ел башы башланып, бу ел рәсми рәвештә оешкан опера составының бөтен иске музыка көчләребезне диярлек, бергә оештырып, үз эченә әллә никадәрле яшь көчләрне дә тартуы һәм акрынлап үсә баруы белән бергә, аларга эшләрендә таяныч, киләчәккә ышаныч булып, көч биреп торуы, бу хәлнең дөреслеген ачык күрсәтсә кирәк дип уйлыйм.

Аннан соң бу опера һәйәтенең бер идарә кул астына җыелып, бергә оешкан һәм тиешенчә хәзерләнгән бер көч булып, планлы рәвештә перифериядәге пролетар районнарында хезмәт итә алуын һәм композиторларның яңа әйберләрен уйнатып, җырлатып карау өчен әзер бер көч булып торуын һәм шулай ук аерым комиссияләр, бригадалар төзеп эшләү юлы белән яңа репертуар тудыру, аны баету юлында да күп хезмәт итә алачагын да истән чыгарырга ярамый.

***12 нче сорауга:*** Кадрлар мәсьәләсенә килгәндә, бездә, гомумән, музыка көчләре, бигрәк тә композиторлар кадрлары «юк»дип әйтерлек дәрәҗәдә аз.

Шуның өчен иң элек аларны күбәйтү, үрчетү һәм үстерү турысында сөйләргә кирәк.

Моның өчен музыкантның кәсебен, башка кәсепләр (инженерлык, врачлык, агрономлык) белән куя торган шәраит тудырырга кирәк.

Без бу көнгә хәтле «музыкантлар читешми, кеше юк, кеше кирәк, музыкантлар кирәк» дип шаулап йөрүгә карамастан, бу мәсьәләдә конкрет нәтиҗә бирерлек шәраитлар тудыра алганыбыз юк. Бу хәл татар яшьләренең музыкантлыкка бирелмәүләренә, шул юлга тартылып килә алмавына һәм шуның аркасында татардан музыкант яшь көчләрнең җитешмәү – чыкмавына иң беренче сәбәп булды дип уйлыйм. Казанда ун елдан бирле дәвам итеп килә торган Мех.техникумының тәҗрибәсе моны бик ачык күрсәтте, һәр елны 20–30 татар баласы алына барган хәлдә, бетереп чыгучы йә консерваторияләргә китүчеләр елына бер-ике йә бер дә юк булып, калганнары техникумда бер-ике ел маташканнан соң, музыканы ташлап, йә нинди дә булса башка уку йортына күчеп йә турыдан-туры хезмәткә кереп китә бардылар.

Кадрлар азлыкның икенче гомуми сәбәбе булып, техникумда укучыларны юлбашчылык итүче учреждениеләрнең музыкантка артык мөһим булмаган йә бер дә кирәкмәгән зиннәтлелек (роскошь[1]) дигән төслерәк карашлары аркасында булса кирәк. Материаль яктан (юньле-башлы торак булмау, стипендиянең иң түбән дәрәҗәсе бирелеп, ул да булса, бик аз санда булуы кебек) бик начар шартлар эчендә торулары булды.

Шуңар күрә, кадрларны үстерү өчен икенче чара итеп, мин музыкаль тәрбия мәсьәләсенә бик нык әһәмият бирү, аны беренче планга кую һәм укучыларны иң яхшы шартта булган укучылар белән бер дәрәҗәгә кую кирәк дип уйлыйм.

Инде беркадәрле кадрлардан файдалану юлларына килсәк, беренчедән, аларга иҗат эше белән шөгыльләнә алырлык шәраитлар тудырырга кирәк. Икенчедән, аларга заданиеләр бирү, заказлар бирү шикелле чаралар белән билгеле бер эш тудыру һәм аны билгеле бер юлда алып бару кирәк. Өченчедән, эшләгән эшләрнең реаль файда күренерлек рәвештә әсәрләрен сатып алу һәм бастыру шикелле, үзеннән-үзе эшкә кызыктыра торган чаралар күрергә кирәк.

Шуның белән бергә бу чараларның зарарлы яклары да булырга мөмкин. Алар бердән, музыка дөньясын акча өчен генә эшләнгән халтура, чүп-чар белән тутыру булса, икенчедән, үсеп җитмәгән яшьләр өчен дә композиторлык чире тудырып, аларны укуларыннан аеру, аларны ярты юлда калдыру рәвешендә булырга мөмкин.

Татар музыкасы галәменә килеп очраган чит музыкантлар үзләрен сукаланмый торган кырга барып кергән крестьян кебегрәк хис итеп, кай җиреннән сөрсәң дә иген уңар дигән төслерәк хәрәкәт итүләрен һәм моңар кадәрле мин күргән, белгән эшләр иң әүвәл акча (авторский алу) мәсьәләсен күз алдында тотып кына эшләнеп, әллә нинди ярамас хәлләр узганын мин күп фактлар белән күрсәтә алыр идем. Ләкин бу урында санап тормый, характерлы берсен генә күрсәтәм:

Мин бер заманнарны «Дүдәк» көен хор өчен эшләп, «Кыйгаклар бак-баклар» өстәп җырлаткан идем. Шуннан соң аны Архангельский дигән берәү кайдандыр-кемнәндер табыпмы-языпмы алган да Татиздатта «Татар халык көе» дип сатып, авторскиен кесәгә салып та киткән. Матбугат, әдәбият һәм хокук торышыннан бу эш ничек атала торгандыр, анысын белмим. Ләкин аннан катгый нәзар, зрә чеп-чи бер шәхси иҗатны ул халык көе иттереп, дөньяны саташтырып куйган.

Әлегә хәтле туган халык көйләрен җыйнау турында, бердән, фәнни тикшерү институты Музсектор планы буенча экспедицияләр чыгарып, көйләрне җыйдыру эшен эшкә ашырырга һәм аны ашыктырырга кирәк, икенчедән, аерым кешеләрдә сакланып яткан кулъязмаларын җыйнап сатып алырга кирәк.

[1] Бу сүз кириллицада бирелгән.

Җыйналган көйләрне эшләү (разрабатывать[1] итү) эше композиторлар эше булганлыктан, ул хакта югарыда әйтелгән тәкъдимнәргә кайтарып калдырырга туры килә.

Халык көйләрен тудыру мәсьәләсендә массага ярдәм йөзеннән югарыда күрсәтелгән чаралар белән массага музыкаль тәрбия бирү, аның музыка культурасы дәрәҗәсен үстерү юлын тотарга мөмкин. Ләкин моның белән дә әллә ни мөһим халык көйләре тудырып булыр дип уйламыйм. Чөнки тарихның күрсәтүенә караганда, халык көйләре һәм, гомумән, халык иҗаты дигән нәрсәләр, тормышның һәм мәдәниятнең бер билгеле дәрәҗәсенә кадәрле генә дәвам итеп, аннан соң халык иҗаты акрыная, зәгыйфьләнә, азая һәм бара торгач, ул бөтенләй туктап, иҗат эше бөтенләе белән аерым шәхесләр (шагыйрьләр, әдипләр, композиторлар...) кулына күчеп кала.

Дөрес, масса эчендә бик күп яңалыклар, яңа иҗатлар туарга мөмкин һәм алар масса тарафыннан кабул ителеп, таралып, җәелеп, массалашып китәргә дә мөмкин. Ләкин аларны иҗат итүчеләр шәхсесез (безличный[2]) халык булмыйча, шул халыкның эчендәге музыкантлар йә җырчылар, икенче төрле әйтсәк, чын мәгънәсе белән пролетар баласы – пролетар композиторлары булырлар дип уйлыйм.

Караш салу мәсьәләсе. Ул көйләрнең барысын бергә җыйнап, җыенысына бер караш белән хөкем чыгарырга мөмкин түгел дип уйлыйм. Шуңар күрә ул көйләрне берәм-берәм карап чыгып, җентекләп тикшереп, һәркайсын, мөмкин булган кадәрле тарихларын (кайда, ничек чыгышларын) өйрәнергә, кайда нинди урында кулланылганын эзләп, табып, рухи, төзелеше якларыннан әлеге белгечләр комиссиясендә тикшереп һәм пролетариат массасы белән (клубларда...) тикшереп, яраклысын – яраклыга, яраксызын аерып архивка куярга кирәк булыр дип уйлыйм.

Моның өчен кирәкле көч, бик үк җитеп бетмәсә дә, бар, һәм ул киткән саен үсә барачак дип уйлыйм.

Ләкин бу эштә чит милләт эшчеләренең (әлеге комиссиядә әгъза булудан артык) берничек тә файдалары тимәс дип уйлыйм.

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының текстология бүлеге*
*фәнни хезмәткәре* ***Фәйзуллина Фәния Галимулла кызы***
*әзерләде*

[1] Бу сүз кириллицада бирелгән.
[2] Бу сүз кириллицада бирелгән.

УДК 81'33

***Н.М. Мифтахетдинова***

# ТӨРКИ ТЕЛЛЕ ЯЗУ МАШИНАЛАРЫНДА ЯҢАЛИФКӘ ЯРАКЛАШТЫРЫЛГАН СТАНДАРТ КЛАВИАТУРА ПРОЕКТЛАРЫ

В Советском Союзе у тюркских народов одна из полностью реализованных масштабных реформ – это переход от арабицы к так называемой Яналиф. С введением нового тюркского алфавита на основе латиницы встал вопрос о создании унифицированной клавиатуры пишущих машин, наборных касс.

В 1926 году создан Всесоюзный центральный комитет нового тюркского алфавита (ВЦК НТА). В состав комиссии входили видные ученые-тюркологи, лингвисты, полиграфисты. Комитет выполнял следующие задачи: создание унифицированного тюркского алфавита на латинице, терминологии, разработка стандартной клавиатуры пишущих и наборных машин и другие вопросы по реализации латинского алфавита в национальных республиках. По поручению ВЦК НТА М. Идрисов разработал унифицированную клавитуру. В некоторых национальных республиках были проекты клавиатур пишущих машин, в частности в Татарстане проект Г. Измайлова.

В данной работе рассматриваются статьи оппонентов М. Идрисова и Г. Измайлова, опубликованные в журнале «Яналиф» 1929–1930 гг. В создании унифицированной клавиатуры они взяли за основу метод Б.А. Гольцева, который был утвержден ВЦК НТА.

Техническая комиссия, созданная в Татарстане, приняла в 1929 году проект стандартной клавиатуры пишущих машин Г. Измайлова. По утверждению М. Идрисова, он приспособил татарских букв на азербайджанскую клавиатуру. Однако исследования М. Идрисова показали, что такая клавиатура пишущих машин для других тюркских языков не пригодна.

1929 году М. Идрисов разрабатывает унифицированную клавиатуру пишущих машин для 8 тюркских языков на основе «слепого метода».

В 1930-е годы М. Идрисов продолжает работу по созданию стандартной клавиатуры пишущих машин для 20 тюркских и других национальностей. В Татарстане разработки Идрисова были внедрены в производство в 1936–1937 гг.

**Ключевые слова:** Яналиф, пишущая машина, 10 пальцевая система, арабица, арабисты, латинисты.

In the Soviet Union, among the Turkic nations, one of the fully implemented large-scale reforms is the transition from Arabic to the so-called Yanalif. With the introduction of a new Turkic alphabet based on the Latin alphabet, the question arose of creating a unified keyboard for typewriters and typesetting cash desks.

In 1926, the All-Union Central Committee of the New Turkic Alphabet (VCC NTA) was created. The commission included prominent Turkologists, linguists, printers. The Committee carried out the following tasks: the creation of a unified Turkic alphabet in Latin, terminology, the development of a standard keyboard for typewriters and typesetting machines, and other issues related to the implementation of the Latin alphabet in the national republics. On behalf of the All-Russian Central

Committee of the NTA, M. Idrisov developed a unified keyboard. In some national republics there were projects for typewriter keyboards, in particular in Tatarstan the project of G. Izmailov.

This paper examines the articles of opponents M. Idrisov and G. Izmailov, published in the journal «Yanalif» in 1929–1930. In creating a unified keyboard, they took as a basis the method of B.A. Goltsev, which was approved by the All-Russian Central Committee of the NTA.

In 1929 the Technical Commission which was established in Tatarstan adopted the project of a standard typewriter keyboard by G. Izmailov. According to M. Idrisov, he adapted the Tatar letters to the Azerbaijani keyboard. However, studies by M. Idrisov showed that such a typewriter keyboard is not suitable for other Turkic languages.

In 1929 M. Idrisov develops a unified typewriter keyboard for 8 Turkic languages based on the «blind method».

In the 1930s, M. Idrisov continued to work on creating a standard typewriter keyboard for 20 Turkic and other nationalities. In Tatarstan Idrisov's developments were put into production in 1936–1937.

**Keywords:** Yanalif, typewriter, 10-finger system, Arabic alphabet, Arabists, Latinists.

Яңалифкә күчү барышында төрки халыклар алдына язу машиналарында бердәм калыплашкан клавиатура булдыру мәсьәләсе килеп баса. Язу машиналары клавиатурасында хәрефләр бирелешендәге төрлелек машинисткаларның эшен катлауландыра, типографияләрдә хәреф җыючының төрле хәрефләр урнашкан кассаларда эшләргә мәҗбүр булуы хезмәт җитештерүчәнлеген түбәнәйтә, полиграфия сәнәгатенең үсешен тоткарлый. Шулай ук типографияләрдә кулланылмый яткан хәреф билгеләренең күплеге, ил күләмендә металл, шул исәптән кургашын кытлыгын исәпкә алганда, икътисадка аеруча зур зыян сала.

Милли республикаларда латинга күчү төрле оешмаларга берләшү аша, уртак идея тирәсендә тупланган түгәрәкләр эшчәнлеге рәвешендә 1920 елларда башланып китә һәм берничә елдан дәүләт тарафыннан финанс ягыннан тәэмин ителгән һәм совет идеологиясенә тулаем җавап биргән зур көчкә әверелә. Латинга күчү хәрәкәте ил күләмендә бердәм үзәк – Бөтенсоюз яңа төрки алфавиты үзәк комитеты аша идарә ителә. Һәр милли республикада яңа төрки алфавитка күчү бүлекчәләре эшли. Латинга күчү төрки халыклар белән бергә башка халыкларга да үтеп керә. Бу елларда рус телен дә латинга күчерү өлкәсендә эшчәнлек җәелеп китә.

Казанда 1928 елның 18–23 декабрендә Бөтенсоюз яңа төрки алфавиты үзәк комитетының III пленумы үтә. Әлеге пленумның Казанда узуы латинчылыкның җиңүе буларак билгеләп үтелә, гарәп шрифтында китаплар басуга чикләүләр кертелә, мәктәпләрдә латин әлифбасы нигезендә укыта башлыйлар. Шулай ук пленумда һәр республикада латинга күчешнең башлану һәм тулысынча тәмамлану вакытлары билгеләнелә. Азәрбайҗанда 1922 ел – латинчылыкның тарала башлау вакыты, 1929 ел тулысынча латинга күчү елы дип күрсәтелә. Татарстанда исә бу эшнең 1927 елда башланып, 1931 елның

1 гыйнварына тәмамлануы көтелә [А. Камчин-Бек, с. 125]. Азәрбайҗан белән чагыштырганда Татарстанда латинлашу чорының күпкә соңрак башлануын һәм тәмамлануын күрәбез. Төп сәбәпләрнең берсе – Татарстан җөмһүриятендә гарәп шрифтына корылган полиграфия сәнәгать үзәге булу. 1927 елда Татарстан Гыйльми советы карамагында Мәгариф халык комиссариаты тарафыннан билгеләнгән жюри комиссиясе басма гарәп хәрефләрен бер шәкелдә калдыру проектларына конкурс үткәрә һәм җиңү яулаган проект тиз арада типографиядә кулланышка кертелә. Бу конкурста М. Идрисов проекты нәфислеге һәм кулланылышы ягыннан иң отышлысы дип табыла һәм беренче урынны яулый. И. Зәйнуллин белән К. Фәхретдиновның уртак проектлары икенче урын ала. Афиша хәрефләре калыплары буларак Ш. Тукаев проектына өстенлек бирелә [Мәгариф, 1927, б. 119].

Ил күләмендә гарәпчеләр тарафыннан Казанда үткәрелгән төрки халыклар өчен гарәп хәрефләрен бер шәкелгә калдыру реформасы китап басуны икътисади яктан отышлы итә, язу машиналары клавиатурасына татар һәм башка төрки әлифбасы сыешлыгын тәэмин итә. Мәсәлән, М. Идрисов кереш мәкаләсендә: «Читтән кергән язу машиналарын сүтми генә клавиатурага алфавитны урнаштыру ысулын уйлап табуга хәрефләрнең бер язылышын гына калдыру төп этәргеч булды», – дип искәртә [Идрисов, б. 3].

Шул ук вакытта реформаның тормышка ашырылуы латин язуы таралуны тоткарлаучы көчле киртәгә әйләнә.

Ф. Агазадә, К. Карашлы хезмәтендә гарәпчеләр үткәргән бер шәкелгә калдыру реформасының кулланылышка керүе нәтиҗәсендә Татарстан, Казакъстан, Кырым төбәкләрендә латинга күчү вакытының берничә елга соңга калып башкарылуы искәртелә [Агазаде, Каракашлы, с. 38].

1927 елда Казанда үткән конкурста җиңү яулаган талантлы полиграфист М. Идрисов сигез төрки телдә язу һәм типографиядә хәреф җыю машиналарының стандартлаштырылган клавиатураларын эшли (1929). Һәм аны Бөтенсоюз яңа төрки алфавиты үзәк комитеты карамагына тапшыра. Аның Казан татарлары, башкорт, казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән, азәрбайҗан һәм Кырым татарлары телендә стандартлаштырылган клавиатуралар схемасын һәм беркадәр аңлатмаларны үз эченә алган фәнни хезмәтләре басылып чыга [Идрисов, 1929].

М. Идрисов Бөтенсоюз яңа төрки алфавиты үзәк комитеты тарафыннан һәр сигез телдә язылган китаплар һәм матбугат басмалары белән тәэмин ителә. Шушы материал нигезендә ул һәр телдә хәрефләрнең кулланылыш ешлыгын билгели. Әлеге эзләнүләр таблицада, басмаларда күрсәтелеп барыла. Ул сигез телдән барлыгы 70 меңгә якын хәреф, һәм хәрефнең хәреф белән очрашуын белү өчен, яңадан комплекслап, 55 мең пар хәреф саный. М. Идрисов фәнни эзләнүләрендә Б.А. Гольцев методологиясенә таяна.

Хәреф белән хәрефнең бергә туры килү ешлыгын билгеләү, текстлардагы сүзләрне хәрефләргә таркатып, аларның бер-берсе

белән нинди ешлыкта кушылып килүләрен тикшерү рәвешендә алып барыла, мәсәлән, «алардан» сүзендә: *ал, ла, ар, рд, да, ан.* Шул рәвешле һәр телнең материалы тикшерелә.

М. Идрисов язу машиналарының стандартлаштырылган клавиатурасында хәрефләрне төймәгә урнаштыруны *10 бармак белән язу* ысулына яраклаштыра. Һәр бармакның көченә карап, имән бармак төймәләренә күп очрый торган хәрефләрне, аннан, киметә барып, иң аз кулланыла торган хәрефләрне чәнчә бармакларга билгели, уң кулга эш күбрәк калдырыла.

М. Идрисов төрки-татар телләренә хас сингорманизмны да читләтеп үтми: калын һәм нечкә сүзләрдә очрый торган хәрефләрне төрле бармакларга тарата. Шул рәвешле телнең эчке кануннарын язу машиналарына җайлаштыру сүзләрне бер кул белән генә җыю ихтималын читләтеп үтәргә мөмкинлек бирә.

Соңыннан Бөтенсоюз яңа төрки алфавиты үзәк комитеты М. Идрисов тарафыннан сигез төрки тел өчен эшләнгән бердәм стандарт клавиатура проектын милли республикалардагы бүлекчәләргә тапшыра. Һәр телдә типографияләрдә – хәреф җыю, машинисткалар курсында практик кулланылышы тикшерелә. Күпчелек республикаларда проект уңай бәяләнә һәм тиз арада гамәлгә кертелә.

Татарстанда исә М. Идрисовныкы белән бергә Г. Измайловның да стандартлаштырылган клавиатура проекты тәкъдим ителә. 1929 елда Татарстанда техник комиссия төзелә һәм биредә Г. Измайлов проекты уңай бәя ала. М. Идрисов проекты элекке кулланылыштагы латин хәрефләре өстендә эшләнүе аркасында кабул ителми.

Габдрахман Измайлов (1889–1957) – полиграфист, татар милли стенографиясенә нигез салучыларның берсе. Типография эшчәнлеген революциягә кадәр үк башлый. 1901–1906 елларда ул – Казан университеты басмаханәсе эшчесе, 1917 елдан Казанда бертуган Кәримовлар типографиясендә хәреф җыючы. Совет чорында Г. Измайлов – Казанда Камил Якуб исемендәге полиграфия-нәшрият комбинаты директоры, аннан «Яңа китап» нәшрияты идарәсе рәисе урынбасары вазифаларын үти. 1921 елда Казанда үткән хәреф ислахы конкурсының жюри рәисе була.

Шулай ук Г. Измайлов хәреф җыючылар әзерләү курслары мөгаллиме дә була. 1933 елда репрессияләнә һәм 8 елга ирегеннән мәхрүм ителә. Бары тик 1957 елда гына аклана.

«Яңалиф» журналында Татарстан җөмһүрияте тарафыннан оештырылган Техник комиссиядә Г. Измайлов проектына өстенлек бирелүен һәм, М. Идрисовның язу машинасы клавиатурасы проектындагы кимчелекләрне күрсәтеп, мәкалә басыла [Яңалиф, 1929. № 11]. Г. Измайловның әлеге мәкаләсен редакция фикер алышу рәвешендә тәкъдим итә. Элекке алфавиттан файдалануны М. Идрисов хезмәтенең төп кимчелеге дип саный. Бу очракта Азәрбайҗанда кулланылган алфавит турында сүз бара (искәрмә. – *Н.М.).* 1929 елда төрки халыклар өчен уртак алфавит кабул ителә.

М. Идрисов исә Г. Измайлов клавиатурасының Азәрбайҗан клавиатурасының татар теленә яраклаштырылган бер варианты гына булуын, төрки халыклар өчен стандарт клавиатура була алмавын дәлилли [Яңалиф. 1930. № 22].

1930 елда М. Идрисов Бөтенсоюз яңа алфавиты үзәк комитеты йөкләмәсе буенча бу өлкәдә эшчәнлеген дәвам итә. Ул 1929 елгы проектлардагы җитешсезлекләрне төзәтә, төрки халыклар өчен 1929 елда кабул ителгән стандарт алфавитта нәшер ителгән китаплардагы текстларны куллана. Нәтиҗәдә 20 төрки тел һәм башка телләр өчен язу һәм типографиядә җыю машиналары клавиатуралары эшләнә.

Татарстанда 1936 елда М. Идрисов проекты буенча «Яңалиф» язу машинасына эшләнгән клавиатура производствода тикшерү үтә. Нәтиҗәсе уңай бәяләнә һәм ул 1936–1937 елларда кулланылышка кертелә [Выписка, 1936].

Түбәндә әлеге мәкаләләр тәкъдим ителә.

## Яңалиф клавиатурасы

Шәрык җөмһүриятендә Яңалиф гамәлгә куела башлау белән төрле-төрле клавиатураларда язу машиналары һәм типографияләрдә төрлечә итеп хәреф салынган набор кассалары күренә башлады. Хәзерге көндә бер шәһәрдә генә түгел, бәлки бер үк учреждениядә яңалифчә ике төрле клавиатурада язу машинасы, бер үк типографиядә ике төрле клавиатурада язу машинасы хәреф кассасы очратып була.

Мондый төрлелек хезмәтне җиңелләштерү һәм экономика ягыннан күп уңайсызлыклар тудыра. Киләчәктә моның аркасында без язу машинасының клавиатурасын да хәреф кассаларын да стандартлаштыра алмаячакбыз. Бер клавиатурада язып өйрәнгән машинистка икенче урынга күчү белән үк икенче төрле клавиатурада язарга, бер хәреф кассасына ияләшкән наборщикка икенче кассадан җыярга өйрәнергә һәм шуңа никадәр вакыт уздырырга туры киләчәк. Бу яктан да без эшченең квалификациясен күтәрү юлында комачаулыклар ясаган булабыз.

Шуның белән бергә типографияләр өчен коелган хәрефләрнең кирәк үлчәүдә дөрес куелмавын, кирәкле бер хәрефнең җитмәгәнен һәм аз китә торганының күп булуын да күреп торабыз. Хәзерге вакытта металл (кургашын) кризисы барганда хәреф кассаларында әллә никадәр хәрефнең файдасыз ятканлыклары күз алдыбызда.

Менә мин шул җитешсезлекләрне төшенеп, стандартлаштыру юлында башлангыч бер хезмәт булсын дигән ният белән, төрек-татар халкы өчен берләштерелгән клавиатура һәм набор кассасы проектларын хәзерләдем. Бу эшләрне барлыкка китерү иң әүвәл һәр халыкның әлифбасындагы хәрефләрнең язмада ни дәрәҗәдә очраганлыкларын тикшерү һәм шуларны санау аркасында гына була ала.

Хәреф санау методлары белән Бөтенсоюз Яңалиф комитетын таныштырганнан соң, комитет тарафыннан миңа түбәндә саналачак

телләрдә китап, гәзит һәм журналлар бирелде: 1) казан татарлары, 2) башкорт, 3) казакъ, 4) кыргыз, 5) үзбәк, 6) төрекмән, 7) азәрбайҗан һәм 8) Кырым татарлары телендә. Бу мәкаләмдә шул әсәрләргә таянып төзелгән проектлардан язу машинасы клавиатурасына тукталмакчы булам.

Бу клавиатура түбәндә саналачак нигезләрдә төзелде:

1. Клавиатураны СССРда таралган машиналардан «Ундервуд»-ның 42 клавишлы машинасына төзү.

2. Хәрефләрне төймәгә урнаштыру «10 бармак белән язу» ысулына яраклы тиеш; ягъни һәр бармакның үз көченә карата күп очрый торган хәрефләрне имән бармак төймәләренә, аннан азайта барып, иң аз китә торган хәрефләрне чәнчә бармакларга, уң кулга күбрәк эш калдыру.

3. Бер-берсенә күп очрый торган хәрефләрне бер генә бармак астында калдырмыйча, мөмкин булган кадәр ике бармакка бүлеп кую. Болай итү бер-берсе белән күп очрый торган ике хәрефне бер бармак түгел, бәлки һәр ике бармак суксын өчен кирәк була. Чөнки эшләгәндә бармакларның бәргәләп хәрәкәтләнүләре эшкә күп җиңеллек бирә. Мәсәлән, төрек-татар телләрендә иң күп очрый торган *ар, ла, ан,ын, ер, йа, лә* кебек иҗекләр (комплекслар)ның хәрефләре минем клавиатурада һәр ике имән бармакка бүленгәннәр. *А, ә, ь, е* хәрефләре уң имән бармакка, *л, н, р, т, й* кебек хәрефләр сул имәнгә куелганнар.

4. Төрек-татар телләрендәге сингорманизм аерымлыкларына нык игътибар итеп, калын һәм нечкә сүзләрдә очрый торган хәрефләрне төрле бармакларга бүлгәләү. Әгәр моның киресенчә булса, ул вакытта бөтен сүзләр бер кулдан гына язылу ихтималы зурая. Машинада язганда бер кулның эшләп, икенчесенең тик калуы эшнең үрчемле булуына кимчелек китерә.

5. Клавиатураны югарыда саналган барлык телләргә бертөрле һәм барысына яраклы итеп төзү. Төймәгә урнаштырылган бер хәреф нинди генә телдә басканда да бармакларның хәрәкәтенә зур үзгәреш китерерлек булмасын. Бармакларның көчләренә карап бирелгән эш проценты икенче телдә баскан вакытта да сизелерлек дәрәҗәдә үзгәрмәсен. Мәсәлән, татардагы *ә* белән казакътагы *ә* нең язуда очрауларында күп аерма бар. Шулай булган хәлдә, минем клавиатурада ике төрле телдә язганда да имән бармакның эш проценты бер үк чамада тора.

Менә мин шушы нигезләр өстендә төзелгән проектны Бөтенсоюз Үзәк Яңалиф комитетының Гыйльми хәятенә тапшырган идем. Шул проектым, нигездә, яраклы дип табылганнан соң, һәр җөмһүриятнең үзендәге комитетларына, яки гыйльми үзәкләренә таратылган иде. Алардан беренчеләр казакъ, кыргыз, үзбәкләр минем проектны үзләренең язу машиналары өчен нигез итеп алырга булганнар иде. Шулар рәтеннән Татарстан Гыйльми Үзәге янында да бер техник комисссия төзелеп, минем клавиатура проекты да каралган. Г. Измайловның язуына күрә, минем проект, комиссиянең фикеренчә, бердәм Яңалифнең иске имлясына карата төзелгәнлектән, икенчедән хәреф саннары аз булганлыктан яраксыз дип табылган.

Минем проект өчен саналган хәреф турысына килсәк, 8 телдән барлыгы 70 меңгә якын хәреф, һәм хәрефнең хәрефкә очрашуын белер өчен, яңадан комплекслап 55 мең пар хәреф саналган. Хәрефләрне тикшергән чакта яңа имля мәсьәләсе минем өчен артыгы белән аңлашылган мәсьәләләрдән булганлыктан, язуда мәгълүм берничә хәрефләрнең (*ь, е, й*) азрак куллану ихтималы клавиатураның әллә ни үзгәрүенә сәбәп була алмый. Хәзер шуны тикшереп карасак, минем фикерем дөрес булганын күрәбез.

Бу мәкаләдә минем тарафтан 8 тел өчен берләштерелгән клавиатураның рәсеме күрсәтелә. Һәр хәрефнең астында Г. Измайловның яңа имлядан саналган цифрлары язылa. Клавиатураның астында һәр кул һәм бармакка күпме процент эш төшкәне күрсәтелә. Уң кулга барлык эшнең 52,67 проценты, сул кулга 47,33 проценты төшкән була. Минем әүвәлге клавиатурада уң кулга 53,30%, сул кулга 46,33 проценты төшкән була. Минем әүвәлге клавиатурада уң кулга 53,30%, сулга 46,70% эш туры килгән иде. Димәк, яңа имляда *ы, е, й* кимү кулларның эш хәрефләренең кимүе кулларның эш процентларына артык үзгәреш ясый алмаган. Моның белән уң кулның эше сулга фәкать 0,63% кына күчкәнен күрәбез.

Комиссия минем клавиатурага яңа цифрларны салып карарга, ни өчендер, кирәк тапмаган. Әгәр шулай итеп караган булса, дөреслек ачылган булыр иде.

Г. Измайлов клавиатурасына килсәк, ул инде комиссиядә яңа бер проект хөкемендә кабул ителгән һәм шуны Татарстанда стандартлаштыру турында карар да чыгарылган. Ләкин бу мәсьәләдә мин һичбер төрле дә яңалык яки Измайлов проекты диярлек бер эш тә күрмим. Чөнки мондый клавиатура минем кулга эш башлаганда ук кергән иде.

Бөтенсоюз Яңалиф комитеты миңа хәреф санау материаллары җибәргән вакытта Азәрбайҗанда кулланыла торган клавиатураның схемасын һәм Кырым клавиатура проектын да биргән иде. Мин үз вакытында шуларның башка телләргә ярап-ярамаганлыкларын тикшереп узган идем. Азәрбайҗан клавиатурасы бераз үзгәреш белән татар теленә яраса да, башка телләргә бөтенләй туры килмәгәнгә күрә, аны нигез клавиатура итеп алу файдасыз булачак иде.

Менә шул Азәрбайҗан клавиатурасының нәкъ үзе шикелле бер клавиатура Г. Измайлов тарафыннан да «Татар стандарт клавиатурасы» исемендә комиссиягә тәкъдим ителә. Ике клавиатура арасында аерма булса, ул да 6 хәрефнең (*е, ч, ң, о, а, ь*) урыннарын күчерүдә генә була. Башка 36 төймәнең хәрефләре үз урыннарында калдырылалар. Шуңа күрә комиссиягә бу клавиатураны Измайлов проекты дип түгел, бәлки Азәрбайҗан клавиатурасы татар теленә яки башка төрек-татар телләренә ярыймы-юкмы дип карарга кирәк иде. Бу эшне дә комиссия җиңел генә уздырган вакытта, проект төзүче сыйфаты белән миннән беркадәр ачыклаулар соралган булса, мәсьәлә, әлбәттә, икенче рәвештә, дөрес юл белән хәл ителгән булыр иде.

Инде Г. Измайлов биргән клавиатураның башка телләргә ярап-ярамаганын тикшерә башласак, бер карауда ук аның Татарстан өчен генә хәзерләнгәнен күрәбез. Аның клавиатурасына башка телләрнең цифрларын китереп караганда, бармакларның эш нормасы мөмкин булмаслык дәрәҗәдә үзгәреп китә. Мәсәлән, кырым, казакъ һәм төрекмән телләрендә уң кулның эше 64% ка менеп, сулныкы 36% ка төшеп кала. Боларны җентекләү һәм клавиатураның югарыда күрсәтелгән нигезләре туры килеп җитмәвен тикшерү бу урында минем эшем түгел. Фәкать мин шуны гына әйтеп китәргә тиешле, әгәр Татарстан бөтен СССР масштабыннан карап, берүзе өчен генә булмыйча, бәлки барлык төрек-татар телләренә яраклы бер клавиатура булдыруны кирәк дип тапса, ул вакытта Измайлов биргән клавиатура шул теләкләрне аз гына булса да үти алмаячак.

*М. Идрисов. Яңалиф. 1930. № 22*

**Язу машинасы турында (Проект стандартной клавиатуры татарских пишущих машин (42 кл.))**

Бездә бу көнгә кадәр ясалып чыккан машиналарның клавиатуралары бер төрле яктан да эшләнмичә һәм гыйльми яктан да тикшерелмичә, хәрефләрнең клавиатурага куелышы ничек туры килсә, шулай куелып килде. Ләкин безнең практик эштә язу машиналарының клавиатураларында хәрефләрнең ул формада, анархия юлы белән баруы Яңалифкә күчкәч мөмкин түгел.

Менә боларны игътибарга алып, Татарстан Үзәк Яңалиф комитеты татар язу машиналарының клавиатураларын юлга салу, стандарт формага кую һәм гыйльми әсаска кору чараларына кереште.

Бу вакытта Яңалиф комитетында ике проект бар иде: берсе Мөхәммәт Идрисов тарафыннан, икенчесе Габдрахман Измайлов тарафыннан эшләнгән проектлар. Яңалиф комитеты бу ике проектны карап чыкканнан соң, мәсьәлә бик әһәмиятле булганлыктан, проектларны тирәнрәк тикшереп чыгар өчен, Татарстан Үзәге янында махсус Техник комиссия төзеп, комиссия эшләренә белгечләрне дә җәлеп итәргә тиеш тапты.

Техник комиссия үзенең утырышларында бу ике проект белән дә танышып, аларны тикшереп чыкканнан соң, М. Идрисов проекты иске имля белән басылган китаплардан алынган хәреф саннары әсасына каратып төзелгәнлекне һәм дә саналган хәреф саннарының да аз булуын игътибарга алып, аның проектын яраксыз дип тапты.

Техник комиссия Г. Измайловның проекты турында докладын тыңлаганның соңында, түбәндәге карарлар чыгарды:

1. Татарча язу машиналарын нык нигездә итеп билгеләү өчен, саналган хәреф саннарын (13 басма табак) җитәрлек дип табарга.

2. Хәзергә кадәр чыккан татар язу машиналарының клавиатураларында хәрефләрнең куелышында бер генә форма булмаганлыкны һәм хәрефләрнең куелышы бер төрле дә гыйльми әсаска корылмаганлык-

ны, шуның аркасында эшләп чыгару эше түбән торганлыкны, шулай ук татар машинисткаларының квалификациясен күтәрүгә дә комачаулыклар тудырганны искә алып, киләчәктә чыга торган язу машиналарының клавиатураларын стандарт формага салуны кирәк дип табарга.

3. Бөтен Татарстанда татарча язу машиналары өчен клавиатурага стандарт форма итеп Г. Измайлов тарафыннан эшләнгән проектны алырга. Шуның белән бергә, бу көнгә кадәр Татарстанда Яңалиф хәрефләре һәм гарәп хәрефләреннән Яңалифкә ясалачак язу машиналарының клавиатураларында әкренләп шул стандарт форма клавиатурага ясалырга тиеш табарга.

Киләчәктә татар әлифбасында тагы бер-ике хәреф артуны стандарт форма клавиатураны тормышка үткәргәндә күз алдында тотарга кирәк, шуның өчен Татарстанда ясала торган яңа машиналар 46 төймәле (клавишлы) булырга тиешләр.

4. Язу машиналарының клавиатураларын стандартлаштыру эшләрен рәсмиләштерү ягын Татарстан Гыйльми Үзәгеннән үтенергә һәм бу эшне тизләтергә кирәк дип табарга.

Бу стандарт форма итеп кабул ителгән язу машинасының клавиатурасына хәрефләрнең куелышы хәзерге яңа имля буенча саналган хәреф саннары әсасына, машинада басканда кайсы хәреф күпме кергәнлекне һәм шуның белән бергә күбрәк керә торган хәрефләрне уртадагы төймәләргә, азрак керә торган хәрефләрне кырыйдагы төймәләргә куеп, урыс язу машиналары кебек гыйльми нигезгә каратып төзелгән.

Моннан соң Татарстанда ясала торган язу машиналары шул стандарт форма клавиатурада ясалырга тиеш.

*Г. Измайлов. Яңалиф. 1929. № 11*

**Әдәбият**

*Агазаде Ф., Каракашлы К.* Очерк по истории развития движения нового алфавита и его достижения. Казань: 1928. Издание ВЦК НТА. 134 с. (НМРТ КППи-124639-31)

Выписка из протокола заседания Президиума Татарского Комитета Нового Алфавита при ЦИК ТАССР от 11 декабря 1936 года (НМРТ КППи-124639-31)

Жюри комиссиясе карарлары // Магариф. 1927. № 12. С. 116–119.

*Идрисов М.* Яңалиф язу машиналары клавиатурасы // Яңалиф. 1930. № 22.

*Идрисов М.* Баш хәрефләр турында. Мәскәү, 1926. 12 б.

*Идрисов М.* Схема унифицированной клавиатуры пишущей машины «Ундервуд» на Ново-тюркском наречии. Москва: Издание ВЦК НТА, 1929.

*Идрисов М.* Схемы клавиатуры пишущей машины и наборной кассы казанско-татарского наречия. Москва: Издание ВЦК НТА, 1929.

*Измайлов Г.* Язу машинасы турында // Яңалиф. 1929. № 11.

*Камчин-Бек А.* Победа Нового Алфавита в Советском Союзе // Культура и письменность Востока. Кн. VI. Баку: Издание ВЦК НТА, 1930. 228 с.

***Мифтахетдинова Нурия Мидхәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Милли музее өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82.0

***Г. Шәрәф***

## ИЛЬИНСКИЙ БЛЮМЕНАУ[1]

В данной статье дается информация о писателе, поэте, переводчике, литературоведе Александре Адольфовиче Блюменау (Ильинский,1885–1971). Поэт-переводчик наряду с поэтическими переводами стихов Овидия, Гете, Гейне, Гюго, а также армянских, грузинских поэтов занимался и переводами татарских песен. В статье Г. Шарафа рассматриваются переводы А.А. Блюменау татарских песен.

**Ключевые слова:** Галимджан Шараф, Александр Адольфович Блюменау, история татарской литературы, переводы, фольклор.

This article provides information about the writer, poet, translator, literary critic Alexander Adolfovich Blumenau (Ilyinsky, 1885–1971). The poet-translator, along with poetic translations of poems by Ovid, Goethe, Heine, Hugo, as well as Armenian, Georgian poets, also dealt with translations of Tatar songs. The article by G. Sharaf considers the translations of A.A. Blumenau Tatar songs.

**Keywords:** Galimdzhan Sharaf, Alexander Adolfovich Blumenau, history of Tatar literature, translations, folklore.

Александр Адольфовичның Казанга килүен язган идек. Аның килүеннән файдаланып, аның берлән мосахәбезне[2] укучыларымыз белән уртаклашабыз. «Сезнең татар җырларыны тәрҗемә белән шөгыльләнә башлауга нәрсә сәбәпче булды?» дигән сөальгә А.А. әфәнде түбәндәге җавапны бирә:

– Без Урта Русиянең зур шәһәрләреннән, хосусан, пайтәхетләрендә торучылар татарларның «шурум, бурум» дип кычкырып йөрүчеләрдән башкасыны бик аз беләмез. Татар дигәч тә безнең күзгә кулына иске нәрсәләр тоткан бер сыйфат күренә.

– Без кешеләрнең үзләренә махсус вә оригинальный матурлыклар белән тулы, безгә күренми торган әдәби дөньялары барлыгын белмибез. Аларның нинди читенлекләр эчендә ничә йөз еллар буенча үзләренең милли хосусиятләрене саклап килә алулары вә аларның сәбәпләре тугрысында без уйлап карарга теләмибез.

– Минем берничә еллар (1905–1909 га кадәр) Уфа губернасы башкортлары арасында үткәргән гомерем бу милләткә карашымны бөтенләй үзгәртте.

Мин башкортлар белән күп катнаша, сөйләшә идем; иң сөйгән нәрсәм – башкортлардан җырлату, курай уйнату иде. Су буйларында бөтен төннәр җырлар тыңлап үтә иде. Шулай итеп маташа торгач, мин татарча яхшы гына сөйләшергә өйрәнгәнемне сизми калганмын.

---

[1] Александр Адольфович Блюменау (Ильинский, 1885–1971) – язучы, шагыйрь, тәрҗемәче, әдәбият галиме. *(Э.М. Галимҗанова иск.)*

[2] *Мосахәбезне* – сөйләшеп утыруыбызны, әңгәмәбезне.

Татарча сөйләгәнемне аңлау, татарларның күңелләре, хәятләренең төрле яклары белән танышуга миңа күп ярдәм итте. Акрын-акрын минем алдымда бу халыкның йомшак, яхшы күңелләре ачыла башлады. Мин бу күңел, бу җаннарда ниндидер куәтле, таза вә киләчәкләренә өмид белән карата торган бер көч күрә башладым.

Татарларның җырларына әһәмият бирә башлаганнан бирле, татар җырларының үзләренә генә махсус русларга, хәтта, гомумән, яурупалыларга ят булган эчкә керү нөфүз куәсе[1] мине гаҗәпләндерә иде. Мин аларның көйләрен, җырларын тыңлаганда үзем дә татарлаша, башкортлаша, үзем дә аларча уйлый, аларча тоя башлый идем. Вә торган саен бу халыкны үземә якынрак күрә, аларны ярата башладым. Үзем яраткан бу халыкны башкаларга гына яраттырасым килә башлады.

Моның өчен аларның өске тормышлары белән генә таныштыру йитми, аларның искедән бирле йөрәкләреннән янып чыккан, аларның шатлыкларыны арттыра, кайгыларыны баса торган күңелләреннән агып чыккан нәрсәләр белән таныштыру кирәк иде.

Иптәшләремнән яшь шагыйрь Ширинскийның киңәше берлән, мин рус матбугатында татарларны таныштыру юлында икенче иптәшем Хәсән әфәнде Таниевның ярдәме аркасында татар җырларын русчага тәрҗемә итә башладым.

Җырларда халыкның җаны, тормышы иң күп күренгәнгә, бу башлавымны иң яхшы юл дип беләм.

Кыскасы: татарларга өмидем, әдәбиятларында хосусият күрүем мине тәрҗемә эшенә керештерде. «Татар җырларында нинди хосусиятләр күрәсез?» – дигән соравыма:

– Беренче, татарларның мәхәббәт җырларындагы искренность, чын сөю, куәтле мәхәббәтнең аңкып торуы – миңа охшаган нәрсәләрдән берсе. Безнең рус җырларында ул куәтне табып булмый. Бездә сөю җырларында бер дә искренность юк. Чын сөю берлән уен-көлке галәме бергәрәк буталып, гыйшык кызулыкларын сеңдергән. Икенче, татар җырларындагы охшату *(тәшәббеһ)*ләр, татар җырларындагы матур охшатуларны, нинди генә телгә тәрҗемә кылсаң да, аның матурлыгын бетерергә мөмкин булачак түгел. Андагы тәшәббеһләр башка телдән урланган булуы да мөмкин түгел, чөнки иң матур охшатулар – татарларның үзләре тормышына гаид[2] нәрсәләрдән алынганнары. Өченче, җырларның ясалышы вә озыннары андый төзелеш безнең рус җырларында юк. Ул безнең өчен яңа. Шуңа күрә мин татар җырларын тәрҗемә иткәндә дә үз урыннарында калдырып тәрҗемә итүгә әһәмият бирәм. Һәм хакыйкатән дә, минем тәрҗемәләр укучыларга, укуы күңелле булган бер яңа нәрсә булып чыга. «Татарча җырлардан башка хәзерге әдипләремезнең әсәрләрене тәрҗемә итәргә уйламыйсызмы?»– дигән сөальгә А.А. әфәнде: «Җырлар һәм ши-

[1] *Нөфүз куәсе* – сүз үтемлелеге, көче.
[2] *Гаид* – караган.

гырьләр тәрҗемәсен дәвам иттереп, әдәби әсәрләргә дә күчәргә дәртем бар. Белмим, кайчан муафикъ була алырмын», ди.

– Тәрҗемә иткәндә нинди әсәрләрне тәрҗемә итәргә уйлыйсыз?

– Әле бер мөхәррирнең бер әсәрләрен күрсәтә алмыйм, алай да мин татарларның төп үз тормышларыннан алынып, татарларның үзләренә махсус тормыш картиналарыны күргәзә торган әсәрләрне тәрҗемә итүне муафикъ табам. Чөнки рус матбугатында инде аңарга ихтыяҗ бар, диде.

– Бераз сөйләшеп утыргач, сүз арасында: бу ел кышның яртысын татарлар күбрәк шәһәрләрнең берсендә торып, татар җырлары хакында тагы киңрәк мәгълүмат алып, татар җырлары хакында Мәскәүдә лекция укырга хәзерләнгәнне сөйләде.

«Өеңдәге хәбәрне күршедән сора», диләр. Үз җырларыңдагы хасиятне үзең белмәгәч, башка кешеләрнең айлар, еллар хәзерләнеп укыган лекцияләрене тыңлап рәхмәт укырга тугры килә шул инде.

А.А. җәнаплары 1905 елларда гына яза башлап, беренче әсәре (кечерәк кенә шигырь мәҗмугасы) 1905 сәнәдә рус матбугаты арасында күренә башлаган.

Бу көндә русларның айлык журналларында, Мәскәүнең көндәлек гәзитәләренең бәгъзеләрендә, язучы һәм хәзер рус матбугатында яхшы ук модага кергән «Иптәшләр мәҗмугалары»нда күренекле урыннар тотып килә торган бер шагыйрь һәм драматургдыр.

А.А. җәнапларының башка рус әдип, мөхәррирләренә караганда безнең өчен бер хосусияте бар. Ул татар телене яхшы белә, татарның иске җырлары, яңа әдәбиятына әһәмият бирә.

Аның татар әдәбиятына әһәмият бирүе бер археолог, бер академикның әһәмият биргәне кеби фәнни тәдкыйкать[1], тарихи әһәмияте өчен түгел; бары бер әдип, бер шагыйрьнең ул әсәрләр, ул җырларда әдәби матурлык, хосусый бер күңеленә охшау күргәнлегеннәндер.

Ул татар җырларын, шигырьләрен татарның үз мәгънәсен русчага тәрҗемә кылып, русларның яхшы әдипләренең әсәрләре, шигырьләре берлән бер рәткә куя. Аларның әсәрләреннән чын татарның йөрәгеннән чыккан сүзләр дә ким түгел, татарларның искедәге моңнары, зарлары, русларның да шул вакытларда әйткән сүзләренә биргесез икәнне, татар җырларын тәрҗемә кылып, күрсәтеп аңлатырга тели.

Әлегә кадәр татар җырлары, ориенталистлар тарафыннан тәрҗемә ителеп, мөтәхассыйслары[2] өчен берничә нөсхәләр генә бастырылып таратылганнары күренгәли иде, ләкин алар берсе дә гомум халык укып ләззәтләнер, шундагы кыйммәтле мәгънәләрдән гомум халыкны файдаландыру өчен тәрҗемә ителгән әсәрләр түгел, бары мөтәхассыйс кешеләрнең кабинетларында булындыру өчен хәзерләнгән тәрҗемәләрдер.

А.А. җәнаплары тәрҗемә булмаган үз шигырьләренең дә бәгъзеләрене татар рухында, татар җырлары гарузында яза. Анда татар

[1] *Тәдкыйкать* – тикшеренүе.

[2] *Мөтәхассыйслары* – белгечләре.

җырларында гына очраргa мөмкин охшатулар ясый. Мисал өчен бәгъзеләрене күрсәтәмез:

Йөрәгемне яндырадыр бер мәхәббәт ялкыны,
Файда бирми һич тә миңа бозлы суның салкыны.

———

Сандугачның балалары бар да кунган тирәккә,
Мәхәббәтең бигрәк каты – кан төшерде йөрәккә.

———

Ал күлмәгем ике пар, берсен кисәм, берсе бар,
Йөрәгемне яндырадыр нечкә билле матур яр.

———

Җефәк киң кара сачең – җефәк бирим урарга,
Бик сагындым, бик саргайдым, килдем җаным күрергә.

***Русчалары:***

Огонь спалил мне всю душу, огонь любви молодой,
Не в силах я унять огня холодной, как лед, водой...

———

Соловушки-детки в ветвях играют, лаская глаз;
От любви пылающей душа кровью облилась.

———

Рубах алых и не счесть – надел одну еще есть,
Страсть к девушке тонко-тальей[1] больно, трудно перенесть[2].

———

Как черный шелк коса твоя, дам шелк волос заплетать.
Я соскучился, я желтый стал, пришел тебя повидать.

**Горе**

*(татарский мотив)*

Умер мой мальчик... Я молюсь Аллаху
Желтые щеки жег своей слезой...
Умер мой мальчик... Я на землю лягу,
С тобой рядышком, с тобой, мой родной...
Я не услышу твоего «алекюм»,
Я не увижу твоих добрых глаз,
Тебя, мой мальчик, заменить мне не [с] кем,
Ты, как лампа в семь фитилей, погас.
И зачем солнцем залито небо?
И зачем пчелы жужжать целый день?
Если-б не уснул, скакал на коне-бы,
И мед бы ты ел, укрываясь в тень...
А теперь ты спишь, спишь, резвый, в полудни,
Я не вижу твоих добрых глаз...
Родной мой мальчик, праздник моих будней,
Ты, как лампа в семь фитилей, погас.

[1] *Тальей* – талией.
[2] *Перенесть* – перенести.

***Тәрҗемәсе:***

## Кайгы

*(татар көенә)*

Минем балакаем үлде... Мин, Аллага гыйбадәт кыла-кыла, саргайган йөзләремне күз яшьләрем белән яндырдым.

Минем балакаем үлде... Синең белән бергә, синең белән беррәттән мин дә җиргә ятар идем, җанкисәгем!

Мин синең «сәлам»еңне ишетмим, мин синең нурлы күзләреңне күрмим, синең урыныңа торырлык, сиңа алмаштырырлык дөньяда һичкем юк, балакаем! Син, җиделе лампа сүнгән кеби сүнеп киттең... Нигә генә соң күк кояш белән яктыртылган? Нигә генә соң умарта кортлары көне буе шаулыйлар? Аһ, әгәр мәңгелек йокы белән йокламаган булсаң, син атларда йөрер идең, вә күләгәгә качып, баллы икмәк ашар идең... Әмма хәзер син йоклыйсың, көн уртасында да йоклыйсың, шаянкаем, нурлы күзләреңне күрә алмыйм. Җанкаем, балам, бәйрәмсез көннәрдә бәйрәмем; җиделе лампа күк, сүндең дә киттең...

*Кояш, 1913, 28 июль, № 181;*
*29 июль № 182.*

*Текстны басмага әзерләүче:*
***Галимҗанова Эльмера Мәхмүт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге мөдире*

УДК 792.071

*Г.И. Каюмова*

# КАМАЛЛАР ДИНАСТИЯСЕНЕҢ ДӘВАМЧЫСЫ
## *(Г. Камалованың тууына 100 ел тулу уңаеннан)*

В статье рассматривается сценическая деятельность народной артистки ТАССР, заслуженной артистки РСФСР Г.Камаловой, преемницы актёрской династии Камаловых, актрисы с широким диапазоном, чьей творческой манере свойственны жизненная достоверность и яркая театральность.

**Ключевые слова:** Г. Камалова, актриса, драма, комедия, сцена, образ.

The article examines the stage activity of the People's Artist of the TASSR, the Honored Artist of the RSFSR G. Kamalova, successor of the Kamal`s dynasty of actors, the actress with a wide range whose creative manner is characterized by vital authenticity and vivid theatricality.

**Keywords:** G. Kamalova, actress, drama, comedy, stage, image.

Драма, комедия, көчле характерлар актрисасы, ТАССРның халык артисты (1976), РСФСРның атказанган артисты (1957) Гәүһәр Габдулла кызы Камалова 1922 елның 29 сентябрендә Ташкент шәһәрендә драма актёры һәм режиссёр, профессиональ татар театрына нигез салучыларның берсе – Габдулла Галиәкбәр улы (Камал I) һәм драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1954), РСФСРның атказанган артисты (1957) Фатыйма Хәйрулла кызы гаиләсендә дөньяга килә. Ул – актёр Камаловлар династиясенең дәвамчысы, татар драматургиясенә һәм профессиональ татар театрына нигез салучыларның берсе, танылган драматург, татар театры тарихында актёрлар династиясен башлап җибәргән Г. Камалның туганының кызы.

Г. Камалова 1949 елда Мәскәүдә Дәүләт театр сәнгате институты (ГИТИС) каршындагы Татар театр студиясен тәмамлый, РСФСРның атказанган артисты О.И. Пыжова төркемендә укый. 1949–1950 елларда – Казан Яшь тамашачылар театрының татар төркеме актрисасы, 1950 елдан – Татар дәүләт академия театрында. Студент елларында уйнаган тәүге Васса Железнова (М. Горькийның шул исемдәге пьесасы буенча), Кунакай (Г. Мөсрәповның «Кузы Көрпеш һәм Баянсылу» әсәре буенча) рольләреннән үк Г. Камалова «үзен көчле драматик темпераментка ия актриса буларак таныта» [Татар энциклопедиясе, 2012, б. 240]. Социалистик реализм иҗат агымының башында торган бөек пролетар язучы А.М. Горькийның «Васса Железнова» әсәрен сәхнәгә куючы режиссёр-педагоглар О.И. Пыжова һәм О.А. Якубовская спектакльдә барыннан да элек буржуазия сыйныфының һәлакәткә дучар ителүенә басым ясау белән беррәттән алдынгы, революцион, яшь буынның аренага килүен күрсәтүне максат итеп куялар. Спектакльдә төп фигура – әлбәттә, Г. Камалова иҗат иткән Васса Железнова –

пароход компаниясе хуҗасы, акчалы һәм абруйлы, тимердәй нык холыклы ханым, мөһим идея-эстетик мәгънәгә ия катлаулы образ. «Ул гаҗәеп көчле, нык ихтыярлы, үз дигәнен эшләмичә, теләгенә ирешмичә калмый торган акыллы хатын. Аның байлыкка гына омтылмыйча, балалары, ире, үзе турындагы төпле уйлары, һичшиксез, тамашачының игътибарын үзенә җәлеп итә» [Татар совет театры, 1975, б. 199]. Тамашачы аның фикер агышының эзлекле рәвештә, эчке каршылыклар аша үскәннән-үсә баруын күрә. Бер караганда, героиня һаман да әле үзенең ныклыгын саклаган кебек. Ихтыяр көчен, күңел җылысын салып алга этәргән эшенең юкка чыгачагын сизенү аның рухи фаҗигасын билгели. Васса, акыллы кеше буларак шуны аңлап, фаҗиганы булдырмый калырга омтыла, бар көчен шуңа җигә. Килене Рашель (Ш. Әсфәндиярова башкаруында) белән ике арадагы низаг та, гап-гади бер бәхәстән башланып китеп, ахырга таба социаль конфликт югарылыгына үсеп җитә. Бу инде каенана белән килен арасындагы шәхси аңлашылмаучылыкларга гына корылган каршылык кына түгел, ә капма-каршы карашлы ике сыйныф, ике лагерьның бәрелеше була.

Г. Камалованың Татар академия театры сәхнәсендә тудырган образлары, характерның асылына төшеп, бөтен тирәнлеге белән ачылуы, социаль характеристиканың төгәллеге, форма ныклыгы, ачыклыгы ягыннан аерылып тора. Актрисаның Софья, Полина (М. Горький. «Соңгылар», «Дошманнар»), Гайнавал, Ханзафа (Т. Гыйззәт. «Ташкыннар»), Мәргыйдә (М. Әмир. «Хөррият»), Камилә (Х. Вахит. «Беренче мәхәббәт,), Галимә (Ф. Бурнаш. «Яшь йөрәкләр»), Зөләйха («Ш. Хөсәенов. Әни килде»), Гашия (Т. Миңнуллин. «Иргетләр»), Сабира (Г.Ибраһимов. «Татар хатыны ниләр күрми»), Ләйли (Н. Исәнбәт. «Миркәй белән Айсылу») рольләре – шундыйлардан. Х. Вахитның яшьлек романтикасы, мәхәббәт лирикасы белән сугарылган, драматургның иҗат мәйданын билгеләгән «Беренче мәхәббәт» пьесасы буенча куелган спектакль аерым игътибарга лаек. Мәңгелек мәхәббәт һәм яшьлек темасы кешенең шәхес булып җитлегүе, ныгуы, тормышта үз урынын табуы проблемасы белән баетыла. 1960 елда бу спектакль бай актёрлык тәҗрибәсенә ия Р. Бикчәнтәевнең режиссёрлык юнәлешендәге эшчәнлегендә беренче җитди җиңүе була. Мавыктыргыч сюжет, зур осталык белән корылган интриганы Р. Бикчәнтәев «персонажларның үзенчәлекле характерлары белән нигезләп ныгыта» [Галиәсгар Камал исемендәге.., 2009, 1 т., б. 292]. Бу спектакльдә Г. Камалова кайчандыр яшьлегендә уйланылмаган гамәл кылган, шулай да бик намуслы, гадел Сәлим Гәрәевичнең (Камал III башкаруында) «ачык йөзле, бераз тулырак гәүдәле булуына карамастан, гаять җитез, беркатлырак хатыны Камиләне» [Галиәсгар Камал исемендәге.., 2009, 1 т., б. 293], язучы, әдәбият галиме, тәнкыйтьче Г. Кашшаф фикеренчә, үз кайгыртучанлыгы үзенә үк авырлык тудыра торган «тынгысыз кайгыртучы» ананы «бик әйбәт» уйный. «Камилә – Камалова ана да, дус та, ул мәрхәмәтле дә, үзенчә

акыллы да, тик җиңелчәлек тә юк түгел. Иренә әйтмичә генә кызына «яхшы» кияү табып, Рәхиләне кияүгә бирергә риза булуы шуны күрсәтә» [Кашшаф, 1960, б. 105], – дип яза мәкалә авторы. Спектакльдә һәр актёр үз ролен зур җаваплылык хисе тоеп башкара, тамашачы һәркайсының уенын яратып кабул итә. Яшь режиссёр бу спектакльдә бербөтен актёрлар ансамбле тудыруга ирешә. Спектакль театр тәнкыйте тарафыннан да уңай бәяләнә [Кашшаф, 1960; Иделле, 1960; Мөсәгыйть, 1960]. Шул елны режиссёр Р. Бикчәнтәев һәм драматург Х. Вахит шушы спектакль өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнәләр. 1960 елда гына да аның театр сәхнәсендә 99 тапкыр уйналуы – спектакльнең уңышын билгеләүче, күтәрелгән мәсьәләләрнең актуальлеген, режиссёр һәм иҗат коллективы башкарган эшнең камиллеген раслаучы күрсәткеч. Әдәбият галиме А. Әхмәдуллин билгеләп үткәнчә, «Беренче мәхәббәт» Уфа, Алма-Ата, Ташкент, Сәмәрканд, Бохара, Оренбург, Сембер, Чабаксар, Ижау һ. б. шәһәрләрнең театрлары сәхнәләрендә зур уңыш белән бара [Ахмадуллин, 2012, с. 316].

1960 еллар башында театр беренче мәртәбә Г. Ибраһимов прозасына мөрәҗәгать итә. Әдипнең революциягә кадәрге татар авылы тормышын, аеруча хатын-кызлар язмышын үзәккә алып яктырткан «Татар хатыны ниләр күрми» әсәре буенча куелган спектакльнең төп уңышы, – Г. Кашшаф фикеренчә, «аның реалистик көчендә, сәнгать чынлыгында, берсе икенчесенә охшамаган характерларның гәүдәләнешендә» [Кашшаф, 1975, б. 85]. «Әдипнең каләм көче бөек Толстойның художниклык көчен хәтерләтә... Г. Ибраһимов революциягә кадәр яшәгән хатын-кызлар язмышын, аларны чолгап алган тирәлекне шундый реалистик чаралар белән күрсәтә, бу реализмда тормыш-көнкүреш детальләрен тотып ала белү осталыгы, кешеләр характерын җанландыра торган буяуларның төрлелеге, искелекне фаш итүдә дәһшәтле рәхимсезлек, матурлыкны һәм хатын-кызның күңел нәфислеген олылау, хәтта аларга бер көч итеп табыну кебек сыйфатлар бар» [Кашшаф, 1975, б. 82, 83], – дип яза ул, үз сүзләре белән әйтсәк, «социаль типларны ювелир осталыгы белән эшкәртә белгән бөек әдипнең» [Кашшаф, 1975, б. 83] каләм тибрәтү осталыгына сокланып. 1978 елда режиссёр П. Исәнбәт кабат шушы ук инсценировкага әйләнеп кайта. Беренче вариантта «куе буяуларда тормыш-көнкүреш күренешләре һәм социаль мотивлар өстенлек алган булса» [Галиәсгар Камал исемендәге.., 2009, 1 т., б. 300], икенчесендә исә режиссёр «спектакльнең эчке хасиятенә күбрәк игътибар бирә, татар халкының күңел кылларын тибрәтә торган яңа, нәфис сәхнә чаралары эзли һәм, сәхнә киңлеген иркенрәк файдаланып, шартлы-метафорик алымнарны мул кулланып, сәнгати яктан нәфис бизәлешкә ия булган өр-яңа әсәр тудыра» [Галиәсгар Камал исемендәге.., 2009, 1 т., б. 297]. Гөлбану ролен яшь артистлар А. Гайнуллина һәм Ф. Хәйруллина башкара. Башка рольләрдә Ш. Биктимеров, Р. Шәрәфиев, Н. Дунаев, И. Хәйруллин чыгыш ясый. Г. Камалова

Сабира ролендә уйный. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: бу составта актёрларның һәркайсы үз ролендә алыштыргысыз була. Алар тарафыннан һәр персонажның рухи дөньясы психологик яктан нечкә, төгәл һәм үтемле итеп ачыла. Ш. Хөсәенов иҗатының иң югары ноктасын билгеләгән, әдипне ил күләмендә киң мәйданга чыгарган, таныткан, көчле социаль-иҗтимагый яңгырашлы «Әни килде» пьесасы буенча 1970 елның 26 мартында куелган, тормышчан җирлеге нык спектакль турында да шуңа охшаш сүзләр әйтергә мөмкин. Театр белгече, галим Г. Арсланов билгеләп үткәнчә, спектакль «зур уңыш белән куела. Тамашачы аны иҗат итүчеләргә басып кул чаба» [Галиәсгар Камал исемендәге.., 2009, 1 т., б. 357]. Актёрларның сирәк очрый торган done бербөтен ансамблендә һәр актёр – төп рольне башкаручы Г. Ибраһимова, Н. Дунаев (Сәйяр), Н. Гәрәева (Римма), Ш. Биктимеров (Ислам), Р. Таҗетдинов (Инсаф), Г. Шамуков (Максуд), Г. Камалова (күптән түгел генә югары уку йортын тәмамлаган Сәйярнең гаделлек өчен көрәшеп яшәүче кыю йөрәкле фатир хуҗасы Зөләйха ролендә) – барысы да, характерның психологик асылын тирән тоеп, аның дөньяга карашын ачык яктыртып, үзенә билгеләнгән рольне зур җаваплылык хисе белән башкара. Актёрлар, сәхнә югарылыгыннан затсыз сыйфатларны, ятышсыз гамәлләрне фаш итеп, рухи матурлыкка өндиләр, мәрхәмәтле булырга чакыралар, мораль-этик, әхлакый кыйммәтләрне яклап чыгалар, шул рәвешчә эстетик идеал бөеклегенә омтылалар. Ярылып яткан сәхнә темпераментына ия актриса буларак, Г. Камалова Ч. Айтматовның «Анам кыры» әсәре буенча куелган телевизион спектакльдә Тулганай ролен башкара. Ул шулай ук телевидениедә режиссёр, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Г. Хөсәенов тарафыннан тормышка ашырылган башка постановкаларда да уңышлы чыгыш ясый. Актрисаның, героиняларының драматизм белән сугарылган, кайвакыт хәтта фаҗигалы язмышларын тирәнтен кичереп, мимика, кул, гәүдә хәрәкәтләре, интонация ярдәмендә эчке асылларын ачу осталыгы ул иҗат иткән образ-характерларның сәнгати бөтенлеген билгели.

Аз, әмма ышандырырлык дәрәҗәдә төгәл сәнгати сурәтләү чаралары ярдәмендә Г. Камалова театр сәхнәсендә көчле характерлы хатын-кыз образлары тудыра. Э. Альтның «Сукыр» әсәре буенча куелган спектакльдә ул башкарган Диаконисса, Х. Вахитның «Мәхәббәтең чын булса» пьесасы буенча куелган спектакльдә Хәят – шундыйлардан. Диаконисса – Камалова – бары күзләреннән генә эчке киеренкелеге сизелеп торган, хакимлек итәргә яратучы көчле хатын кыз. Сәхнәдә аның йөзе ак, гәүдәсе тораташ, куллары ялварулы халәттә кушырылган була. Бу ханымның дини фанатизмы артында эчке трагедиясе яшеренгән. Диана белән икесенең диалогында хатын «тирән хәсрәте сизелеп торган тыныч кына тавыш белән сугышта үлгән балалары һәм ире турында сөйли. Һәм әле генә бер-берсен күралмаган ике хатын-кыз арасында рухи туганлык хисе барлыкка килә» [Илялова, 1978, с. 52]. Х. Вахитның «мактаулы, җаваплы һәм авыр

хезмәт кешеләренә дан җырлау нияте белән язылган» [Әхмәдуллин, 2007, б. 36] «Мәхәббәтең чын булса» пьесасы буенча спектакльдә актриса зирәк, авылдашларының хөрмәтен казанган өлкән яшьтәге укытучы Хәят Газизовна ролен башкара. Әлеге образ аша бурыч хисе, хезмәткә, үзара мөнәсәбәтләргә, балаларны тәрбияләүгә карата намуслы, гадел булу һәм тугрылык хуплана. «Тормышта ялган урын алмасын, тәрбия эшендә фальшның эзе дә булмасын, сөюдә риялануга урын юк – тәҗрибәле укытучы Хәят Газизовна да, яшь укытучы Мөршидә дә менә шулар өчен көрәш алып бара. Бу көрәштә олы яшьтәге Хәят Газизовна яшьләргә хас романтик омтылыш, активлык үрнәкләре күрсәтә» [Әхмәдуллин, 2007, б. 36]. Актриса бу образны сәхнәдә тормышчан һәм ышандырырлык итеп гәүдәләндерә. Карап торышка Г. Камалова героинялары тыныч, хис-кичерешләрендә тотрыклы, аз сүзле, сирәк елмаючан, кайвакыт хәтта кырыс, әмма әлеге басынкылык артында, гадәттә, тирән драматизм, көчле хисләр яшеренгән. Персонажларның эчке дөньясын, рухи кичерешләрен тирәнтен ачып, алар язмышында аерым чорның социаль-икътисади каршылыклары чагылышын төгәл тоемлап, актриса теге яки бу героинясы кылган гамәлнең сәбәбенә нигезле төшендерә.

Г. Камалованың иҗат биографиясендә аның комедиячел талантына юл ачкан Шәмсия, Бибигайшә (Х. Вахит. «Күк капусы ачылса», «Ике килен-килендәш»), Хаҗия (Т. Гыйззәт. «Кыю кызлар»), Фәүзия (Ф. Яруллин. «Әнә килә автомобиль»), Гөлбану (К. Тинчурин. «Назлы кияү»), Хәдичә, Нәгыймә (Г. Камал. «Банкрот»), Әйшә, Гөлбану (Н. Исәнбәт. «Зифа», «Хуҗа Насретдин»), Камилә (М. Кәрим. «Кыз урлау») рольләре аерым игътибарга лаек. «Әлеге образларга теге яки бу күренешләрне гротеск дәрәҗәсенә җиткереп сурәтләү, тормыш дөреслеге хас» [Татар энциклопедиясе, 2012, б. 241]. Тамашачы Г. Камалованың водевиль һәм комедияләрендә уйнавыннан ләззәт ала. Актриса үзе иҗат иткән образларның көлкеле гамәлләре артында рәхимсез тормыш хакыйкате, социаль-иҗтимагый каршылыклар кискенлеге хөкем сөрүен яхшы тоя һәм шуны киң җәмәгатьчелек игътибарына үтемле итеп җиткерә белә. Аңарда юмор хисе, шуклыкшаянлык, тормышчан оптимизм ташып тора. Ул сәхнәгә чыгып, авызын ачуга, тамашачы ирексездән елмая башлый, спектакль дәвамында рәхәтләнеп көлеп утыра, спектакль ахырында инде, аның актёрлык осталыгына мөкиббән китеп, тыела алмыйча шаркылдап көлә. Х. Вахитның «Күк капусы ачылса» водевиле буенча куелган спектакль – актрисаның комедиячел талантын тулы яктырткан спектакльләрнең берсе. «Шампанский күбекләре сыман җиңел, якты юмор, бетмәстөкәнмәс фантазия, актёр табышлары, көлкеле детальләр белән тулып, ургылып-ташып торган музыка, җыр һәм бию номерлары, интермедияләр белән баетылган» [Галиәсгар Камал исемендәге.., 2009, 1 т., б. 328] «Күк капусы ачылса» спектакле беркемне дә битараф калдыра алмагандыр, мөгаен. Тамашачы Н. Әюпов башкаруында «акыл ягыннан бераз сайрак, ялкау, кеше исәбенә ашап-эчеп, сыйла-

нып яшәүдән дә тартынмый торган туймас тамак» [Галиәсгар Камал исемендәге.., 2009, 1 т., б. 329] Ризван һәм Г. Камалова башкарган Шәмсия күренешләрен «аеруча яратып кабул итә. Үзенчә хәйләкәр, очраган бер өйләнмәгән яшь егетне мәхәббәт ятьмәсенә эләктерергә әзер торучы, шактый олы яшьтәге кыз булса да, яшьләрчә киенүче, яшь күренергә тырышучы Шәмсия образы әле моңа кадәр күбрәк драматик рольләр башкарган Г. Камалованың чын комедия остасы икәнен раслады, спектакльнең иҗади ачышы булды» [Галиәсгар Камал исемендәге.., 2009, 1 т., б. 329], – дип яза Г. Арсланов. Гаилә тормышына җиңел карашлы азгын Шәмсия образы Г. Камалова уенында бөтен нечкәлекләре белән фаш ителә. Актриса башкарган комедия рольләре галереясында аеруча истә кала торганы – Н. Исәнбәтнең халык авыз иҗатына нигезләнеп язылган «Хуҗа Насретдин» пьесасы буенча куелган спектакльдә Гөлбану образы. «Сугыш алды елларының тормыш-көнкүреш драмалары фонында якты комедия чаткылары сирпеп, халыкка даны таралган акыл иясе Хуҗа Насретдин турындагы дәртле-күңелле спектакль сәхнәгә менә» [Галиәсгар Камал исемендәге.., 2009, 1 т., б. 225], – дип яза театр белгече И. Илялова. Галимә ассызыклап үткәнчә, «пьеса да, спектакль дә ханнар һәм байларның мәкереннән, хәйләкәрлегеннән өстен торган халык зиһененең югарылыгын алга сөрә, гади халыкның әхлакый җиңүе фикерен күтәреп чыга» [Галиәсгар Камал исемендәге.., 2009, 1 т., б. 225], актёрлар коллективы тарафыннан иҗат ителгән характерларның тормышчан булуы шуны раслый. Спектакльдә Хуҗаның йомшак күңелле, ярата белүче, шул ук вакытта үзенчәлекле характерга ия хатыны Гөлбану-Камалова зирәк, шат күңелле, нурлы йөзле Хуҗа Насретдинне тулыландырып тора. «Татар әдәбиятының йөзек кашы, татар драматургиясенең алтын фондында лаеклы урын алган сәхнә әсәрләре иҗат итеп, тәнкыйди реализм әдәбиятының югары баскычта булуын раслаган бөек әдип» [Каюмова, Бадрутдинова, 2019, с. 30], татар драматургиясе классигы Г. Камалның XX гасыр башы татар сәүдәгәрләренең комсызлыгын, затсыз сыйфатларын, ятышсыз гамәлләрен кыю фаш иткән «Банкрот» комедиясе буенча куелган спектакльдә Г. Камалова бай хатыннарын алдап, им-том белән шөгыльләнеп йөрүче оятсыз Нәгыймә карчык образын зур осталык белән гәүдәләндерә. Социаль баскычның югарысында торучыларның череп таркалуы кебек «яман чир»нең йогышлы булуын әлеге персонажның сөйләгән сүзләре, кылган гамәлләре аркылы яхшы тоемларга мөмкин. «Капиталистик җәмгыять шартларының кеше шәхесенә тәэсирен үзе күргән, шул шартлар авырлыгын үз җилкәсендә татыган художник» [Әхмәдуллин, 2003, б. 122], аеруча комедия жанрында зур идея-эстетик ачышлар ясаган К. Тинчуринның революциягә кадәрге пьесалары арасында үзенең сәнгатьчә камил эшләнеше белән аерылып торган, «татар мещаннарының тормышын гаять үткен буяуларда үзенчәлекле образлар, кызыклы ситуация ярдәмендә фаш иткән» [Каюмова, 2014, б. 438] «Назлы кияү» комедиясе буенча сәхнә күргән спектакльдә

Г. Камалова «назлы егет» Рәшиткә матди җирлеге нык булган бай хатын эзләүдә зур активлык күрсәткән, бердәнбер улын «бәхетле» итү теләгендә урыны-урыны белән хәтта чама хисен югалткалап та җибәргән Гөлбану ролен, образга кереп, оста итеп башкара. Аның һәр сүзе, һәр хәрәкәте тамашачыда тыелгысыз көлү хисе уята. Ә. Гобәйдуллина фикеренчә, ургылып торган юмор, комизм бу актриса уенының аңа гына хас, һичкем кабатлый алмас иҗат йөзен билгеләүче талант күрсәткече була [Губайдуллина, эл. ресурс]. Сәхнәдәш дуслары раслап үткәнчә, Г. Камалова хәтердә калырлык сокландыргыч, мул бизәкле сәхнә остасы гына түгел, чын кеше, тугры дус та була белгән. «Бөтен нәрсәдә ихлас иде. Ихлас ярата, ихлас тузына, нәфрәтләнә... Гәүһәр апаны сәхнә яшәтә, яшәртә иде. Ә утырып торганда... бу зур гәүдәсе белән сәхнәгә чыгар да, селкенә дә алмас кебек тоела иде. Ләкин сәхнәдә башын гына күрсәтүе була («Татар хатыны ниләр күрми»), могҗиза туа иде. Әйтерсең лә аның тулы гәүдәсе үзеннән-үзе күтәрелә, җиңеләя, күзләреннән очкыннар оча. Сәхнә аның гәүдәсе белән генә түгел, энергиясе, аурасы, рухы, җаны белән тула иде» [Хәйруллина, 2003, б. 68], – дип искә ала аны сагынып, хезмәттәше актриса Ф. Хәйруллина.

Г. Камалова 1990 елның 6 апрелендә вафат була. Киң диапазонлы актриса, үзенең сәхнә тормышында психологизм белән сугарылган тирән мәгънәле, һәркайсы күңел җылысы белән өретелгән үзенчәлекле характерлар иҗат итеп, татар сәхнә сәнгатен истә калырлык якты образлар белән баета.

**Әдәбият**

*Арсланов М.Г.* Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. Казан: «Заман» нәшр., 2014. 584 б.

*Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: история и проблемы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 511 с.

*Әхмәдуллин А.* Кәрим Тинчурин стиле // Кәрим Тинчурин: Истәлекләр, шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 122–123.

*Әхмәдуллин А.Г.* Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе: Монография. Казан: Мәгариф, 2007. 223 б.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Йөз ел. 2 томда. Спектакльләр / авт.-төз.: Л. Шакирҗан, Г. Гыйматова. Казан: Заман – Татар. кит. нәшр., 2009. 1 т. 568 б. = Татарский государственный академический театр имени Галиасгара Камала. Сто лет. В 2-х томах. Спектакли / авт.-сост.: Л. Шакирзян, Г. Гиматова. Казань: Заман – Татар. кн. изд-во., 2009. Т. 1. 568 с.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Йөз ел. 2 томда / авт.-төз.: Л. Шакирҗан, Г. Гыйматова. Казан: Заман – Татар. кит. нәшр., 2009. 2 т. 368 б. = Татарский государственный академический театр имени Галиасгара Камала. Сто лет. В 2-х томах / авт.-сост.: Л. Шакирзян, Г. Гиматова. Казань: Заман–Татар. кн. изд-во., 2009. Т. 2. 368 с.

*Губайдуллина А.* Гаухар Камалова. [Электронный ресурс]. URL: https://www.kino-teatr.ru/teatr/acter/sov/345017/bio/ (дата обращения: 7.06.2022).

*Иделле Г.* Иҗади уңыш // Совет Татарстаны. 1960. 24 январь.

*Илялова И.И.* Актерское искусство современного татарского театра. Казань: Татар. кн. изд-во, 1978. 143 с.

*Илялова И.* Г. Камал театры артистлары: Биогр. белешмәлек = Артисты театра им. Г. Камала: Биогр. справочник. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 334 б.

*Каюмова Г.И.* Кәрим Тинчуринның «Назлы кияү», «Сакла, шартламасын!..» комедияләрендә конфликт һәм характерлар гәүдәләнеше // История России и Татарстана: Итоги и перспективы энциклопедических исследований: сборник статей итоговой научно-практической конференции научных сотрудников Института Татарской энциклопедии АН РТ (г. Казань, 25–26 июня 2014 г.) / Ин-т Татар. энциклопедии АН РТ. Казань: «Фолиант», 2014. Вып. 6. Б. 436–451.

*Каюмова Г.И., Бадрутдинова Ф.Р.* Галиәсгар Камал һәм Камаллар династиясе «Татар энциклопедиясе» битләрендә (Г. Камалның тууына 140 ел тулу уңаеннан) // История России и Татарстана: Итоги и перспективы энциклопедических исследований: Сборник статей итоговой научной конференции научных сотрудников Института татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ (г. Казань, 29 мая 2019 г.). Казань, 2019. Вып. 11. Б. 29–37.

*Кашшаф Г.* Яңалык нәрсәдә? // Совет әдәбияты. 1960. № 3. Б. 98–105.

*Кашшаф Г.* Кыргыйлык һәм күңел нәфислеге // Күңел көзгесе: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 82–90.

*Мөсәгыйть Ф.* Матур яшьлек турында // Совет Татарстаны. 1960. 2 июль.

Татар совет театры (очерклар) / редколлегия: Б. Гыйззәт, И. Илялова, Һ. Мәхмүтов, А. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 495 б. (ил. белән 528 б.).

Татар энциклопедиясе: 6 томда / баш мөх. Ә.М. Мазһаров, җаваплы мөх. Г.С. Сабирҗанов. Казан: «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-ты» дәүләт учреж-се, 2012. 3 т.: К–Л. 716 б.

*Хәйруллина Фирдәвес*. Юксыну. Казан: «Ак барс» нәшр., 2003. 84 б.

***Каюмова Гөлия Илдус кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Татар энциклопедиясе*
*һәм төбәкне өйрәнү институты Энциклопедистика үзәгенең*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82.0

***Ф.Х. Миңнуллина***

# ОЛЫ ГАЛИМ, МИЛЛӘТПӘРВӘР ШӘХЕС
## *(Н. Ханзафаровның 85 яшьлек юбилее уңаеннан)*

В статье рассматривается научная и общественная деятельность доктора филологических наук Н. Ханзафарова. Ученый написал труды по истории татар, драматургии, комедиографии, также является автором многочисленных статей по творчеству татарских деятелей искусства, по современным проблемам татарской драматургии.

**Ключевые слова:** ученый, драматургия, татарская драматургия, Н. Ханзафаров, театр, история, символ.

The article examines the scientific and social activities of the Doctor of Philology N. Khanzafarov. The scientist is the author of numerous works on the history of the Tatars, drama, comedy. N. Khanzafarov is also the author of numerous articles on the work of Tatar artists, modern problems of Tatar drama.

**Keywords:** scientist, drama, theater, history, symbol.

Гомерен татар әдәбият белеме фәненә багышлаган галим, Татарстан Дәүләт гербы идеясе авторы, Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты, филология фәннәре докторы Назыйм Габдрахман улы Ханзафаров исеме киң җәмәгатьчелеккә яхшы таныш.

Назыйм Габдрахман улы Ханзафаров 1937 елның 12 сентябрендә хәзерге Яшел Үзән районының Олы Кайбыч авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, 1954 елда Казандагы 8 номерлы техник училищега укырга керә. Аны 1955 елда бетерә һәм Биектау районының Бөреле МТСында радиотехник булып эшли. 1956–1958 елларда армия хезмәтендә була. Аннан кайткач, Олы Кайбычта Культура йорты директоры булып эшли. 1965 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый һәм Яшел Үзән шәһәренең «Родина» Культура сараенда эшли. Татар әдәбияты белән кызыксыну аны Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына алып килә [Вәлиев, 2005, б. 340]. Ул 1975 елда Азат Әхмәдуллин җитәкчелегендә татар әдәбияты белгечлеге буенча филология фәннәре кандидаты, («Нәкый Исәнбәт драматургиясе»), 1996 елда филология фәннәре докторы дәрәҗәсенә («Татарская комедия (истоки и развитие)») ирешә. Берничә юнәлештә эшчәнлек алып барган галим – «Нәкый Исәнбәт драматургиясе (жанр, конфликт һәм герой проблемалары)» (1982), «Татарская комедия (истоки и развитие)» (1996), Казандагы Сөембикә манарасы һәм Болгардагы Кара Пулатны өйрәнүгә, Татарстан гербы өстендә эшләү тарихына багышланган «Символы Татарстана: мифы и реальность» (2001) дигән монографияләрнең авторы. Бу хезмәтләр фәннең төрле тармакларына таянып башкарылган. Биредә ул тарихчы, археолог, фольклорчы буларак та

ачыла. Әйтергә кирәк, ул – тирән белемле галим, тынгысыз җәмәгать эшлеклесе, эзләнүчән, һәр мәсьәләгә аек акыл һәм, эшнең кирәклеген аңлап, халык мәнфәгатен күздә тотып эш итүче шәхес. «Назыйм Ханзафаров – Татарстан мөстәкыйльлеген яклау комиссиясенең Координация шурасы әгъзасы да. 1990 елның 25 ноябрендә Казанның Актёрлар йортында Татарстанның суверенитетын яклау комитетының оештыру корылтае булып узды. Аны оештыручыларның берсе Назыйм әфәнде иде» [Әмирхан, 1997]. Моннан берничә еллар элек татар халкы билгеле бер алгарыш кичергән, әдәбият, коммунистик идеология кысуларыннан арынып, үзенең асылын ачу мөмкинлеге туган дәвердә дә гаять әһәмиятле мәсьәләләр аның тарафыннан эзләнү объекты буларак алына: Ш. Мәрҗани җәмгыяте эшчәнлегендә зур эш башкара, татар гимназияләрен ачып йөрүчеләрнең алгы сафында була. Ш. Мәрҗани җәмгыятенең мәгариф комиссиясе рәисе буларак гимназияләр ачу, аларга җитәкчеләр билгеләү, тәҗрибәле укытучылар табу буенча эш алып бара, җыелышларда чыгышлар ясый, матбугат битләрендә мәкаләләр бастыра. 1990 елда «Социалистик Татарстан» газетасында басылган «Милли мәктәп – милләтнең киләчәге» дигән мәкаләсендә, мәсәлән, ул хаклы рәвештә, «милли мәктәп яңармый торып, милләтнең яңарышын өмет итеп булмый» [Ханзафаров, 1990], – дип язып чыга.

Әйтергә кирәк, Назыйм аганың кызыксыну объектлары күптөрле. Фәнни эшчәнлеге татар әдәбиятын өйрәнүгә юнәлдерелгән булса да, аның белән генә чикләнми. Аны милли бәйрәмнәребезнең сыйфаты, киләчәге, тарихи-архитектура һәйкәлләребез, аларның тарихы да борчый. Халкыбызның тарихи мирасына таянып язылган «Сөембикә» либреттосы, Республикабызның символларыннан берсе – Дәүләт Гербы авторы булуы да шулар җәһәтеннән. Назыйм ага – башка төр кызыклы темаларга да әледән-әле мөрәҗәгать итүче тикшеренүчеләребезнең берсе. Бу уңайдан аның 1990 елда «Идел» журналында басылган «Алланың кашка тәкәсе» исемле мәкаләсе дә игътибарга лаек. Биредә сүз, төрки халыкларның мәҗүсилек заманнарыннан килгән традиция буенча, татарларда тәкәнең борын-борыннан нигъмәт алласы булып саналуы, аның төрле хәвеф-хәтәрләрдән саклау символына ия мал булуына да күпсанлы дәлилләр китерелә. Аның «“Елантау”: уйдырма һәм чынбарлык» [Ханзафаров, 1993, б. 53–55] дип исемләнгән язмасы да кызыклы. Галим биредә «Зилант»ның зур тарихын күзәтә һәм бу атаманың килеп чыгышын, үзгәрешләрен аңлата, үзенчәлекле фаразлар китерә. «Йолдызлар иле вә Сөембикә манарасы» дип аталган язмасында исә ул әлеге тарихи һәйкәлнең серләрен ача. Р. Әмирханов сүзләре белән әйткәндә, автор милли мирасыбыз иминлеген ныгыту өчен киләчәк буынга мөһим һәм «таушалмаган» фәнни дәлилләр бирә [Әмирхан, 1997]. Билгеле булганча, Татарстан Республикасының дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларация игълан ителгәч, аның Дәүләтчелек символларын булдыру мәсьәләсе алга килеп баса. Герб мәсьәләсен хәл итү өчен үткәрелгән конкурска

кергән 55 проект арасыннан Н. Ханзафаров идеясенә нигезләнгәне сайлап алына, уртасына канатлы барс урнаштырылган герб Татарстан Югары Советында кабул ителә. «Символы Татарстана: мифы и реальность» (2001) хезмәтендә «Сөембикә манарасының» символикасын, идеясен, мәгънәсен бәян итә, тарихын безнең эрага кадәрге борынгы чорлар белән тыгыз бәйләп күрсәтә.

Озак еллар буе ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләгән галимнең фундаменталь хезмәт – «Татар әдәбияты тарихы»ның алты томлыгы дөньяга чыгуда да роле зур була. Әлеге хезмәттә ул автор, җаваплы редактор урынбасары, редколлегия әгъзасы буларак актив катнаша. Төрле томнарында урын алган М. Фәйзи, Н. Исәнбәт, Т. Гыйззәт, К. Тинчурин иҗатларын яктырткан мәкаләләре аны, совет чорында язылуларына карамастан, шул катлаулы елларда әдәби процессны җентекләп тикшерә белүче әдәбият галиме итеп таныта. М. Җәлил, Г. Камал, Ф. Бурнаш кебек классикларыбызның күптомлыкларын бастырып чыгаруда да ул чиксез хезмәт куя. «Шушы елларда Назыйм Ханзафаров институтның әдәбиятчылары алдында торган гыйльми планнарны да тормышка ашыруга кереште. Татар драматургиясе тарихын җентекләп тикшерү белән бергә аңа текстологик эшләр дә йөкләнде. Мәсәлән, М. Җәлилнең тууына 70 ел тулу уңае белән ул каһарман шагыйрьнең 4 томлы “ Әсәрләр”енең 2 нче һәм 4 нче томнарын матбугатка әзерләү эшен башкарды. Шагыйрьнең васыяте буенча, аның иң якын дусты Г. Кашшаф бу басманы гамәлгә куючы итеп күрсәтелергә тиеш иде, чынлыкта исә томнарны Н. Ханзафаров белән Ф. Ибраһимова төзеде. Билгеле инде, 50 нче елларда М. Җәлилнең 3 томлыгын төзегәндә, Г. Кашшаф туплаган тәҗрибә дә игътибардан читтә калмады. 70 нче елларда Н. Ханзафаров шулай ук Г. Камал “ Әсәрләр”енең 2 томын матбугатка әзерләде (2010 елда Татарстан китап нәшриятында әлеге “ Әсәрләр”нең төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басмасы да нәшер ителде)», – дип яза бу хакта озак еллар буе Н. Ханзафаров белән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында бергә хезмәттәшлек иткән әдәбият галиме З. Рәмиев [Рәмиев, 1997]. Тагын шуны да искәртү мөһим, 1988 елда дөнья күргән «Октябрьгә кадәрге татар театры» китабы да (төп авторы Һ. Мәхмүтов) Н. Ханзафаровның каләме аркылы үтеп, тиешле фәнни калыпка кертелә. Әлеге монографик тикшеренү театр тарихындагы күп кенә ак тапларны бетерү, гаделлекне торгызу, Г. Исхакый мирасына объектив бәя бирү кебек мөһим казанышлары белән игътибарны җәлеп итә.

Н. Ханзафаровның әдәбият белеме өлкәсендәге иң зур табыш-ачышлары татар драматургиясе, театр сәнгате тарихы белән бәйле. Аның нәтиҗәләре дистәдән артык мәкаләдә, «Нәкый Исәнбәт драматургиясе», «Татарская комедия (истоки и развитие)» дигән монографияләрендә чагылыш таба. Назыйм ага Ханзафаров драматургия тарихын өйрәнеп, XX гасыр башы һәм 1920–1960 еллар сәхнә әдәбиятының үсеш тенденцияләренә, жанр һәм жанр

формалары системасы формалашуга җентекле бәя бирә. «Татар әдәбияты тарихы»ның 4–6 нчы томнарындагы драматургиягә бәйле бүлекләрдә, шулай ук газета-журналлардагы дистәләгән мәкаләләрендә әлеге төрнең мәйданга килгәннән алып бүгенге көнгә кадәрге үсеш-үзгәреш тенденцияләре, традиция-яңачалыклар, классик һәм бүгенге көн авторларының табышлары һ.б. җентекле һәм фәнни нигезгә салып тикшерелә. М. Фәйзи, Н. Исәнбәт, Т. Гыйззәт, Г. Камал, К. Тинчурин, Н. Исәнбәт кебек драматурглар иҗатын, әдәби-эстетик эзләнүләрен, стиль үзенчәлекләрен иҗтимагый-сәяси тормыш һәм рус, дөнья әдәбияты казанышлары белән бәйли. Мәсәлән, Н. Ханзафаровның «Нәкый Исәнбәт драматургиясе» дип аталган китабында Н. Исәнбәт иҗатының үсеш баскычлары билгеләнә, пьесаларының жанр үзенчәлекләре ачыклана. Әйтергә кирәк, бу хезмәт күренекле драматург һәм галим турында беренче монографик хезмәт булды. Беренче бүлектә Н. Исәнбәтнең драматургиягә килү юлына күзәтү ясап, Н. Ханзафаров киң укучылар даирәсенә билгеле булмаган, Н. Исәнбәт белән шәхси сөйләшүләрдән алынган материалларны да китерә. Язучының беренче чор иҗатында мәгърифәтчелек позициясендә торуына басым ясый, драма әсәрләренә анализ бирү белән генә чикләнмичә, аның поэзия өлкәсендәге эшчәнлегенә дә игътибар итә. Н. Исәнбәт драмалары идея-тематик яктан үзара тыгыз бәйләнештә булуын, аларны ватанчылык, азатлык, батырлык, дуслык, саф мәхәббәт, аң-белемгә, яктыга, азатлыкка омтылу фикерләре берләштерүен билгели.

«Татарская комедия» хезмәтендә инде автор комедия жанрының килеп чыгышын борынгы заманнарда барлыкка килгән карнаваллар, йола тамашалары, цирк кәмитләре һ.б. белән аңлата. Галим раславынча, татар комедиясе үсешенә, аның төрле жанр төсмерләре барлыкка килүдә Европа, рус һәм төрек драматургиясе көчле тәэсир ясый. Р. Ганиева билгеләгәнчә, «гомумән алганда, Европа комедиографиясе традицияләренең татар драматургиясенә ике юнәлеш – рус әдәбияты һәм француз драматургиясенең көчле тәэсирен татыган төрек әдәбияты аша үтеп керүе хезмәттә ышандырырлык дәлилләнгән» [Ганиева, 1997]. Әлбәттә, татар халкының көлү сәнгате, комедия жанрының тарихы турында язу җиңел эш түгел. Ул бөтендөнья драматургиясен, теориясен яхшы белүне таләп итә. Назыйм аганың хезмәтен укып чыкканнан соң, татар комедиографиясенең тарихы бай, уңышлары зур булуына инанасың. XX гасырның әдәби-эстетик хәрәкәте катлаулы, каршылыклы булуга карамастан, татар комедиясендә гомумкешелек идеалларының күтәрелүе, сәнгатьчә милли йөзен саклап калуы автор тарафыннан конкрет мисаллар белән дәлилләп барыла. Ул, татар комедиясенең торышын бәяләү белән бергә, аның нинди юнәлештә үсүен, үзгәрешен күрсәтеп бара. Георгий Ломидзе да хезмәтне югары бәяләп: «Бу китап – йомгак, мәгълүм дәрәҗәдә киләчәк эшләрнең перспектив юлы. Ул бай материалы белән дә, үткен фикерле нәтиҗәләре белән дә игътибарны җәлеп итә.

Үлчәп, уйлап, акыл белән язылган» [Ломидзе, 1997]. Мордва дәүләт университеты галиме Е.Чернов әлеге китапның «Күпмилләтле әдәбият белеме фәне өчен дә зур әһәмияткә ия» булуын искәртә. Башкортстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы Р. Баимов та: «Н. Ханзафаровның фәнни эзләнүләре дөньяны һәм мәдәни кыйммәтләрне заманча күрә белү белән аерылып тора, хезмәтнең концепцияләре актуаль. Әһәмияте татар әдәбияты белән генә чикләнми, ә гомум мәнфәгать киңлекләренә чыга», дип яза [Баимов, 1997]. Гомумән, әлеге хезмәт фәнни-теоретик һәм фактик чыганакларның байлыгы, әдәби материалны, төрле чорларны киң планда һәм тирәнлектә иңләп алуы белән аерылып тора. «Татар сәхнә сәнгате тамырлары чыганаклары» исемле язмасында да галим татар халкының сәхнә әдәбияты, күп гасырларны иңләгән милли-мәдәни байлыкның бер өлеше буларак, үзенең тамырлары белән тирән тарих катламнарына барып тоташуын билгели. Сәхнә әдәбияты формалашуда татар фольклоры һәм әдәби мирасындагы театраль-драматик күренешләрнең әһәмияте зур булуын, бу тамырлар уртак төрки һәм гарәп-фарсы мәдәнияте белән тарихи бәйләнешле булуын бәян итә. Мәсәлән, мәсәл һәм драматик уеннарда борынгы халык театрларының репертуарын нәкъ менә шушы жанр әсәрләре тәшкил итүе дәлилләнә. Урта гасыр язма әсәрләренең исә XX гасыр башы татар драматургиясе белән җитди бәйләнешен конкрет мисаллар белән раслап бара. Мәсәлән, Г. Камал пьесаларында гаять оста сурәтләнгән яучы карчык образлары «Кыйсасел-әнбия» (Рабгузи), «Мәҗмугыл-хикәят», «Бәхтиярнамә», «Тутыйнамә» һ.б. әсәрләрдә традицион персонажлар буларак сурәтләнәләр, ди галим.

Галим бүгенге көн татар сәхнә әсәрләрен дә күзәтеп, бәя биреп бара. «Яңа гасыр татар драматургиясе», «Драмаларда күңел дөньябыз. (Туфан Миңнуллин драматургиясенә бер караш)», «“Идегәй” фаҗигасы хакында», «Без сугышта...» һәм башка мәкаләләре шундыйлардан. Алар XX–XXI гасыр башы татар сәхнә әдәбияты үзенчәлекләрен, бүгенге көн драматургларының әдәби-эстетик эзләнүләрен күзалларга ярдәм итә. Мәсәлән, «Драмаларда күңел дөньябыз (Туфан Миңнуллин драматургиясенә бер караш)» язмасында ул, Т. Миңнуллинның «Эзләдем, бәгърем, сине», «Саташу» исемле сәхнә әсәрләрен бәяләп, язучының хәзерге драмаларында шәхеснең күңел дөньясы бөтен нечкәлекләре һәм каршылыклары белән чагылыш табуын билгели. Гасыр ахырында язылган пьесаларында кешеләрнең язмышы, эчке дөньялары беренче планга чыгуын дәлилли. Бу яктан 2001 елда Г. Камал театрында күренекле режиссер Р. Исрафилов тарафыннан уңышлы куелган «Эзләдем, бәгърем, сине» мелодрамасы аерылып тора, ди галим. «Без сугышта» мәкаләсендә З. Хәкимнең пьесалар конкурсында (2003) беренче урын алган «Телсез Күке» драмасы – язучының аңа кадәр язган әсәрләренең фәлсәфи һәм сәнгати «каймагы» булып торуы ассызыклана. Биредә документаль җирлектә чагылыш тапкан гаять киң, җитди, яңа проблемалар урын ала. Язучы илләр,

халыклар, тарихлар, буыннар, заманнар, кешелек яшәеше хакында ачынып уйлана, хайвани сыйфатларны, золымны кире кага дигән нәтиҗәгә килә.

Фәнни редактор буларак, Н. Ханзафаров озак еллар дәвамында «Яңа татар пьесасы» конкурсында җиңгән әсәрләрне китап итеп әзерләүдә дә җиң сызганып эшли. Әлеге җыентыкта урын алган аерым бер пьесаларга анализ ясап, мәкаләләрен матбугат битләрендә бастыра. Алар XX–XXI гасыр башы татар сәхнә әдәбияты үзенчәлекләрен, төрле чорларда яшәгән драматургларның әдәби-эстетик эзләнүләрен күзалларга ярдәм итә. Гомумән, драматургия һәм театр сәнгатенә караган мәкаләләр циклында Н. Ханзафаров – заман үзгәрешләрен тоемлаучы, драматургия тарихына бәйле казанышларны күрсәтүче галим.

Мәкалә ярты гасырдан артык гомерен татар гуманитар фәне өлкәсенә багышлаган, үзенең белемен, акылын, көчен халкына хезмәткә юнәлткән, зур ихтыяр көченә ия Н. Ханзафаровның 85 яшьлек юбилее уңаеннан язылды. Ул матур планнар, изге омтылышлар белән яши. Ходай Тәгалә аңа саулык, җан тынычлыгы, иҗат уңышлары юлдаш итсен.

**Әдәбият**

*Әмирхан Р.* Батыр Габдрахман улы // Шәһри Казан. 1997. 3 октябрь.

*Баимов Р.* О татарской комедии с надеждой и любовью // Казанские ведомости. 1997. 6 августа.

*Вәлиев Н.* Назыйм Ханзафаров // Әдәби Алабуга. 2005. Б. 340–344.

*Ганиева Р.* Татар комедиясе // Ватаным Татарстан. 1996. 11 июль.

*Ломидзе Г.* О татарской комедии с надеждой и любовью // Казанские ведомости. 1997. 6 августа.

*Рәмиев З.* Олы Кайбычта – үз урамы, фәндә – үз юнәлеше // Мәдәни җомга. 2012. 12 октябрь.

*Ханзафаров Н.* Милли мәктәп – милләтнең киләчәге // Социалистик Татарстан. 1990. 29 ноябрь.

*Ханзафаров Н.* Елантау: уйдырма һәм чынбарлык // Идел. 1993. №. 7. Б. 53–55.

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

## ТАТАР МИФОЛОГИЯСЕ ҺӘМ ДӨНЬЯ

**(Татар халык иҗаты: 25 томда. 1 т. : Мифология ([төз., иск. һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт. Л.Х. Дәүләтшина] Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. 511 б.) китабына рецензия)**

Татар халык рухи иҗатын академик дәрәҗәдә барлау, гыйльми яктан җентекләп, масштаблы һәм системалы өйрәнү – татар фольклористикасының XXI гасырда торышының бик тә сыйфатлы, актуаль билгеләре. 25 томнан торган «Татар халык иҗаты» басмасын башлап ачучы беренче том – «Мифология» томы шушы югарылык һәм тирәнлекнең дәлиле. Беренчедән, иң борынгы иҗат төре һәм дөньяны танып белү, үзләштерү, мәдәниләштерүнең архаик ысулы буларак мифик иҗат – һәр милләтнең үзаңы, этник, милли үзлегенең (идентификациясенең) иң ачык өлгесе. Икенчедән, томда борынгы язмалар, татар фәнендә XVIII гасырда ук теркәлгән текстлар белән беррәттән, хәзерге дәвер халык хәтереннән язылып алынган мифлар да урын алган. Бу ике факт мәгәр кешелек үзаңы экологиясенең торышын, милли иҗади көчен һәм милләтнең Вакыт, Аралык, Урын даирәләрендә традицион урынын ачарга зур мөмкинлек бирә. Чөнки кеше һәм кешелекнең мифологик күзаллавына, ачык иҗат тотрыклылыгына рухи, тарихи, экологик аң дәрәҗәсе зур йогынты ясый.

Миф һәм мифологик иҗат – ул архаик дәвер кешесенең генә карашы түгел. Дөньяны метафорик, мифологик күзаллау XXI гасырда да дәвам итә, әмма образлар, персонажлар, табигать, җиһан исемнәренең бирелеше генә заманга ярашлы үзгәрә. Мәсәлән, урамда мөгезле машина – аңа бассаң, су килә *(колонка);* зәңгәр күзле дүрткел башлы шайтан *(телевизор);* кулыңда кеше тавышы килә *(кесә телефоны)* һ.б. Шушы уңайдан мифология классигы А. Лосев сүзләре актуаль һәм тирән гыйльми сизгерлек белән әйтелгән: «Миф есть наивысшая по своей конкретности максимально интенсивная в величайшей мере напряженная реальность, это не выдуманная, но наиболее яркая и самая подлинная действительность. Это совершенно необходимая категория мысли и жизни, далекая от всякой случайности и произвола» [Лосев, с. 33].

Милләтнең генетик хәтер тирәнлеге, иҗади комары һәм дөньяны хикмәтле образда күзаллап тәэсир итүе – миф тудыруы – милләтнең югарылыгы, олы булмышы ул. Милләтнең теле, мәдәнилек көче һәм бәхетле киләчәкле, югары репутацияле булу билгесе аның миф иҗат итүенә бәйле.

25 томлык «Татар халык иҗаты»ның «Мифология» китабы әнә шундый масштаблы принципларны алга чыгара. Соңгы елларда язып алынган экспедиция материаллары татар халкының миф иҗат итүен дәвам иткәнен күрсәтә. Шул ук вакытта Г. Ибраһимов исемендәге Тел,

әдәбият һәм сәнгать институты архивында дистә еллар дәвамында тупланып килгән мирасны барлау исә татарның милли үзаңының, мифик аңының үсешен дә, заманча трансформация үзенчәлекләрен дә чагылдыра.

Гомумән, 25 томлыкның стратегик максатына – «халыкның рухи байлыгын үзенә кайтару, аны популярлаштыру, тарихка кертеп калдыру, фольклордагы күпгасырлык табышларны бербөтен итеп күзаллап, күпъеллык фәнни-тикшеренү нәтиҗәләрен гомумиләштерү»гә тулысынча ирешелгән [Татар халык иҗаты, 2021, б. 6].

Мифологиягә караган мирасны томда бирү тәртибе, классификацияләү, идея, тематик юнәлеш һәм эчтәлекләре буенча төркемләү, һәммәсенең мәгънә-фикер, асылын барлау уңышлы башкарылган. XXI гасыр фольклористикасы, мәдәни антропологиясе, социаль фольклористикасы кебек актуаль юнәлешләргә җавап бирә бу хезмәт. Академик томның кереш сүзе (авторы Ләйлә Хәсән кызы Дәүләтшина) – үзе фикер тирәнлеге, масштаблы һәм комплекслы булуы белән дә, анализлауның югары дәрәҗәсе белән дә бер зур мөстәкыйль гыйльми хезмәт.

Татарның бүгенге аңында урын алган бик борынгы алиһәләр (Тәңре, Жир-Су, Умай, Алас һ.б.), җен, албасты, өрәк, убыр, шүрәле һ.б. түбән рухларга бәйле мифологик карашларны да, югары рухларны да игътибар үзәгенә ала автор һәм алар «татар халкының мифологик системасын реконструкцияләү өчен кызыклы һәм файдалы чыганак ролен үтиләр» [Татар халык иҗаты, 2021, б. 12] дигән көнүзәк нәтиҗә ясала. Бу җәһәттән татар мифологиясе бик борынгы катлам – төрки мифология белән тамырдаш.

Кешелекнең архаик дәвердән башлангыч алган иҗади күзаллавын күзәткәндә, «милләт», «этник» дигән төшенчәләр белән эш итәргә ярамый. Шуңа күрә татар халкының мифологик истәлекләрен өйрәнгәндә, борынгы төрки мифологик мирасны гомумиләштереп туплап файдалану зарурлыгы [Татар халык иҗаты, 2021, б. 12] үзен гыйльми яктан аклый. Шуңа да төрки халыклардан башкорт, казакъ, кыргыз, үзбәк, каракалпак, алтай һ.б. халыклар мифологиясе фонында татар мифологиясен өйрәнү бу томда күпьяклы, максатлы башкарылган. Төрки-татар мифологиясе тарихын барлаганда Азия һуннары (хунн-хунну) һәм Европа һуннары (гуннар) мирасын кытай, грек, әрмән тарихына бәйләп тикшергән мәшһүр галимнәр – Н.Я. Бичурин, Н.В. Кюнер хезмәтләренә [Бичурин, 1952; Кюнер, 1961, с. 7–8] игътибар бирелә. Борынгы төркиләрнең мифологик карашлар системасының бербөтенлеген, төзеклеген өйрәнү өчен томны төзүче «Гун иленең» мифологик күзаллауларына бәйле хезмәтләрнең иң бае һәм тулысы – Мовсес Каганкатвациның «История агван» хезмәтенә [Каганкатваци, 1861] дә мөрәҗәгать итә. Дөнья фәнендә популяр хезмәтләр, Орхон-Енисей рун язмалары, VIII–X гасырларга караган «Ырг битиг» (Юрау китабы) китабындагы фольклор истәлекләре, мифологик сюжетлар, табигать, кеше, хайван һәм башка персонажларга бәй-

ле мәгълүматларның [Шәрипов, б. 62] урын алуы да китапны югары гыйльми сыйфатлы итә.

Татар фольклорын язып алу тарихына да игътибар итә Л.Х. Дәүләтшина. XVIII гасырдан башлап, Г.Б. Миллер, И.С. Паллас, И.И. Лепехин, И.П. Рычков, М.Д. Чулков хезмәтләреннән алынган мәгълүматлар томның нигезле өлешен тәшкил итә. Әйтергә кирәк, гыйльми эзләнүләр мәлендә яңа табышлар булу һәм аларны фәнни әйләнешкә кертү үзе бер олы гыйлем тармагына карый, аерым игътибарга бәягә лаек. Мәсәлән, Я.Д. Коблов хезмәтендә (1913) мифологик персонажлар өлеше шундый [Коблов, 1910]. Күренекле татар археографы С.Г. Вахиди җыйган мифологик легендалар да шушы томга кергән. Халык иҗаты буенча том төзү – ифрат катлаулы, җаваплы, зур тәҗрибә, күпьяклы белем таләп иткән, бәһалап бетергесез олы эш. Хәтта зур монографик хезмәт язуга караганда да ул үтә дә тирән, киң гыйлемлелек, эрудиция һәм гомумиләштерү куәсенә ия булуны таләп итә, шуңа өстәп, көчле логика, интуиция, олы ярату, егәрлелек кирәк.

Л.Х. Дәүләтшинаның колачлы эзләнүләре, татар фольклорына бәйле күп еллар буе язып алынган һәртөрле мәгълүмат туплавы (Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты, Башкорт дәүләт университеты, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге һәм башка бик күп экспедиция материаллары һ.б.), үзенең дә бу өлкәдә кыр тикшеренүләре алып баруы томның күпкырлы, фәнни нигезле хезмәт булуын күрсәтә.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан эшләнгән 12 томлык тупланманың бер өлешен генә мифология тәшкил итсә [Татар халык иҗаты, 1987], бу том исә тулысынча мифологиягә багышланган! Һәм шундый күләмлелек, күркәмлек һәм күптөрле темалы, эчтәлекле мифлардан фундаменталь том хасил булу – Россия, дөнья фәнендә бик зур гыйльми вакыйга, күренеш ул. Шул ук вакытта, җыелган жанр өлгеләрен системалы бирә белү, төзү гамәле, ирешкән нәтиҗәсе моңарчы булган тирән теоретик хезмәтләргә нигезләнүдән, аларга таянудан камил сыйфатлы булган. Шуңа күрә Л.Х. Дәүләтшина танылган галимнәр – Ф.И. Урманчеев, М.Х. Бакиров, Х.Ш. Мәхмүтов, Г.М. Дәүләтшин, Л.Ш. Җамалетдинов, А.Х. Садекова, Ф.З. Яхин, И.Г. Закирова, Л.М. Мөхәммәтҗанова хезмәтләренә таяна һәм шуңа да әлеге том – көчле фикерле, дәлилле, классификациясе ачык-төзек, материал бирү алымнары, концепциясе белән заман фольклористикасы таләпләренә бөтен яклап җавап бирә.

Россия фольклористикасы классиклары Л.Н. Виноградова, С.М. Толстая мифология материалларын барлаганда, мәдәни текстны реконструкцияләгәндә, һәртөрле персонажларның функциясе, текстларның лексикасы, хәтта образларга бәйле булмаган нәрсәләрнең дә исәпкә алынырга тиешлеген игътибар үзәгенә ала [Виноградова, Толстая]. Безнең хезмәтләрдә исә мифологиягә караган (текстлар) карашлар нигезендә – җиһанны, табигать-кеше мөнәсәбәтләрен камилләштерү иҗаты, хаостан космос хасил булу үзенчәлекләре ачылды.

Янә килеп, мифология үзенең яшәү формаларын XX–XXI гасырларда да борынгы бию, уен, им-томнарда, хәтта җырда дәвам итүе турында фикерләр әйтелде [Султангареева, с. 14–48, 170–179]. Анализланган «Мифология» томында шушы концепциялар аермачык күзәтелә. Мифик персонажларларның асылы, аларның кыяфәте, холык үзенчәлеге, функцияләре, шулай ук әлеге заман фольклор хәтерендә, төрле жанрларда (им-том, дәвалау, этикет-тәрбия һ.б.) чагылышы бербөтен буларак бирелә. Идея-тематик колач бу томда бик масштаблы – дөнья һәм төрки кабиләләр яратылышы, югары аллалар, рухлар, ияләр, табигать «хуҗалары» бирелеше һәм аларны күзаллау бер тәртиптә тәкъдим ителә. Әйләнә-тирәдәге төрле объект һәм күренешләрнең килеп чыгышы, беренче кешеләр һәм алып-пәһлеваннар үз урынын алдан ала. Түбән рухлар өлешенә шайтан, пәри, бичура, өрәк, убыр һ.б. керүе бөтен фольклористика таләпләренә җавап бирә. Ягъни информантның тел, сөйләш, диалекты саклана, аутентик рәвештә бирелеш төгәл үтәлә – шуның белән милләтнең генетик хәтеренә ачык дәлил күзаллана.

«Дәвалау һәм саклау магиясе», «Халык ышанулары» өлешләрендә мифологик белем, дөньяны күзаллау эзләре ачык чагылыш тапкан һәм татар халкының этномәдәни, этнопсихологик фикерен, дөньяны танып белүнең борынгы катламнарын иҗади чагылдыру осталыгына бигрәк тә ачык мисал булып тора. Кызыл балчыктан яратылган адәм, актан киенгән Хозыр килү, бүре токымыннан төркиләр башлану, йолдызларның адәм җанының чагылышы булуы, Тәңре һәм Тәңрегә корбан багышлау, күк күкрәткән Күк атасы, каган-ханнарның Тәңре билгеләвенчә сайлап алынган кешеләр булуы һ.б.– барысы да башкорт мифологиясендә дә типологик күренеш һәм шуның белән төрки тамырлы халыкларның тирән рухи тамырларына матур дәлил.

«Төньюкүк истәлеге», «Шаньюй урдасы тәртипләре», «Ашина ыруы», «Куар алласы», «Күк рухына багышлау», «Күлтәгин истәлеге» кебек борынгы төрки-монгол, кытай мифологиясенә караган мирасның татар телендә бирелүе хезмәтнең бәясен тагын да арттыра. Китапка кергән мифология истәлекләренә тирә-як ияләре, табигать хуҗалары, йорт ияләре, җен-пәри балалары һәм су иясе, ут иясе күренү, алар белән «мөгамәлә итү» ысуллары белән бирелгән комплексларның мифология яссылыгында каралуы да – бүгенге заман фольклористикасында актуаль күренеш. Хорафати хикәяләр дип йөртелгән иҗади текстларның, им-томда хәрәкәт иткән, багучылыкка бәйле ритмик такмакларның, яңгыр, кояш чакыруларның да метафорик асылында миф һәм бик борынгы реалийлар ята һәм алар томда урынлы рәвештә бирелә.

Әлеге көндә әтәч кычкырса – «җен-пәри югала», «җен алыштырган баланы җиргә бәрсәң – үлә, анан соң гына адәм баласы йортына кайта», «җенле урында ат пошкыра, бармый», «убыр утына – сүгенү кирәк» дигән мотивларга корылган текстларда исә мифлар зур урын били. Бүгенге фәндә мифны фольклордан чикләми карау өчен

бу принципны дәлилле дип саныйбыз. Гомумән, галимнәр өчен дә, киң катлау укучылар өчен дә, яшь балаларда җир-суга, табигатькә, туган телгә сөю тәрбияләү максатында да, мәгариф системасында куллану өчен дә ифрат матур, эчтәлекле, югары кимәлдә дөнья фәне таләпләренчә эшләнгән бу тупланма – бик кирәкле, көтеп алынган күренеш.

Татарның борынгы ышану, инануларына гына түгел, аның аңбелеме, иҗади, философик фикеренең тирән тамырлы феномен булуына багышланган бу хезмәт – системалы бирелеше, концептуальлеге, комплекслы булуы белән зур яңалык һәм фәндә, рухияттә, мәдәнияттә кирәкле, мәртәбәле күренеш. Кереш сүз фикерле, мәгълүматлы һәм төзек логикалы булуы белән үзе бер зур хезмәт һәм гаҗәеп бай мифологик хәзинәгә җавап бирә. Искәрмәләр һәм аңлатмалар өлеше, шартлы кыскартулар – гыйльми дәрәҗәдә тирән эшләнгән, анык, тулы мәгълүматлы башкарылган. Мондый систематик том – төрки гуманитар фәнендә зур, күренекле табыш.

**Әдәбият**


*Бичурин Н.Я.* (Иакинф) Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. М.-Л.: Изд-во АН СССР ИЭ им. Миклухо-Маклая, 1952. Т. I. 362 с.; Т. II. 335 с.

*Виноградова Л.Н. Толстая С.М.* К проблеме идентификации и сравнения персонажей славянской мифологии // Славянский и балканский фольклор. Верования. Текст. Ритуал.

*Каганкатваци М.* История агван: пер. с арм. СПб.: Тип. Акад. наук. 1861. 376 с.

*Коблов Я.Д.* Мифология казанских татар. Казань: Типо-лит. Имп. Ун-та, 1910. 49 с.

*Кюнер Н.В.* Китайские известия о народах Южной Сибири, Центральной Азии и Дальнего Востока. М.: Изд-во вост. лит-ры. 1961.

*Лосев А.Б.* Диалектика мифа. М. Академия наук, 2008. С. 33.

*Султангареева Р.А.* Башкирский фольклор: семантика, функции и традиции. Уфа: Башэнцикл. 1 т., 2018.

Татар халык иҗаты: 25 томда. 1 т.: Мифология / төз., иск. һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт. Л.Х. Дәүләтшина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. 511 б.

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / төз. С.М. Гыйләҗетдинов. Казан: Татар кит. нәшр. 1987.

*Шәрипов Ә.* Орхон-Енисей язмалары // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 1 т. Борынгы чор һәм Урта гасырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014.



***Солтангәрәева Розалия Әсфәндияр кызы,***

*филология фәннәре докторы, М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университеты Гыйльми тикшерену үзәге җитәкчесе*

**2022 елның 27 июненнән 8 июленә кадәр** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының комплекслы экспедициясе Пенза өлкәсендә эшләде. Унике көн дәвамында филология фәннәре кандидаты, фольклорчы галим И.И. Ямалтдинов җитәкчелегендәге экспедициядә филология фәннәре кандидаты, фольклорчы Р.Ф. Сафиуллина, филология фәннәре кандидаты, тел белгече Ә.К. Булатова, педагогика фәннәре кандидаты, музыка белгече Н.Х. Нургаянова, сәнгать белгече А.Ф. Борһанова, археограф Ф.Г. Фәйзуллина һәм эпиграфика белгече В.М. Усманов катнашты. Галимнәр төркеме татарлар күпләп яши торган унбиш торак пунктта (Каменка районының Кикин (Кикын), Тәләтен, Мачали, Кобылкин, Кочалейка (Ятмис), Белинский районының Кутеевка (Качкару), Пачелма районының Решетин, Татар Никольские, Вадинский районының Татар Шуриновкасы (Шуринка), Мучали, Татар Лакасы, Вадинск, Чудовка (Чудилка), Спасск районының Шалдавыч, Белоозерка авылларында) тикшеренүләр алып барды. Кыр тикшеренүләре барышында галимнәр тарафыннан татар халкының милли-мәдәни мирасы өйрәнелде, тел, фольклор, сәнгать, музыка, археография, эпиграфика, шулай ук традицион мәдәният буенча бай материал тупланды.

**2022 елның 2–12 июлендә** Троицк туган якны өйрәнү музее базасында «Тукай Троицкида» дип аталган Бөтенроссия арт-пленэры узды (проектның кураторы – сәнгать белеме үзәге мөдире, сәнгать фәннәре докторы Р.Р. Солтанова). ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Троицк шәһәре хакимияте, «Россия рәссамнар берлеге» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстандагы төбәк бүлеге, Татарстан рәссамнар берлеге һәм Сәнгать белгечләре ассоциациясенең Татарстан бүлекчәсе белән берлектә оештырылган бу чара бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның Троицк шәһәренә килүенә 110 ел тулуга багышланган иде. Проект кысаларында Троицк туган якны өйрәнү музеенда «Хәзерге заман сынлы сәнгатендә Габдулла Тукай топослары: традицияләр һәм новаторлык» дигән темага түгәрәк өстәл оештырылды. Чара кысасында 2021 елда Милләтләр эшләре буенча Федераль агентлыкның «Ключевое слово» конкурсында «Иң яхшы фәнни проект» номинациясендә лауреат дип табылган өч томлы «Габдулла Тукай: тормышы һәм иҗаты (Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗат хроникасы өчен материаллар)» басмасы тәкъдим ителде. Түгәрәк өстәл эшендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре (сәнгать фәннәре докторы Р.Р. Солтанова, филология фәннәре кандидатлары М.И. Ибраһимов, Л.Р. Надыршина), җирле тарихчылар (Р.Г. Гыйззәтуллин, И.Р. Әхмәдшин) катнашты.

**2022 елның 3–7 июлендә** Мәскәүдә кырыктан артык илдән килгән белгечләр катнашында Халыкара җирле халыклар телләре унъеллыгы һәм ЮНЕСКО-ның «Информация для всех» хөкүмәтара программасы кысаларында «Всемирная сокровищница

родных языков: оберегать и лелеять. Контекст, политика и практика сохранения языков коренных народов» темасына Халыкара фәннигамәли конференция узды. Чарада ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының фән буенча урынбасары, филология фәннәре кандидаты Олег Хисамов катнашты, ул «Россиядә күптеллелек: җирле халыклар телләрен яклау сәясәте һәм практикасы» дип аталган пленар утырыш кысаларында «Татарстан Республикасында күптеллелекне саклау һәм үстерү: контекст, сәясәт, практика» дигән темага доклад ясады.

**2022 елның 30 июленнән 2 августына кадәр** Казан шәһәрендә Бөтендөнья татар конгрессының VIII Съезды узды. Съезд эшендә Россия Федерациясенең 76 төбәгеннән, 35 якын һәм ерак чит илләрдән 1500 дән артык делегат һәм кунак катнашты. Быел VIII Съезд Бөтендөнья татар конгрессы оешуга 30 ел тулуга багышланган иде. Шул уңайдан Бөтендөнья татар конгрессы илнең 53 төбәгеннән котлау хатларын кабул итте. Оешманы 30 еллыгы белән Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин, Удмуртия, Дагстан республикалары, Саратов өлкәсе, Красноярск крае һәм башка төбәкләр җитәкчеләре, Мәскәү мэры Сергей Собянин котлады.

**2022 елның 1 августында** Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясенә гариза кампаниясе старт алды. Премия 2020 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән гамәлгә куелды һәм ике елга бер тапкыр тантаналы рәвештә Илһам Шакировның туган көнендә тапшырыла. Приз фонды 600 мең сум тәшкил итә. 200 мең сумлык өч премия ике вокалистка (иратка һәм хатын-кызга) һәм «Халык җырларын башкаручы» номинациясендә җиңүчегә тапшырылачак. Гаризалар кабул итү 2022 елның 15 ноябренә кадәр дәвам итәчәк.

**2022 елның 4 августында** «Стиль жизни – культурный код» дип аталган II Этно-fashion фестиваль кысаларында «Эпическая константа современной культуры: проблемы сохранения и популяризации национальных эпосов» дип аталган Халыкара конференция узды. Конференциянең төп оештыручысы Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге иде. Чараны оештыруда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Бөтендөнья татар конгрессы һ.б. оешмалар да актив катнашты.

Конференциягә Кыргыз Республикасыннан, Казакъстаннан, Азәрбайҗаннан, Россия төбәкләреннән белгечләр чакырылган иде. Чарада татар халкының рухи мирасын саклау мәсьәләләре турында сүз барды. Конференциядә ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Л.Х. Мөхәммәтҗанова, Р.Р. Солтанова, И.Г. Закирова, Л.Р. Петрова катнашты. Л.Х. Мөхәммәтҗанова «Татар эпосының төп үзенчәлеге» дигән темага доклад белән чыгыш ясады. Р.Р. Солтанованың «Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында “Идегәй” спектаклен кую

тарихыннан» дип аталган онлайн доклады сәнгать мәсьәләләренә багышланган иде. Халыкара конференция вакытлы матбугат вәкилләре һ.б. катнашында үтте.

**2022 елның 4 августында** Төркиянең «Һәҗә» нәшриятында (Әнкара) «Хәзерге заман татар хикәяләре антологиясе – XXI гасыр» китабы дөнья күрде. Җыентыкта утыз татар язучысының яңа гасырда иҗат ителгән хикәяләре урын алган. Антологиянең кереш сүз авторы – Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла. Хикәяләрне төрек теленә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Фатиһ Кутлу тәрҗемә иткән. Китап шушы көннәрдә Төркиядә сатуга чыкты. Тиздән әлеге антология, Татарстан Язучылар берлеге хозурындагы Әдәби тәрҗемә үзәге проекты буларак, Мәскәүдә рус телендә нәшер ителер дип көтелә.

**2022 елның 5 августында** «Пирамида» концертлар залында Татарстанда XXIV «Бәллүр каләм – 2021» журналистика һәм масса-медиа өлкәсендәге республика бәйгесе лауреатларын бүләкләделәр. Бүләкләүләр уннан артык номинациядә тормышка ашырылды. Гран-прига КФУның Милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире Васил Заһит улы Гарифуллин лаек булды.

**2022 елның 15 августында** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге мөдире Рауза Солтанова җитәкчелегендәге яшь тукучылар, Татарстан уку йортлары укытучыларыннан торган бер төркем Удмуртия Республикасы Халык иҗаты йорты оештырган «Кросна» дип аталган заманча тукучылык фестивалендә катнашты (Кыяс районы Карамас-Пельга авылы). Чарада катнашучыларга туку остасы З.А. Мәҗитова Карамас-Пельга авылында урнашкан музейдагы кул эшләнмәләрен тәкъдим итте. Фестиваль кысаларында шулай ук удмуртларның көнкүреше һәм мәдәнияте белән таныштыру максатыннан, Иске Салья авылына десант оештырылды. Сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова, «Бизәкле туку: үткәннән киләчәккә» дигән түгәрәк өстәлдә катнашып, «Татарстан Республикасында тукучылыкны үстерү проблемалары һәм перспективалары» дигән темага доклад белән чыгыш ясады.

**2022 елның 16 августында** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре Татарстан Республикасы педагогик хезмәткәрләре һәм идарә кадрларының «Татарстан Республикасында милли мәгарифне үстерү» темасына багышланган республика форумы эшендә катнашты. Казан шәһәренең «Адымнар – белем һәм татулыкка юл» полилингваль комплексында оештырылган методик мәйданчыкларда гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары каршында Институтның милли мәгариф бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты Г.Н. Мөхәрләмова һәм шул ук бүлекнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты, доцент Л.М. Гыйниятуллина чыгыш ясады. Алар форумда катнашучыларны ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты-

ның милли мәгариф өлкәсендә тормышка ашырыла торган проектлары белән таныштырдылар.

**2022 елның 19 августында** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Татарстанга, Казакъстан тарихы буенча документлар һәм кульъязмаларны ачыклау максатыннан, эш визиты белән килгән Казакъстан Республикасы Кульъязмалар һәм сирәк китаплар милли үзәге вәкилләре белән эшлекле очрашу узды. Институт эшчәнлеге, тормышка ашырыла торган проектлар белән кунакларны директорның фән буенча урынбасары, филология фәннәре кандидаты Олег Хисамов, инновацион эшчәнлек һәм тышкы элемтәләр буенча директор урынбасары, филология фәннәре кандидаты Алсу Шәрипова таныштырды. Очрашу барышында алга таба хезмәттәшлек турында сүз барды, уртак эшчәнлек юнәлешләре билгеләнде. Кульъязмалар һәм сирәк китаплар милли үзәге директоры урынбасары Нурлан Ережепов җитәкчелегендәге Казакъстан белгечләре шулай ук ТӘһСИнең Язма мирас үзәге эшчәнлеге белән дә таныштылар.

**2022 елның 21–31 августында** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең чираттагы комплекслы экспедициясе Красноярск өлкәсенең Пировск районында эшләде. Экспедициянең максаты әлеге төбәктәге татар авылларын барлау, халыкның рухи һәм матди культурасын өйрәнү, тел үзенчәлекләренә һәм фольклорына кагылышлы материаллар туплау иде. Пировск районының татарлар яши торган торак пунктларында – Икшүрмә, Коврига, Яңа Тимершик, Яңа Сатыш, Комаровка, Шагирислам, Долгово, Солоуха, Куренная Ошма, Пировск авылларында эш алып барылды. Экспедициянең җитәкчесе – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары О.Р. Хисамов авылларның микротопонимиясенә караган материаллар туплады; лексикология һәм диалектология бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре А.Я. Хөсәинова әлеге төбәктә яшәүче татар халкының тел үзенчәлекләрен өйрәнде; халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре И.Г. Закирова фольклорның төрле жанрларына караган материалларны, иске татар язулы китапларны барлады; Сәнгать үзәге фәнни хезмәткәре Н.В. Герасимова халыкның матди мәдәниятенә караган материал туплады, Сәнгать үзәге фәнни хезмәткәре Н.Х. Нургаянова халыкның музыкаль мирасын өйрәнеп, биредә башкарыла торган җырларны, мөнәҗәтләрне, бәетләрне, уен фольклорын язып алды.

**2022 елның 24 августында** Мәскәүдә Россия дәүләт балалар китапханәсендә Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллинга (1948–2020) багышланган кичә оештырылды. Чарада Татарстан шагыйрьләре һәм язучылары, Роберт Миңнуллинның туганнары һәм якыннары катнашты. Чара Мәскәүдә Татарстан мәдәнияте һәм Татар балалар әдәбияты көннәре кысаларында үтте.

**2022 елның 24–25 августында** Казанда Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов ярдәме белән Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы Идел буе

федераль округының чираттагы «Сообщество» форумын уздырды. Форумның максаты – социаль проектларны эшләү һәм гамәлгә ашыру сыйфатын арттыруга һәм секторара хезмәттәшлекне үстерүгә ярдәм итү.

«Россия: мәдәниятләр күптөрлелеге, гражданнар бердәмлеге» темасына багышланган өченче форум кысаларында утызга якын эш мәйданчыгы – секцияле дискуссияләр һәм проект сессияләре, түгәрәк өстәлләр, мастер-класслар, семинарлар, питчинг-сессияләр, тренинглар һәм эшлекле киңәшмәләр оештырылды. Чарада дәүләт оешмалары вәкилләре, коммерцияле булмаган оешмалар, иҗтимагый оешмалар вәкилләре, галимнәр, журналистлар һ.б. катнашты.

**2022 елның 5 сентябрендә** Казанда Толстой урамы 16 А йорт диварында Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллинга истәлек тактасы ачылды. Чарада Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәшин, Татарстан Республикасы Мәдәният министры Ирада Әюпова, Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары, галимнәр, журналистлар, киң җәмәгатьчелек катнашты.

**2022 елның 6 сентябрендә** Г. Тукайның Казандагы әдәби музеенда шагыйрьнең Троицк шәһәренә баруына 110 ел тулуга багышланган «Тукай Троицкида» күргәзмәсе ачылды. Экспозициядә 2022 елның 2–12 июлендә Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәрендә узган «Тукай Троицкида» исемле артпленэр кысаларында иҗат ителгән төрле жанрдагы кырыклап рәсем һәм графика әсәре, шулай ук Татарстан Республикасы Милли музеенда, Троицк туган якны өйрәнү музеенда, КФУның Н. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклануучы архив материаллары, сирәк фотосурәтләр, Г. Тукай һәм Троицк шәһәренә багышланган басмалар тәкъдим ителә. Тамашачылар һәм кунаклар алдында сәламләү сүзе белән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты, филология фәннәре докторы Д.Ф. Заһидуллина, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек бүлеге мөдире А.Ш. Фәйзрахманов, Троицк шәһәре мэры А.Г. Виноградов, Троицк туган якны өйрәнү музее директоры, тарих фәннәре кандидаты Е.Г. Подгайко, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы, Троицк шәһәрендә туган Р.Г. Сафиуллина чыгыш ясады. Проект кураторы, әлеге күргәзмәне оештыручы, ТӘһСИнең Сәнгать белеме үзәге мөдире, сәнгать белеме докторы Р.Р. Солтанова хәзерге Троицк шәһәре сурәтләре, Тукайның «Валлаһи» шигыре буенча Троицк шәһәренең үзәк мәйданында рус һәм татар телләрендә күрсәтелгән флешмоб белән таныштырды.

**2022 елның 7–11 сентябрендә** Казанда XVIII Казан халыкара мөселман киносы фестивале узды. Комиссия рәисе буларак, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе һәм Россиянең халык артисты Владимир Хотиненко чакырылган иде. Биш көн дәвамында төрле мәйданчыкларда тамашачылар игътибарына иллегә якын фильм тәкъдим

ителде. Конкурста Россиянең унсигез өлкәсеннән һәм егермедән артык илдән кунаклар катнашты.

**2022 елның 9 сентябрендә** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре Ульяновскида узган Халыкара конференция эшендә катнашты. Чара мәдәни мирасны саклау мәсьәләләренә багышланган иде. Ул XII Халыкара «Пластовская осень» рәссамнар ассамблеясы кысаларында В.И. Ленин исемендәге Ульяновск өлкә фәнни китапханәсендә (Китап сараенда) узды. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләренең конференциядә ясаган чыгышлары зур кызыксыну уятты. Сәнгать белеме кандидаты О.Л. Улемнованың доклады 1920 елларда Казан авангарды рәссамнары иҗатында крестьян мотивларына багышланган иде. Филология фәннәре кандидаты А.Я. Хөсәинова үз чыгышында татар мәдәниятен һәм телен саклауда мөһим элемент булган татар авыллары исемнәренең үзенчәлекләре турында сөйләде; сәнгать белеме кандидаты Н.В. Герасимова Себер авылларының татар утарлары турында сөйләде, аларның милли тәңгәллекне саклауда һәм туристларны җәлеп итүдәге зур ролен билгеләп үтте.

**2022 елның 9 сентябрендә** Казакъстанның Семей шәһәрендә «Иртыш буе татарлары: тарих һәм хәзерге заман» дип исемләнгән Халыкара фәнни-гамәли тарихи-төбәк тарихын өйрәнү конференциясе оештырылды. Чарада Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе В.Г. Шәйхразыев, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шакиров, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының Татар төбәкләрен өйрәнүчеләр белән эшләү комитеты җитәкчесе А.Ә. Борһанов, галимнәр, туган якны өйрәнүчеләр, дин һәм җәмәгать эшлеклеләре, Абай өлкәсе Семей шәһәренең, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясендә татарлар күпләп яшәгән тарихи төбәкләрнең татар иҗтимагый оешмалары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашты. Конференциягә Татарстаннан барган делегация составында ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге мөдире И.Г. Гомәров һәм баш фәнни хезмәткәр А.М. Ахунов бар иде. Галимнәр «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә чыккан «Милли-мәдәни мирасыбыз: Казахстан татарлары. Семей» китабын презентацияләделәр.

**2022 елның 10 сентябрендә** Казан шәһәрендә «Мәдәниятләр мозаикасы» сигезенче этноконфессиональ фестивале узды. Фестивальнең төп оештыручылары – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Казан шәһәре Башкарма комитеты, Татарстан Халыклары ассамблеясы һәм Дуслык Йорты. Фестиваль мәйданчыгында кунакларга халык кәсепләре эшләнмәләре күргәзмәсе, этномаркет, Татарстан Республикасының традицион конфессия мәйданчыклары, шулай ук фудмаркет тәкъдим ителде.

**2022 елның 14 сентябрендә** А.С. Пушкин исемендәге Алабуга Үзәк китапханәсенең уку залында

танылган татар драматургы һәм режиссер Кәрим Тинчуринның туына 135 ел тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә оештырылды. 15 сентябрь – татар драматургиясе классигы Кәрим Тинчурин гына түгел, татар халкының тагын бер күренекле талант иясе – Таҗи Гыйззәтнең дә туган көне, шунлыктан Алабугада узган әдәби-музыкаль кичәнең беренче өлеше биредә тәүге татар театрын оештыручы драматург Таҗи Гыйззәткә багышланды. «Мәңге балкыр йолдыз» исемле әдәби-музыкаль кичә күтәренке рухта узды.

**2022 елның 15–16 сентябрендә** КФУ базасында Федерация Советының фән, мәгариф һәм мәдәният комитеты әгъзалары катнашында Россия Федерациясе халыкларының туган телләре һәм әдәбияты буенча II Федераль олимпиаданы оештыручыларның Бөтенроссия конференциясе узды. 2022 елның Конференциянең пленар утырышында Россия югары уку йортлары укытучылары Татарстанда балаларны татар теленә өйрәтү ысуллары һәм туган телне саклау һәм үстерү юллары турында фикер алыштылар. Чарада Татарстан Мәгариф һәм фән министры урынбасары М.З. Закирова, Филология һәм мәдәниятара бәйләнышлар институты директоры Р.Р. Җамалетдинов, рус теле һәм мәдәниятара коммуникацияләр югары мәктәбе факультеты деканы Р.Ф. Мөхәммәтшина, Бөтендөнья татар конгрессының «Дөнья» студиясе җитәкчесе Энҗе Шәйхетдинова һ.б. катнашты. Олимпиада мәктәп укучылары олимпиадаларының Россия Советы олимпиадалары исемлегенә керә. Олимпиада дипломантлары югары уку йортларына сынаулардан башка керү хокукын куллана ала. Узган уку елында Олимпиада Россиянең алты югары уку йорты тарафыннан сигез тел буенча уздырылды.

**2022 елның 17 сентябрендә** Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан август ахырында игълан ителгән «Әхмәт ибн Фадланның Итил елгасына сәяхәте» китабы буенча бәйгенең сайлап алу туры узды. Иллегә якын кеше китап хакында тест рәвешендәге сорауларга җавап бирде. Китапны халык арасында популярлаштыру өчен уздырыла торган конкурсның төп шарты – аны тулысынча укып чыгу һәм аерым эпизодларын истә калдыру. Сайлап алу туры нәтиҗәләре сентябрь ахырында игълан ителде, иң күп балл җыючылар 22 октябрьдә Казанда узачак финалда катнашачак.

**2022 елның 19–20 сентябрендә** Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев эшлекле сәфәр белән Әстерхан өлкәсендә булды. 20 сентябрьдә ул Әстерхандагы Муса Җәлил һәйкәленә чәчәкләр салды. Биредә Муса Җәлил һәйкәле «Россия Даны аллеясы» Россия проекты кысаларында 2017 елның 13 маенда ачылган иде. Бөек шагыйрь хәтерен мәңгеләштерү эшендә беренче адымнар Әстерхан җәмәгать эшлеклесе Әдилә Умерова һәм «Дуслык» татар милли мәдәнияте җәмгыяте активистлары инициативасы белән ясала. Проект авторы – Краснодар скульпторы Александр Аполлонов.

**2022 елның 21 сентябреннән 29 сентябренә кадәр** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Татарстанның Баулы районына комплекслы фәнни экспедиция оештырылды. Филология фәннәре докторы, Институтның гыйльми сәркатибе Ләйлә Хәсән кызы Дәүләтшина җитәкчелегендәге галимнәр төркеме Баулы районы татар авылларында һәм Баулының үзендә эш алып барды. Кыр тикшеренүләре барышында галимнәр татар халкының милли-мәдәни мирасын өйрәнделәр, аның авыз иҗаты, теле, сәнгате, музыкасы, археографиясе, шулай ук традицион мәдәнияте буенча бай материал тупладылар.

**2022 елның 21–30 сентябрендә** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге хезмәткәрләре составындагы эпиграфик экспедиция Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәрендә эшләде. Кыр тикшеренүләре вакытында галимнәр төркеме (И.Г. Гомәров, А.М. Ахунов, В.М. Усманов) 300 гә якын кабер ташын теркәде һәм тасвирлады. Шулай ук җирле архивта, туган якны өйрәнү музеенда, шәһәр мәчетләрендә фәнни-эзләнү эшләре үткәрелде. Нәтиҗәдә, элек билгеле булмаган кулъязма материаллар һәм фотосурәтләр табылды. Моннан тыш, шәһәрнең татар җәмәгатьчелеге һәм «Рәсүлия» мәдрәсәсе шәкертләре белән очрашулар узды.

**2022 елның сентябрь аенда** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Д 022.006.02 диссертацияләр яклау советы үз эшчәнлеген дәвам итте. Бу айның чираттагы утырышларында ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре Ләйсән Надыршина, шушы ук бүлекнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Лилия Гыйниятуллина, директорның инновацион эшчәнлек һәм тышкы элемтәләр буенча урынбасары Алсу Шәрипова, директорның фән буенча урынбасары Олег Хисамов филология фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсенә диссертацияләрен уңышлы якладылар. Д 022.006.02 советында алдарак уңышлы яклау узган диссертацияләр хакында сөенечле хәбәрләр килә тора: 8 сентябрь көнне диссовет утырышында тантаналы шартларда Лениза Хәбибуллинага, Бәхтияр Миңнуллинга, Ләйлә Дәүләтшинага һәм Алсу Хасавнехка Югары аттестация комиссиясе тарафыннан расланган докторлык дипломнары тапшырылды. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе диссертацияләр яклау советы үз эшен дәвам итә.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2022. № 3

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 30.09.2022. Басылды: 17.10.2022.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 12. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать
институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
нәшриятында басылды
(нәшрият адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал бушлай таратыла




Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы Идел буе федераль округының
«Сообщество» форумы. Казан, 2022 ел, 24 август.
*Фото https://president.tatarstan.ru/pressa/photoreports/photoreport/8315979.htm сайтыннан алынды*



Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллинга истәлек тактасы ачылу тантанасы.
Казан, 2022 ел, 5 сентябрь.
*Фото https://shaimiev.tatarstan.ru/pressa/photoreports/photoreport/8337319.htm сайтыннан алынды*




«Татарстан Республикасында милли мәгарифне үстерү» темасына багышланган
республика форумы. Казан, 2022 ел, 16 август.
*Фото https://mon.tatarstan.ru/foto.htm/photoreport/8299919.htm сайтыннан алынды*



Троицк туган якны өйрәнү музее базасында «Тукай Троицкида» дип аталган Бөтенроссия арт-пленэры (проектның кураторы – Сәнгать белеме үзәге мөдире, сәнгать фәннәре докторы Р.Р. Солтанова)



Г. Тукайның Казандагы әдәби музеенда шагыйрьнең Троицк шәһәренә баруына 110 ел тулуга багышланган «Тукай Троицкида» күргәзмәсе ачылу чарасы. 2022 ел, 6 сентябрь





Татарстан Республикасы вәкилләре «Кросна» дип аталган заманча тукучылык фестивалендә. Удмуртия Республикасы Кыяс районы Карамас-Пельга авылы. 2022 ел, 15 август

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре фәнни экспедицияләрдә




Красноярск краенда



Баулы районында





Пенза өлкәсендә





Троицк шәһәрендә

## Г.И. Каюмованың «Камаллар династиясенең дәвамчысы» мәкаләсенә



Гәүһәр Камалова балачакта



Гәүһәр Камалова



Г. Камалова «Миркәй белән Айсылу» спектаклендә



Г. Камалова «Назлы кияү» спектаклендә



Г. Камалова «Татар хатыны ниләр күрми» спектаклендә

## Ф.Х. Миңнуллинаның «Олы галим, милләтпәрвәр шәхес» мәкаләсенә



Н. Ханзафаров (уңнан икенче) «Татар комедиясе (чыганаклары һәм үсеше)» хезмәте өчен Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләген алганнан соң. 1997 ел



«Сөембикә» операсы авторлары Б. Мөлеков һәм Н. Ханзафаров

## Яңа китаплар




«Татар халык иҗаты: 25 томда. 1 т.: Мифология» ([төз., иск. һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт. Л.Х. Дәүләтшина] Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. 511 б.)